# ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВНЫҢ тормыш һәм иҗат юлы

# Жизнь и творчество ГАЛИМДЖАНА ИБРАГИМОВА

УДК 929.821.512.145
ББК 83.3(2Рос=Тат)
Ж71

*Публикуется решением Ученого совета
Института языка, литературы и искусства
им. Г. Ибрагимова АН РТ*

Автор текста на татарском языке
*Д.Ф. Загидуллина*

Перевод на русский язык
*Л.Ш. Давлетшиной*

Ж71 Жизнь и творчество Галимджана Ибрагимова. – Казань: ИЯЛИ, 2017.

Издание приурочено к 130-летию татарского писателя и общественного деятеля Галимджана Ибрагимова, посвятившего свои способности и таланты развитию национальной культуры и коренным изменениям татарского общества. Журналист, литературовед, критик, историк, языковед, педагог, политик Ибрагимов проявил себя в разных областях жизни. В издании в хронологическом порядке представлены основные моменты биографии и ступени духовного становления, обусловленные непростыми общественно-историческими событиями, а также проанализированы художественные произведения Г. Ибрагимова разных лет.

Текст издания на двух языках: татарском и русском. Книга оснащена иллюстрациями.

© Институт языка, литературы
и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ, 2017



Галимджан Гирфанович Ибрагимов
1887–1938

XX йөзнең беренче чирегендә татар яңарышын, фикри күтәрелешне, җәмгыятьнең тизләнеп үсүен аерым шәхесләр, милләт язмышын үз язмышы кебек кабул иткән кешеләр оештыру, бербөтен хәрәкәткә үстереп җиткерү мәгълүм. Бу хәрәкәтне әйдәп баручылар арасында берьюлы төрле өлкәләрдә: сәнгатьтә булсын, сәясәттә, фәндә, мәгарифтә-мәдәнияттә һ.б. – яңа сукмаклар салган, өр-яңа күзаллау булдырган, шулай татарлар өчен киләчәкне формалаштырган кешеләр, идея әйдәманнары бар. Акыл һәм сәләтен, хезмәтен һәм көчен милли мәдәниятне, халыкның үзаңын үстерүгә багышлаучыларның берсе Галимҗан Ибраһимов та (Галимҗан Гыйрфан улы Ибраһимов, 1887–1938) татар җәмгыятенең хәл-халәте белән риза-канәгать булмыйча, аны тамырдан үзгәртергә алынган шәхесләрдән була. Язучы, әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче, журналист, тарихчы, тел белгече һәм педагог, җәмәгать эшлеклесе һәм сәясәтче булып танылганда аңа 30 яшь тә булмый әле.



Галимҗан Ибраһимов
Галимджан Ибрагимов





Галимҗан Ибраһимов туграсы. Нәҗип Нәккаш эше. 2007
Тугра Галимджана Ибрагимова. Автор – Наджип Наккаш. 2007

Первая четверть XX века ознаменована возрождением татарской культуры, небывалым подъемом национального самосознания, формированием единого общественного движения, все свои усилия направившего во благо нации. Все эти процессы стали возможны в том числе благодаря деятельности отдельных людей, которые принимали судьбу народа как свою собственную. Среди ведущих деятелей этого движения есть идейные вдохновители, которые проложили пути сразу в нескольких областях: искусстве, политике, науке, образовании и др., открыли новое видение и таким образом сформировали будущее татарского народа. Один из тех, кто посвятил все свои способности и таланты развитию национальной культуры, самосознания народа, Галимджан Ибрагимов (Галимджан Гирфанович Ибрагимов, 1887–1938), не соглашаясь с культурной изоляцией татарского общества, он взялся за его коренное изменение. Писатель, литературовед и критик, журналист, историк, языковед и педагог, общественный деятель и политик… Когда получил признание в этих областях, Галимджану не было даже тридцати.

Яңарыш хәрәкәтен мәйданга чыгарган күп шәхесләрнең биографиясендә, рухи үсү-ныгуында уртак сәхифәләр, гомум иҗтимагый-тарихи сәбәпләр бар. Соңарып, XIX гасырның ахырында гына формалашкан татар мәгърифәтчелеге Беренче рус революциясе белән тоташып китә, Россия зыялылары инкыйлаби күтәргән шигарьләр татар мәгърифәтчеләренең максатлары белән аваздаш яңгырый. Кискен алгарышлар яшь буынның дөньяга карашына гаять көчле йогынты ясый, яшьләр тарихи вакыйгаларның уртасында кала һәм кайсыдыр бер мизгелдә шуларны үз мохитендә әйдәп баручыга әверелә.

Галимҗан Ибраһимов 1887 елның 12 мартында элеккеге Уфа губернасы Эстәрлетамак өязенең (хәзерге Башкортстанның Авыргазы районы) Солтанморат авылында дөньяга килә (Афзал Шамов 1961 елда бу датаның иске стильдән яңага күчкәндә төгәл билгеләнмәгәнлеген, 10 март булырга тиешлеген исбатлый) [Шамов А.



Солтанморат авылының хәзерге күренеше
Современный вид деревни Султанмуратово



В биографии личностей, выведших татарское возрожденческое движение на новый уровень, есть общие страницы: ступени духовного становления, общественно-исторические причины. Идеи татарского просветительства, сформированного несколько позже, лишь в конце XIX века, соединились с лозунгами Первой русской революции, а произведения русской интеллигенции, одухотворенные революционной идеей, звучали в унисон с целями татарских просветителей. Резкие скачки общественного движения, как правило, оказывают весьма сильное влияние на мировоззрение молодого поколения, и в начале XX века татарская молодежь оказалась в гуще исторических событий, став в определенный момент ведущей силой в своей среде.

Галимджан Ибрагимов родился 12 марта 1887 года в деревне Султанмуратово Стерлитамакского уезда Уфимской губернии (сейчас Аургазинский район Республики Башкортостан) (в 1961 году Афзал Шамов доказал, что дата рождения писателя не до конца уточнена при переходе на новый



Г. Ибраһимов кайчан туган? // Галимҗан Ибраһимов: мәкаләләр, истәлек-хатирәләр: төз. Р. Акъегет. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. Б. 343–344].

Авыл тарихы Ибраһимовларның нәсел тарихы белән тыгыз бәйләнгән. Түрсәгәле елгасы белән Авыргазы елгасы килеп кушылган урманлы уйсулык җирләр 1756 елда старшина Солтанморат Янышевка (?–1777) бирелә. Янышевлар нәселеннән чыккан бу морза Себер даругасында старшина булып тора, соңрак почта хезмәтендә эшли, ат сәүдәсеннән салым җыючы була. Е. Пугачев восстаниесен (1773–1775) бастыруда үзенең атлы отряды белән күрсәткән батырлыклары өчен 1776 елда ике алтын медаль белән бүләкләнә. 1775 елда «башкорт депутациясе» составында патшабикә Екатерина II белән күрешә [Султанмурат Янышев // Башкирская энциклопедия. Уфа: Башкирская энциклопедия, 2010. Т. 6. С. 155].

Әлеге матур урыннарны ошатып, Янышев бирегә татарларны күчереп утырта. Авылга 1761 елда нигез салына



Старшина Солтанморат Янышев тарафыннан Юмадил Бухаровка бирелгән документ. 1771 ел, 12 февраль.

Отпускное письмо, выданное мишарским старшиной Султанмуратом Янышевым мишарину Юмадилю Бухарову. 12 февраля 1771.

Источник: Галимджан Ибрагимов: документы и факты; Галимджан Ибрагимов глазами молодых / [авт.-сост. М.Х. Ибрагимов]. Казань: Татар. кн. изд-во, 2012





1850 елгы «Ревизия кенәгәләре»ннән бер фрагмент.

Фрагмент из «Ревизской сказки» 1850 года.

Источник: Галимджан Ибрагимов: документы и факты; Галимджан Ибрагимов глазами молодых / [авт.-сост. М.Х. Ибрагимов]. Казань: Татар. кн. изд-во, 2012

стиль, в действительности же должно быть 10 марта. См.: Шамов А.Г. Ибраһимов кайчан туган? // Галимҗан Ибраһимов: мәкаләләр, истәлек-хатирәләр: төз. Р. Акъегет. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. Б. 343–344).

История деревни тесно связана с историей рода Ибрагимовых. Лесистые пойменные земли в месте слияния рек Турсали и Аургази в 1756 году были переданы старшине Султанмурату Янышеву (?–1777). Этот мурза из рода Янышевых был старшиной Сибирской даруги, позже служил в почтовой службе, был собирателем налогов от торговли лошадьми. За героизм, проявленный со своим конным отрядом в подавлении восстания Е. Пугачева (1773–1775), в 1776 году был награжден двумя золотыми медалями. В 1775 году в составе «башкирской депутации» встретился с царицей Екатериной II [Башкирская энциклопедия: в 7 т. Уфа: Башкирская энциклопедия, 2010. Т. 6, С. 155].

Эти красивые места приглянулись Янышеву, и он решил переместить сюда татар. Деревня была основана в 1761 году

һәм ул бик тиз үсеп китә: Янышев бирегә су тегермәне, тире эшкәртү заводлары кордыра. 1795 елда инде мондагы 60 йортта 408 кеше яшәве мәгълүм. Г. Ибраһимов дөньяга килгән чорда ул зур авыллардан санала. Мәсәлән, 1865 елгы җан исәбе алуда ул ике авыл дип язылган, алардагы 323 йортта 2302 кеше теркәлгән, ике мәчет, ике башлангыч рус мәктәбе эшли [Султанмуратово // Башкирская энциклопедия. Т. 6. С. 155–156].

Ибраһимовларның нәсел шәҗәрәсе Әхмәт (1587–1684) имамнан башлана: Локман (1621–1701), Ибраһим (1684–1753), Хисаметдин (1744–1811), Әхмәт (1786–1865), Нурмөхәммәт (1816–1899) һәм Галимҗанның әтисе Гыйрфан (1847–1913)... [Ибрагимов А.О. Галимджан Ибрагимов в жизни нашей семьи // Галимджан Ибрагимов: документы и факты; Галимджан Ибрагимов глазами молодых: авт.-сост. М.-Х. Ибрагимов. Казань: Татар. кн. изд-во, 2012. С. 259]. Мохтар Ибраһимов истәлекләренә караганда, аларның нәселе Әхмәт ахунны авылга имам итеп Бөре өязеннән



Галимҗан Ибраһимов туган йорт.
Татарстан ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге (ЯһММҮ). Ф. 65. Тасв. 5. С.б. 56

Дом, где родился Галимджан Ибрагимов.
Центр письменного и музыкального наследия Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ (ЦПиМН). Ф. 65. Оп. 5. Ед. хр. 56





Галимҗан Ибраһимовның туу турында таныклыгы.
ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 2. С.б. 1

Свидетельство о рождении Галимджана Ибрагимова.
ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 2. Ед. хр. 1

и очень быстро разрослась. Янышев основал здесь водяную мельницу, дубильный завод. Известно, что в 1795 году здесь уже обитали 408 человек в 60 хозяйствах. Во времена, когда родился Г. Ибрагимов, эта деревня считалась одной из крупных. К примеру, по итогам подушной переписи 1865 года она обозначена как две деревни: зафиксированы 2 302 человека в 323 хозяйствах, 2 мечети, 2 начальные русские школы [Башкирская... С. 155–156].

Родословная семьи Ибрагимовых начинается с имама Ахмета (1587–1684), далее идут Лукман (1621–1701), Ибрагим (1684–1753), Хисамутдин (1744–1811), Ахмет (1786–1865), Нурмухаммет (1816–1899) и отец Галимджана Гирфан (1847–1913) [Галимджан Ибрагимов: документы и факты; Галимджан Ибрагимов глазами молодых: авт.-сост. М.-Х. Ибрагимов. Казань: Татар. кн. изд-во, 2012. С. 259]. Судя по воспоминаниям Мухтара Ибрагимова, их семья обосновалась в деревне Султанмуратово, когда ахуна Ахмета пригласили имамом из Бирского уезда. Точная дата

чакырып китергәннән соң шушында төпләнә. Әхмәт ахунның бирегә күченү елы билгеле булмаса да, М.В. Гайнетдинов Оренбург дәүләт архивында тапкан материалларга караганда, ахун Хисаметдин Ибраһимовның улы Әхмәтне 1807 елның 28 гыйнварендa Солтанморат авылы мәчетенә мулла итеп билгеләү хакында документ сакланган [Гайнетдинов М.В. Г. Ибраһимов һәм Ф. Кәрими // Галимҗан Ибраһимов һәм хәзерге заман: тууына 115 ел тулуга багышланган фәнни конференция материаллары. Казан: Фикер, 2002. Б. 55]. Әхмәт ахунның улы Нурмөхәммәт, Эстәрлетамак өязенең Эстәрлебаш мәдрәсәсендә белем алып, шулай ук гомере буе авылда муллалык итә. Аның дүрт кызы һәм сигез улы арасында өченче бала булып дөньяга килгән Гыйрфан исә Уфадан ерак түгел Кыешкы авылында мәдрәсәдә укый, шунда мөгаллим булып урнашып кала, аннары Троицк шәһәрендәге Рахманколовлар мәдрәсәсенә мөдәррис итеп чакырыла. Шәһәр кызы Бибихәсәнәгә өйләнеп, Солтанморатка әйләнеп кайта [Ибраһимов Мохтар.



Габделхәким – Г. Ибраһимовның бертуган энесе. 1930.

Младший брат Галимджана – Габдельхаким. 1930.

Источник: Галимджан Ибрагимов: документы и факты; Галимджан Ибрагимов глазами молодых / [авт.-сост. М.Х.Ибрагимов]. Казань: Татар. кн. изд-во, 2012





Шакирҗан – Г. Ибраһимовның бертуган абыйсы. 1913.

Старший брат Галимджана – Шакирджан. 1913.

Источник: Галимджан Ибрагимов: документы и факты; Галимджан Ибрагимов глазами молодых / [авт.-сост. М.Х.Ибрагимов]. Казань: Татар. кн. изд-во, 2012

переселения Ахмета ахуна в деревню Султанмуратово не известна. Но, как свидетельствуют материалы, обнаруженные М.В. Гайнутдиновым в Государственном архиве Оренбургской области, сохранился документ о назначении сына Хисамутдина Ибрагимова Ахмета муллой деревни Султанмуратово 28 января 1807 года [Галимҗан Ибраһимов һәм хәзерге заман: тууына 115 ел тулуга багышланган фәнни конференция материаллары. Казан: Фикер, 2002. Б. 55]. Сын ахуна Ахмета Нурмухаммет получил образование в медресе Старлебаш Стерлитамакского уезда, всю свою жизнь прослужил муллой в деревне. Среди его четырех дочерей и восьми сыновей третьим ребенком родился Гирфан. Он учился в медресе деревни Каешлы недалеко от Уфы, там же остался учителем, затем был приглашен мударрисом в медресе Рахмакуловых в Троицке. В городе женился на Бибихасане Загидулловне (1862–1921) и вернулся в Султанмуратово [Галимҗан Ибраһимов: мәкаләләр, истәлекхатирәләр. Б. 49–50].

Туганым турында // Галимҗан Ибраһимов: мәкаләләр, истәлек-хатирәләр. Б. 49–50].

Галимҗан Ибраһимов менә шушы указлы мулла Гыйрфан хәзрәт һәм Троицк шәһәре кызы Бибихәсәнә гаиләсендә дүртенче бала булып дөньяга килә. Җиде баланың өчесе яшьли вафат була.

Гыйрфан хәзрәт гадәти авыл көнитешен үз күрә: җир эшләрен башкарып яшәргә тели, ат чабышларын бик ярата һәм чабышкы атлар асрый. 1910 елларда муллалыгын ташлап, игенчелек белән көн күрүгә күчә.

Белем-мәгърифәтле, буыннан-буынга муллалык итеп, халыкны агартып яшәгән нәселнең лаеклы дәвамчысы булырга тиешле уллары Шакирҗан белән Галимҗанга Гыйрфан хәзрәт төпле белем бирергә омтыла. Алар башта гаиләдә, аннары Кешәнне авылы мәктәбендә һәм туган авылларындагы өч сыйныфлы земство мәктәбендә укып, дини һәм русча башлангыч белем алалар. Галимҗан йөгерек фикерле, телгә оста шәкерт була, яхшы укый. Земство



Бибихәсәнә Загидулла кызы – Г. Ибраһимовның әнисе. 1918. ЯҺММҮ. Ф. 65. Тасв. 5. С. б. 2

Бибихасана Загидулловна – мать Г. Ибрагимова. 1918. ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 5. Ед. хр. 2





«Хөсәения» мәчете. Оренбург

Мечеть «Хусаиния». Оренбург

Галимджан Ибрагимов родился четвертым в семье указного муллы Гирфана хазрата и его жены из Троицка Бибихасаны. Из семи детей трое умерли в детском возрасте.

Гирфану по нраву была обычная сельская жизнь: он хотел работать на земле, любил скачки и сам разводил скаковых коней. В 1910 году он оставил занятия муллой и полностью посвятил себя сельскому хозяйству.

Сыновьям Шакирджану и Галимджану, которые в свое время должны были продолжить достойное дело семьи, из поколения в поколение занимавшегося просвещением народа, Гирфан хазрат стремился дать достойное образование. Сначала дети учились в семье, затем в школе деревни Кешанне и земской трехклассной школе в родной деревне. Галимджан был одним из лучших учеников, его отличали быстрота ума, мастерское владение словом. За успешно выдержанные выпускные экзамены после окончания земской школы братья Ибрагимовы были награждены

мәктәбен тәмамлап имтиханнарны уңышлы тапшырган өчен, абыйлы-энеле Ибраһимовларны Пушкин китабы белән бүләкләүләре дә мәгълүм [Ибраһимов Мотаһар. Туганым турында // Галимҗан Ибраһимов: мәкаләләр, истәлек-хатирәләр. Б. 58–59].

1898 елны әтиләре ике улын Оренбургка «Хөсәения» мәдрәсәсенә илтә. Әмма 11 яшьлек Галимҗанны, яше җитми һәм авыру дип, монда кабул итмиләр. Әтисе аны «Вәлия» мәдрәсәсендә укырга калдыра.

«Вәлия» яки «Вәли мулла мәдрәсәсе» 1720 елны ачылган, искечә (кадими) укытучы мәдрәсәләрдән була. Үзе дә кадими Кышкар мәдрәсәсен тәмамлаган Вәли мулла укыту системасында традицияләрне саклауны, моннан 100–200 ел элек кертелгән тәртипләрне үзгәрешсез үтәүне мөһим дип саный. Галимҗан биредә сигез ел укый, дини һәм фәлсәфи мәсьәләләрдә төпле белем ала. Аның динифәлсәфи бәхәсләрдә көчле булуы, Вәли мулла белән шундый мәҗлесләргә баруы истәлекләрдә теркәлеп калган.




«Хөсәения» мәдрәсәсе. Оренбург

Медресе «Хусаиния». Оренбург





«Вәлия» мәдрәсәсе урнашкан йорт. Оренбург.

Здание медресе «Валия». Оренбург.

Источник: Галимджан Ибрагимов: документы и факты; Галимджан Ибрагимов глазами молодых / [авт.-сост. М.Х.Ибрагимов]. Казань: Татар. кн. изд-во, 2012

книгой Пушкина [Галимҗан Ибраһимов: мәкаләләр, истәлек-хатирәләр... Б. 58–59].

В 1898 году отец отвез сыновей в Оренбург, в медресе «Хусаиния», но 11-летнего Галимджана не приняли, сославшись на то, что еще слишком молод да и здоровьем слаб. Отец оставил его в медресе «Валия».

«Валия», или «Медресе Вали муллы», открытое в 1720 году, было кадимистким учебным заведением. Вали мулла и сам окончил кадимисткое медресе Кышкар и считал основой всего сохранение традиций и порядков в образовании, введенных 100–200 лет назад. Галимджан отучился здесь 8 лет, получил основательное мусульманское религиозное и философское образование. В воспоминаниях отражено, что он был силен в религиозно-философских диспутах, посещал такого рода собрания вместе с Вали муллой.

Однако шакирды были не согласны с обучением по-старому, требования преподавать и светские дисциплины звучали все громче и громче в татарских медресе. Галимджан

Әмма заман шәкертләре искечә укыту белән килешмиләр, дөньяви фәннәрне укыту таләбе татар мәдрәсәләрендә көннән-көн көчлерәк яңгырый. Галимҗан да шәһәр китапханәсенә йөри, газета-журналлар укып бара, мәдрәсәләрдә иске тәртипләргә каршы хәрәкәт кузгалгач, шуңа кушыла. 1905 елны искечә укытуга каршы чыгышлары өчен мәдрәсәдән куыла. Соңрак бу вакыйгалар аның «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» (1907) хикәясендә сурәтләнә.

Хикәя 1907 елда әдәби эчтәлеген Фатих Әмирхан формалаштырып килгән «Әл-ислах» газетында басылып чыга. Замандашлары аның тормыштан алынып язылган булуына, шул чор кадим мәдрәсәләрендә укыту тәртипләрен бик җентекләп, натуралистик детальләрдә сурәтләвенә игътибар итәләр [Фатих Әмирхан турында истәлекләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. Б. 191; Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. Т. 1: Хикәяләр (1907–1929). 505 б.]. Чыннан да, хикәя кадим мәдрәсәләрнең эчке


„ЭЛЬ-ИСЛАХЪ"

«Әл-ислах» газетасы

Газета «Аль-ислах»







«Әл-ислах» газетасында басылган «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» хикәясеннән фрагментлар

Фрагменты рассказа «Изгнание Заки шакирда из медресе» на страницах газеты «Аль-ислах»

посещал городскую библиотеку, читал газеты и журналы, и когда в медресе образовалось движение против старых порядков, присоединился к нему. В 1905 году был изгнан из медресе за выступления против кадимистской системы образования. Позднее эти события он отразил в рассказе «Изгнание Заки шакирда из медресе» (1907).

Рассказ был опубликован в 1907 году в газете «Аль-ислах», литературное содержание которой формировал Фатих Амирхан. Современники обратили внимание на реалистичность рассказа, на доскональное, даже натуралистичное описание всех подробностей учебных порядков в кадимистских медресе [Фатих Әмирхан турында истәлекләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. 191 б.; Ибраһимов Г. Әсәрләр: 8 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. Т. 1: хикәяләр (1907–1929). 505 б.]. Рассказ превращает в объект насмешек внутренний распорядок кадимистских медресе, их учебные программы, порядок обучения, невежество, царившее здесь, грязь, отсталость; прослеживает, как Заки, способный, старательный,

тәртипләрен, уку-укыту программаларын, укыту рәвешен, мондагы наданлыкны, пычраклыкны, артталыкны көлү объекты ясый, укуга сәләтле, тырыш, тыйнак, тәрбияле мәхдүм Зәкинең усал, мәнсез, каты күңелле шәкерткә әверелү юлын тергезә. Алга таба Г. Ибраһимов прозасының «визит карточкасына» әвереләчәк детальләп сурәтләү алымы натуралистик төгәллек белән кадим мәдрәсәләрнең торгынлык оясы булуын, мондагы хәл-күренешләрнең кеше психологиясен, холкын гарипләндерүен тасвирларга ярдәм итә, шул рәвешле язучы кадим уку йортларының милли җәмгыятьне аяныч түбәнлектә тотуын ассызыклый. Очраклы рәвештә җәдит «Гыйльмия» мәдрәсәсенә эләгеп, Зәкинең татар мәктәп-мәдрәсәләрен үзгәртеп кору зарурлыгына төшенүе хикәядәге төп фикер булып формалаша. Халыкның милли үзаңын, җәмгыятьне үзгәртү юлын, милләтне яктылыкка чыгару мөмкинлеген Ибраһимовның җәдит уку-укыту системасы белән бәйләп караганлыгы турында сөйли. Гомумән алганда, хикәя



Галимҗан Ибраһимов.
ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 5. С. б. 21

Галимджан Ибрагимов.
ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 5. Ед. хр. 21





Г. Ибраһимовның энесе Габделхәким Ибраһимов һәм яшьлек дусты Габделләхәт Сөләйманов. ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 5. С. б. 50

Младший брат Г. Ибрагимова Габдельхаким со своим другом Габдельахатом Сулеймановым. ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 5. Ед. хр. 50

воспитанный, скромный ученик, превращается в жестокого шакирда. В дальнейшем превратившийся в визитную карточку прозы Г. Ибрагимова способ детального описания с натуралистической точностью воспроизводит быт старых медресе, подчеркивает, что эти очаги застоя калечат характер человека; таким образом писатель проводит мысль о том, что кадимистские учебные заведения держат национальное общество в печально низком положении. Случайное попадание в джадидистскую медресе «Гильмия», осознание Заки шакирдом необходимости реформ татарских школ и медресе – вот основная мысль рассказа. Развитие национального самосознания, изменение существующего общества, вывод нации к свету Ибрагимов напрямую связывал с джадидистской системой образования. В общем, мысль, высказанная Х. Вали в рецензии на рассказ в 1927 году, и сегодня актуальна: «“Заки шакирд...” в художественном отношении еще слаб, писатель в “Заки шакирде...” выступает еще не как мастер художественного слова, а как носитель

хакында 1927 елны Х. Вәлинең рецензиясендә әйтелгән бәя бүген дә кыйммәтен югалтмаган: «“Зәки шәкерт...”тә әле сәнгать ягы йомшак эшләнгән, әдип әле “Зәки шәкерт...” тә сәнгатьче булып түгел, фикерче булып күренә. Әсәр һәрнәрсәдән бигрәк фикергә бай. Ләкин әсәрдә фикерләр сурәт эченә салынып түгел, турыдан-туры фикер эчендә биреләләр. Әдип вакыйганы баштан алып аягына кадәр үз теле белән сөйли. Геройны бик аз урында үз теле белән сөйләтә. Күп урында аның фикерләрен әдип үзе үк әйтеп бирә» [Вәли Х. «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» (Г. Ибраһимовның беренче әсәре, 1907–1927) // Безнең юл. 1927. № 12. Б. 34–38]. Әмма шунысын да искәртергә кирәк, Ибраһимов-язучы бу үгет-нәсихәтчелектән, публицистлыктан бик тиз арына, чын мәгънәсендә сәнгатьлелек юлына баса.

Күрәсең, дөньяда барган хәлләр аның карашларын да, максатларын да ачыклый-төгәлләштерә: Галимҗан 1906 елда укуын дәвам итәр өчен Троицк шәһәренә юнәлә,



Х. Вәлинең «Безнең юл» журналында басылган рецензиясеннән фрагмент. 1927

Фрагмент рецензии Х. Вали на страницах журнала «Безнен юл». 1927





Х. Вәлинең «Безнең юл» журналында басылган рецензиясеннән фрагмент. 1927

Фрагмент рецензии Х. Вали на страницах журнала «Безнен юл». 1927

мнения, мысли. Произведение богато прежде всего с идейной точки зрения. Но в нем идеи переданы не при помощи образов, а напрямую. Писатель рассказывает событие от начала до конца своим языком. Герой мало где говорит сам. Во многих местах его мысли писатель высказывает сам» [Вәли Х. «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» (Г. Ибраһимовның беренче әсәре, 1907–1927) // Безнең юл. 1927. № 12. Б. 38]. Нужно отметить, писатель очень быстро избавился от такого назидательства, публицистичности, встал на истинный художественный путь.

Видимо, события, которые происходят в мире и стране, корректируют, проясняют мировоззрение и цели Г. Ибрагимова: в 1906 году с целью продолжения обучения он направляется в Троицк, но медресе Троицка произвели на него не очень благоприятное впечатление, и осенью он приехал в Уфу, устроился вольным слушателем в открытое Зией Камали медресе «Галия». В 1906–1908 годах он обучался там. Известно, что Ибрагимов принимал участие в издании

әмма андагы мәдрәсәләрне ошатмыйча, көз көне Уфага килеп, Зыя Камали ачкан «Галия» мәдрәсәсенә ирекле тыңлаучы булып урнаша, 1906–08 елларны шунда белем ала. Оештыручыларның берсе сыйфатында, мәдрәсәдә яшерен газета чыгаруда катнашуы мәгълүм. Мәҗит Гафури, Хәлим Искәндәров, Галә Ходаяров, Фәрзи Әхмәтов, Шәһит Әхмәдиевләр белән дуслашып китә, актив булуы, һәрчак үз фикерен кистереп әйтүе белән иптәшләре арасында да аерылып тора.

Мәдрәсәгә нигез салучы Зыя Камали (1873–1942) – татар җәдитчелек хәрәкәтендә иң билгеле фигуралардан. «Госмания» мәдрәсәсендә үзен сәләтле шәкерт итеп таныткан Зыяны хәйрия җәмгыяте Истанбулга укырга җибәрә. Соңрак ул Мәдинәдә, аннары – әл-Әзһар университетының философия факультетында белем ала, күренекле мөселман реформаторы Мөхәммәд Абдуның шәкерте була. Уфага кайткач, чит илләрдәге дини университетлар тибында югары белем бирә торган мәдрәсә булдыру идеясен тормышка



«Галия» мәдрәсәсе. Уфа. ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 5. С. б. 60
Медресе «Галия». Уфа. ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 5. Ед. хр. 60





«Галия» мәдрәсәсенең хәзерге күренеше. Уфа
Современный вид медресе «Галия». Уфа

подпольной газеты в качестве одного из организаторов. Подружился с Маджитом Гафури, Халимом Искандеровым, Гали Худаяровым, Фарзи Ахметовым, Шахитом Ахмадиевым, выделялся даже среди друзей активностью, прямотой, с которой он высказывал свое мнение.

Основатель медресе «Галия» Зия Камали (1873–1942) – одна из известных фигур татарского джадидистского движения. Шакирда Зию, который зарекомендовал себя как способный ученик медресе «Гусмания», благотворительное общество отправило учиться в Стамбул. Позже он учился в Медине, затем на философском факультете университета Аль-Азгар, был учеником знаменитого мусульманского реформатора Мухаммеда Абдо. По возвращении в Уфу стал воплощать в жизнь свои планы относительно устройства здесь высшего медресе по типу зарубежных религиозных университетов. Но для открытия и работы такого учебного заведения нужны и время, и сильный педагогический состав. В первые годы медресе переживает период становления, в то

ашыра башлый. Әмма мондый уку йортын аякка бастыру өчен вакыт та, көчле мөгаллимнәр дә кирәк. Беренче елларда мәдрәсә әле оешу чорын гына кичерә. Шул ук вакытта Зыя Камали идеяләре белән рухланып төрле җирләрдән җыйналган көчле, фикерле шәкертләр «Галия»дән күпне өмет итә. Әмма укытучыларның зур күпчелеге аларның ихтыяҗларына җавап бирерлек белемле булып чыкмый. Моннан тыш, Зыя Камали укыту программаларын дин әһелләре әзерләү юнәлешендә төзи, фәкать фәнни лекцияләр укуга гына йөз тота. Татар җәмгыятендәге җәдитчелек хәрәкәте тәэсирендә, шәкертләр расписаниеләргә дөньяви фәннәр кертүне таләп итәләр.

Бу мәсьәләләр Г. Ибраһимовның 1907 елны (17 декабрь, 11 сан) Ф. Әмирхан җитәкләгән «Әл-ислах» газетасында басылып чыккан «Уфа мәдрәсәләре» мәкаләсендә дә бик ачык чагыла. Биредә шәкертләрнең 1907 елның ноябренә кадәр иске, тар һәм караңгы бинада яшәүләре (махсус төзелгән яңа бинага 1907 ел ахырында гына күчелә)



Зыя Камали (1873–1942)

Зия Камали (1873–1942)





Г. Ибраһимов Шакирҗан Ибраһимов һәм Шәһит Әхмәдиев белән. 1910. ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 5. С. б. 32

Г. Ибрагимов с Шакирджаном Ибрагимовым и Шахитом Ахмадиевым. 1910. ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 5. Ед. хр. 32

же время сильные, вдумчивые шакирды, собравшиеся здесь, одухотворенные идеями Зии Камали, ожидали от «Галии» очень много. А большинство учителей пока не имеют такой подготовки, чтобы отвечать их требованиям. Кроме того, Зия Камали выстроил учебные программы в направлении подготовки духовных служащих, намереваясь преподавать только религиозно-научные лекции. Под действием джадидистского движения, распространенного в татарском обществе, шакирды требуют включения в расписание и светских дисциплин.

Эти вопросы хорошо отражены в статье Г. Ибрагимова «Уфимские медресе», опубликованной в № 11 от 17 декабря газеты «Аль-ислах», которой руководил Ф. Амирхан. Здесь указано, что шакирды до ноября 1907 года ютились в старом, темном и тесном здании (в специально выстроенное для медресе «Галия» новое здание переехали только в конце 1907 года), медресе называется в числе передовых по уровню преподаваемого религиозного образования: «В этом медресе духовные знания представлены на современном уровне

әйтелә, мәдрәсә дини белемнәр бирү ягыннан алдынгы дип бәяләнә: «Бу мәдрәсәдә голүме диния заманага муафикъ вә файдалы рәвештә тәгълим ителә. Фәлсәфәи диния вә тәфсир дәресләре башка һичбер татар мәдрәсәләрендә күрелмәгән дәрәҗәдә укыла дисәк, мөбалага булмаз, бу дәресләр хәкыйкать тә яхшы укыла. Шулай ук гарәбият вә әдәбияты да яхшы укыла» [Ибраһимов Г. Уфа мәдрәсәләре // Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. Т. 6: публицистика (1907–1932). Б. 7]. Галимҗанны фәнни предметлар, дөньяви предметлар укытылу сыйфаты канәгатьләндерми. Язма «татар милләте хәзерге көндә һәр җәһәттән мөкәммәл итеп бер мәдрәсә тәэсис итәрлек дәрәҗәгә килмәгән әле» дигән фикер белән төгәлләнә. 1908 елны шул ук газетада (10 июнь, 33 сан) дөнья күргән шактый күләмле «Шәкертләр аһ-зары» мәкаләсе Ибраһимовның мәдрәсә белемнәренә кагылышлы уй-фикерләрен тагын да ачыклый төшә. Бер шәкертнең сөйләве кебек язылган бу текстта 20 ел искечә дә, яңача да



Г. Ибраһимов
Шәһит Әхмәдиев белән.
ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 5. С. б. 47

Г. Ибрагимов
с Шахитом Ахмадиевым.
ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 5. Ед. хр. 47





Мәҗит Гафури
(1880–1934)

Маджит Гафури
(1880–1934)

и весьма полезно. Если скажем, что религиозная философия и толкование преподаются на таком уровне, что другим татарским медресе и не снилось, то ничуть не ошибемся. Также хорошо поставлено обучение арабскому языку и литературе» [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Сигез томда. Т. 6: публицистика (1907–1932). Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. Б. 7]. Галимджана не устраивает уровень преподавания общеобразовательных предметов, светских дисциплин. Статья завершается мыслью, что татарская нация еще не дошла до такого уровня, чтобы открыть, основать медресе, совершенное во всех отношениях. Статья «Жалобы шакирдов», опубликованная в той же газете в 1908 году (№ 33 от 10 июня), еще более раскрывает мнение Ибрагимова о качестве образования в медресе. В этом тексте, поданном как рассказ одного шакирда, герой рассказывает о том, что, несмотря на то, что в течение 20 лет учился и по-старому, и по-новому, у него нет профессии, что он не готов нигде работать и зарабатывать деньги. С такими знаниями можно работать муллой либо преподавателем, но

белем алган шәкерт үзенең һөнәрсез булуын, беркайда да эшләргә һәм акча табарга әзер түгеллеген бәян итә. Мондый белемнәр белән мулла яки мөгаллим булып гомер итәргә була, әмма аларны халык, белеменә карап түгел, кем баласы булуын күздә тотып сайлый. Шәкерт авызыннан мәкалә авторы: «Кашки берничә ел русча укысам, һич булмаса язучы яки учитель булып, һәм халыкка, һәм үземә хезмәт итәр идем» дигән сүзләр әйттерә, үз исеменнән милләткә эндәшеп, мондый нәтиҗә ясый: «Хәзерге укулар, укучылар, милләт сиңа тереклек, яшәү бирә торган түгел. Өмид итмә! Алданма! Терек булырга, тереклек сугышында җиңелеп, югалып китмәскә теләсәң, уку-укыту эшене тереклек бирә торган юлга сал» [Ибраһимов Г. Шәкертләр аһ-зары // Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. Т. 6: публицистика (1907–1932). Б. 12–13].

1915 елны «Аң» журналында басылган истәлекләрендә Г. Ибраһимов үзенең шәкертләрне мәдрәсә тормышын камилләштерү кирәклеге хакында Зыя Камалига хат



Әхмәтгәрәй Хәсәни – «Аң» журналы мөхәррире

Ахметгирей Хасани – редактор журнала «Анг»





«Аң» журналы

Журнал «Анг»

их народ выбирает не по уровню образования, а по тому, кем они приходятся влиятельным персонам. Автор статьи устами шакирда говорит, что «если бы учился хотя бы несколько лет по-русски, то мог хотя бы стать литератором или учителем и служить и народу, и себе». Уже от своего имени обращаясь к нации, автор делает вывод: «Нация, нынешнее образование, ученики не могут дать тебе способность жить. Не надейся! Не обманывайся! Если хочешь жить, быть живым, не исчезнуть в войне повседневности, образование направь на живое русло» [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 6: публицистика (1907–1932). Б. 12–13].

В воспоминаниях, опубликованных в 1915 году в журнале «Анг», Г. Ибрагимов говорит о том, что призывал шакирдов составить официальное письмо Зие Камали о необходимости усовершенствования жизни медресе, организовал движение шакирдов [Ибраһимов Г. «Мәдрәсәи Галия вакыйгасы» хакында берничә сүз // Аң. 1915. № 20. Б. 354]. Действительно, помаленьку порядки

язарга өндәве, шәкертләр хәрәкәте оештыруы хакында әйтә [Ибраһимов Г. «Мәдрәсәи Галия вакыйгасы» хакында берничә сүз // Аң. 1915. № 20. 54 б.]. Чыннан да, акрынлап «Галия»дәге тәртипләргә дә үзгәрешләр керә. 1929 елны язылган «Автобиография»сендә Г. Ибраһимов мәдрәсәдән китү сәбәпләрен болай күрсәтә: «Биредә өч елга якын укыдым, ләкин аннан да куылдым; беренчедән, укыту программасын һәм системасын тәнкыйтьләгән өчен, икенчедән, еш кына мәдрәсә идарәсенә каршы чыгып сөйләүләрем өчен һәм, өченчедән, мәдрәсә шәкерте була торып, «Коръән Алладанмы, түгелме?» дигән китап язган өчен» [Галимҗан Ибраһимов. Әсәрләр: тугыз томда. Казан, 2000. Т. 9: хатлар һәм документлар: төз. Ф. Ибраһимова. Б. 17]. Ибраһимовның 1908 елда (31 август, 43 сан) «Әл-ислах» газетасында басылып чыккан «Уфа йоклый» мәкаләсендә исә яшь егетне шәһәрдәге иҗтимагый-мәдәни тормышның сүлпән булуы да канәгатьләндермәү билгеләнә.



Г. Ибраһимов автобиографиясен төзүгә әзерләнгән документларның күчермәләре.

ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 2. С. б. 8

Копии документов, подготовленных для составления автобиографии Г. Ибрагимова. ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 2. Ед. хр. 8





Г. Ибраһимов автобиографиясен төзүгә әзерләнгән документларның күчермәләре.

ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 2. С. б. 8

Копии документов, подготовленных для составления автобиографии Г. Ибрагимова. ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 2. Ед. хр. 8

в медресе «Галия» начинают меняться. В написанной в 1929 году автобиографии в числе причин, вынудивших его покинуть медресе, Г. Ибрагимов называет следующие: «Я учился здесь около трех лет, но и отсюда был изгнан; во-первых, потому что критиковал учебную программу и систему обучения; во-вторых, частенько выступал против руководства медресе; и, в-третьих, будучи шакирдом медресе, написал книгу «Коран от Аллаха или нет?» [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Тугыз томда. Т. 9: хатлар һәм документлар / төз. Ф. Ибраһимова. Казан, 2000. Б. 17]. В статье Г. Ибрагимова «Уфа спит», опубликованной в газете «Аль-ислах» в 1908 году (№ 43 от 31 августа), заметно также, что юношу не устраивала вялая общественно-культурная жизнь в городе.

Проба пера этого периода показывает, что душа молодого человека, переживающая этап духовного становления, ищет опорные точки для дальнейшего возрождения татарского общества. В 1909 году он опубликовал в

Бу чордагы каләм сынаулары егетнең рухи чыныгу-формалашу чоры кичергән күңеле татар җәмгыятендәге киләчәк яңарыш өчен таяныр нигезләр эзләгәнне күрсәтә. 1909 елны ул Оренбургта «Борынгы ислам мәдәнияте» дигән хезмәт бастырып чыгара. Һәм шәрык, һәм гареб галимнәренең (гарәп галиме Җөрҗи Зәйдан һәм француз галиме Гюстав Лебон) хезмәтләрен файдаланып гарәп мәдәниятендәге кискен үсеш-үзгәрешләрне ачкан-аңлаткан әлеге китапчыкта Ибраһимов ислам диненең урта гасырларда күп халыклар мәдәни сикереше өчен нигез булуын дәлилләр китереп исбатлый. Шушы ук елны «Коръән Алладанмы, түгелме?» дигән атеистик характерлы хезмәт язганлыгын үзе искә ала, әмма заманында күп шау-шу тудырган кульъязма безнең көннәргә килеп җитмәгән. Күрәсең, Галимҗан өчен дә XX йөз башы татар зыялыларын борчыган «Шәрыкме, Гаребме?» – милләт өчен рухи мәсләк, кыйбла табу, нинди кыйммәтләргә йөз тотып алга бару – мәсьәләсе иң мөһимнәрдән санала башлый. Ул дөрес карарлар кабул итү өчен



«Борынгы ислам мәдәнияте» китабы. 1909

Книга «Борынгы ислам мәдәнияте» («Древняя исламская культура»). 1909





«Борынгы ислам мәдәнияте» китабы. 1909

Книга «Борынгы ислам мәдәнияте» («Древняя исламская культура»). 1909

Оренбурге труд «Культура древнего ислама». Опираясь на труды как западных, так и восточных исследователей (арабского ученого Джирджи Зайдана и французского ученого Гюстава Лебона), Ибрагимов раскрывает суть резких изменений в арабской культуре, доказывает, что со Средневековья ислам стал для многих народов основой для культурного ренессанса. В том же году упомянул о том, что написал атеистического характера работу «Коран от Аллаха или нет?», но рукопись вызвавшего в свое время немалый шум труда до наших дней не сохранилась. Видимо, и для Галимджана стал актуален вопрос, мучивший татарскую интеллигенцию в начале XX века: Восток или Запад? На какие ценности нужно ориентироваться татарскому народу при дальнейшем развитии? Где тот духовный ориентир? Где Мекка татарской культуры? Для принятия взвешенных решений необходимо учиться, получить основательное образование. И Галимджан приходит к мысли, что нужно приехать в Казань, попробовать

укырга, төпле белем алырга кирәклегенә төшенә, Казанга килеп университетка яки башка рус югары уку йортына керү уена килә.

Г. Ибраһимов берникадәр вакыт казакъ далаларында, Уралда Миас заводында төрле эшләрдә йөри, Әстерханның нугай татарлары арасында һәм Казакъстанда мөгаллимлек итә [Галимҗан Ибраһимов: хатлар һәм документлар: төз. Ф. Ибраһимова. Казан, 2000. Б. 19]. 1909 елның ахырында, университетта уку теләге белән, Казанга килә.

Әмма университетка керү өчен әзерлек зур матди чыгымнар сорый, гимназия программасы буенча хосусый укытучылардан дәресләр алып, имтиханнар тапшырырга кирәк була. Бу хакта югарыда телгә алынган «Автобиография»дә Г. Ибраһимов болай яза: «Казанга күчеп килеп, университетка яисә педагогия институтына керер өчен әзерләнә башладым (1909–1910). Ләкин моңа ике каршылык туды. Беренчедән, махсус программа буенча системалы рәвештә укыр өчен бер төрле дә мөмкинлегем юк иде; икенчедән,



Казакълар тормышыннан бер күренеш
Из жизни казахов





Казан шәһәре күренеше. XX йөз башы
Вид города Казани. Начало XX века

поступить в университет либо другое русское учебное заведение.

Некоторое время Галимджан живет в казахских степях, работает на миасских заводах Урала, учительствует среди астраханских татар и в Казахстане [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 9: хатлар һәм документлар. Б. 19]. В Казань он приехал в конце 1909 года.

Подготовка к поступлению в университет требует больших материальных затрат, нужно брать уроки по программе гимназии у частного педагога и сдать экзамены. Об этом Г. Ибрагимов пишет в упомянутой выше «Автобиографии» так: «Переехав в Казань, начал готовиться к поступлению в университет либо педагогический институт (1909–1910). Но на пути встали два препятствия. Во-первых, для систематического обучения по специальной программе у меня не было возможности; во-вторых, и, это самое главное, я считался политически не благонадежным. Таким людям, тем более нерусским

бусы иң әһәмиятлесе, мин политик яктан ышанычсыз кеше булып санала идем. Андый кешеләргә, бигрәк тә рус-христиан булмаганнарга, югары мәктәп ишекләре ябык иде.

Шуның аркасында мин югары мәктәпкә керү фикеремнән кайтырга мәҗбүр булдым һәм, бөтен көчемне биреп, үзлегемнән белемемне арттыру эшенә керештем. Яшәрлек акча табу өчен, дәресләр бирдем, әдәби темаларга язган мәкаләләремне газеталарда, журналларда бастырдым» [Галимҗан Ибраһимов: хатлар һәм документлар. Б. 17–18].

Казанга килгәндә Г. Ибраһимовның татар җәмәгатьчелеге арасында шактый танылган булуын да игътибардан читтә калдырырга ярамый. 1907 елның ахырында «Әл-ислах» газетасында Ибраһимовның «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» хикәясе укучыга тәкъдим ителә, ул бигрәк тә шәкертләр, яшьләр арасында зур шау-шу тудыра. Соңрак язылган «Автобиография»ләрендә Г. Ибраһимов үзенең шушы газета һәм татар вакытлы матбугаты белән хезмәттәшлеген әлеге факттан башлап җибәрә. Озак та



Әхмәтгәрәй Хәсәни
(1883–1934)
Ахметгирей Хасани
(1883–1934)





Габдулла Тукай
(1886–1913)
Габдулла Тукай
(1886–1913)

и нехристианинам, двери высших учебных заведений были закрыты.

Из-за этого я вынужден был отказаться от мысли поступления в высшую школу и начал вкладывать все силы в самостоятельное обучение, в самообразование. На жизнь зарабатывал частными уроками, публикациями статей на литературные темы в газетах и журналах» [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 9: хатлар һәм документлар. Б. 17–18].

Нужно отметить, что ко времени переезда в Казань Г. Ибрагимов уже был достаточно известной личностью в татарском обществе. Рассказ «Изгнание Заки Шакирда из медресе» вызвал большой шум среди молодежи, особенно шакирдов. В автобиографиях, написанных позже, Г. Ибрагимов акцентирует внимание на том, что сотрудничество с татарской периодической печатью он начал именно с этого факта. Вскоре им уже написаны литературные произведения «Гыйшык корбаннары» («Жертвы любви», 1908), «Татар хатыны ниләр күрми» («Судьба татарки», первый

үтми, «Гыйшык корбаннары» (1908), «Татар хатыны ниләр күрми» (беренче варианты, 1909) исемле әдәби әсәрләре һәм «Борынгы ислам мәдәнияте» (1908–1909) дигән хезмәте языла. 1908 елны «Әл-ислах» газетасында татар мәдрәсәләрендә уку-укытуның торышына кагылышлы берничә шактый кискен эчтәлекле мәкаләләре басылып чыга. Шуңа күрә Казанга килүгә, алдынгы фикерле, каләмле зыялыларның аралашу даирәсенә эләгә: Ф. Әмирхан, Ә. Хәсәни, Г. Тукай, Г. Камал, Хәнәфи Кайбышев һ.б.лар белән дуслаша, татар тормышының төрле якларына кагылышлы публицистик язмалары белән газеталарда чыгышлар ясый.

Каләмнең тәэсир көчен, язу-тасвирлауның куәсен аңлап алган Галимҗан үз стилен, үз сурәтләү юлын табарга омтыла. «Гыйшык корбаннары» (1908) хикәясе, «Татар хатыны ниләр күрми» (1909) повесте кешенең шәхси бәхеткә ирешүен һәм мәхәббәт өчен көрәшүен алгы планга чыгара. Язучы актив, җәмгыятьтә кабул ителгән тәртипләр, иске гореф-гадәтләр белән килешмичә, үз



Фатих Әмирхан
(1886–1926)
Фатих Амирхан
(1886–1926)





Галиәсгар Камал
(1879–1933)
Галиасгар Камал
(1879–1933)

вариант, 1909), научно-публицистические труды. Поэтому сразу же по приезду в Казань он оказался в среде передовой и пишущей интеллигенции: подружился с Ф. Амирханом, А. Хасани, Г. Тукаем, Г. Камалом, Ханафи Кайбышевым и др., регулярно публиковал в газетах статьи, освещающие разные стороны жизни татарского общества.

Осознавший силу слова Галимджан стремился найти свой стиль, свою манеру письма. Рассказ «Жертвы любви» (1908), повесть «Судьба татарки» (1909) на первый план выводят борьбу человека за личное счастье, за любовь. Писатель рисует героев активных, не согласных со старыми порядками, традициями, принятыми в обществе, стремящихся выстроить свою жизнь на новых основаниях, начать с нового пути (герои рассказа Сагид и Галима – сын богача и дочь бедняка, несмотря на социальное неравенство, боролись за свою любовь; героиня повести Гульбану сбежала из родного дома и в мужском обличье странствовала по стране). Даже если они не смогли достичь желанного

тормышын башка юлдан җибәрергә омтылган геройлар тудыра (хикәя геройлары Сәгыйд һәм Галимә – бай улы һәм ярлы кызы – мондый тигезсезлеккә карамыйча, мәхәббәтләре өчен көрәшә; повесть героинясы Гөлбану туган йортыннан кача һәм ирләр кыяфәтендә ил гизеп йөри башлый). Алар бәхеткә ирешә алмасалар да, әсәрләрдәге «гыйсъянчылык чаткылары» [Бәширов Ф. XX йөз башы татар прозасы. Казан: Фикер, 2002. Б. 187] һәр кешенең хөр рухын, бәхеткә омтылышын яшәештәге олы кыйммәт итеп күтәрә. Шушы үзенчәлек алга таба Г. Ибраһимовның романтик иҗатында лейтмотив булып сузыла, бу иҗат, үз чиратында, татар әдәбиятында романтик метод урнашуга йогынты ясый. Язучының романтик әсәрләрендә «шәхеснең югары күтәрелүе милләтнең, халыкның югары күтәрелүен аңлата: геройның көндәлек тормыш ваклыкларыннан өстен хисләре кичерешләрнең яңа бер дөньясын хасил итә, татар милләтенең уянып килүче милли үзаңын гәүдәләндерә» [Нигматуллина Ю.Г. Национальное



Галимҗан Ибраһимов.
ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 5. С. б. 25

Галимджан Ибрагимов.
ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 5. Ед. хр. 25





«Татар хатыныниләр күрми» спектакленнән күренеш

Сцена из спектакля «Татар хатыны ниләр күрми» («Судьба татарки»)

счастья, «искры бунтарства» [Бәширов Ф. XX йөз башы татар прозасы. Казан: Фикер, 2002. Б. 187], выраженные в произведениях, провозглашают высшей ценностью свободный дух человека, его стремление к счастью. Эта особенность в дальнейшем стала лейтмотивом романтического творчества Г. Ибрагимова, которое, в свою очередь, повлияло на становление романтического метода в татарской литературе. «В романтических произведениях Г. Ибрагимова “апофеоз” личности означает апофеоз нации, народа; “страсти” героя, возвышающие его над будничной, прозаической действительностью, составляют новый мир чувств, пробуждающееся самосознание татарского народа» [Нигматуллина Ю.Г. Национальное своеобразие эстетического идеала. Казань: Изд-во КГУ, 1970. С. 71].

Эти произведения свидетельствуют о том, что писатель – мастер в описании природных явлений и с удовольствием обращается к приемам психологизма. Особенно в повести ярко выражено стремление автора показать красоту

своеобразие эстетического идеала. Казань: Изд-во КГУ, 1970. С. 71].

Әлеге әсәрләр язучының психологизм алымнарына бик теләп мөрәҗәгать итә башлавы, табигатьне тасвирлау осталыгы хакында сөйли. Бигрәк тә повестьта татар һәм башкорт халыкларының гореф-гадәтләренә, йолаларына, этнографик үзенчәлекләренә (әйтик, чәчү-игү эшләре белән бәйле өмәләргә, тула, каз өмәләренә, аулак өйләргә) киң урын бирелеп, милли яшәештәге матурлыкны барлау омтылышы ачык күренә. Бу сыйфатлар алга таба әдипнең күпсанлы хикәяләрендә дәвам итә.

«Татар хатыны ниләр күрми» повесте әдипнең һәм шәрык, һәм гареб әдәбиятлары традицияләрен бер әсәр эчендә үреп җибәрү осталыгын күрсәтә (шушы сыйфат XX гасыр башында мәйданга чыккан татар романтик әдәбиятының төп сыйфатларыннан санала). Шәркый романтизм алымнары, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар тормышын, көнкүрешен детальләп тасвирлау рус-европа



«Татар хатыны ниләр күрми» спектакленнән күренеш

Сцена из спектакля «Татар хатыны ниләр күрми» («Судьба татарки»)





«Татар хатыны ниләр күрми» спектакленнән күренеш

Сцена из спектакля «Татар хатыны ниләр күрми» («Судьба татарки»)

повседневной жизни татарского и башкирского народов через традиции, обряды и обычаи этнографических особенностей (к примеру, помочи, связанные с полевыми работами, с коллективными видами труда, посиделки и др.). Эта манера продолжилась и в других многочисленных рассказах писателя.

Повесть «Судьба татарки» показывает мастерство писателя в синтезе как восточных, так и западных литературных традиций в одном произведении (эта особенность считается основной в татарской романтической литературе, вышедшей на арену в начале XX в.). Методы, способы восточного романтизма органично синтезированы с детальным описанием жизни и быта татар конца XIX – начала XX века, с мотивами русской и европейской литератур. С одной стороны, основой для произведения автор выбрал сюжет баита «Җиде кыз» («Семь девушек»), известный в тюрко-татарском мире [Минһаҗева Р.Ә. Галимҗан Ибраһимов иҗатында руссочыл традицияләр // Галимҗан Ибраһимовның иҗат дөньясында. Казан, 2012. Б. 302]. Внешняя обстановка в произведении,

әдәбиятларындагы мотивлар белән тоташып, табигый рәвештә кушылып бара. Бер яктан, язучы әсәренә җирлек итеп төрки-татар халкында мәгълүм «Җиде кыз» бәетенең сюжетын ала [Минһаҗева Р.Ә. Галимҗан Ибраһимов иҗатында руссочыл традицияләр // Галимҗан Ибраһимовның иҗат дөньясында. Казан, 2012. Б. 302]. Әсәрдәге тышкы тирәлек, геройлар бирелеше, Гөлбануның вакыт ягыннан балачагын, үсмерчагын, килен чагын, Габдулла булып яшәгән елларын колачлаган тормыш-көнитеш – бар да татар тормышыннан күчереп куйган кебек. Төп сюжет хәрәкәтен барлыкка китергән гамәл – кызның әтисе Нурый картның аны 25 чакрым ераклыктагы Курайлы авылына, Зариф байның улы Закирга кияүгә бирергә карар кылуы – татар җәмгыяте өчен гадәти, элеккедән килгән, традицион бер гадәт. Аның зарарын, фаҗигаләргә сәбәп булуын күрсәтер өчен язучы сюжет композициясен рус-европа әдәбиятларында актив кулланыла башлаган мифологик мотив – «мәңгелек әйләнеп кайту» мотивы рәвешендә кора.



«Татар хатыны ниләр күрми» спектакленнән күренеш

Сцена из спектакля «Татар хатыны ниләр күрми» («Судьба татарки»)





«Татар хатыны ниләр күрми» спектакленнән күренеш

Сцена из спектакля «Татар хатыны ниләр күрми» («Судьба татарки»)

описание героев, детство, юность Гульбану, время, когда она была молодой невесткой, годы жизни в обличье Габдуллы – все это будто перенесено с татарской действительности. Основное действие, вызвавшее развитие сюжета, – решение отца девушки, Нури, выдать против ее воли замуж за Закира, сына богача Зарифа, в деревню Курайлы в 25 верстах от родного дома – обыденное явление в татарском обществе, традиционное. Чтобы показать вред такого обычая, подчеркнуть то, что это может стать причиной трагедии, писатель выстраивает сюжетную композицию вокруг мифологического мотива «вечного возвращения», активно использующегося в русской и европейской литературах. Таким образом, в произведении появляется философия естественности, естественного человека, который противостоит бессмысленным канонам, придуманным людьми. Этот слой в произведении группируется вокруг Гульбану.

Гульбану с детства была умной, смышленой, красивой и старательной девочкой, росла любимой дочерью матери

Шулай әсәргә гареб әдәбиятларында киң кулланыла торган табигый кеше, табигыйлек фәлсәфәсе килеп керә, һәм ул кешеләр уйлап тапкан мәгънәсез кануннарга каршы куела. Әсәрдәге бу катлам Гөлбану образы тирәсенә җыела.

Балачак-үсмерчактан Гөлбану акыллы, матур, уңган кыз, әнисе Фәтхиянең кадерле баласы булып үсә. Аның төп хыялы – яраткан кешесенә кияүгә чыгып, матур гаилә кору, бәхетле яшәү. Эчкече һәм тупас Закир белән яшәү дә, аннан качып китеп, башкорт бае карт Солтанга хатын булу мәҗбүрияте дә, әлеге бай караклар кулыннан үлгәч, аның 11 яшьлек энесенә никахлану да Гөлбануны бәхетле итә алмый. Язучы сайлау ирегеннән мәхрүм хатын-кызның бәхетле була алмавын өч гаилә моделе мисалында күрсәтә. Сәнгать кануннары буенча, өч тапкыр кабатлану циклны тәгәлли. Димәк, хатын-кыз булып яшәгәндә Гөлбануга (иске тәртипләр белән яшәгәндә – татар җәмгыятенә!) үз язмышын үзгәртергә мөмкинлек юк! Ирләр сафына басудан башка чара калмый. Язучы героинясын, чәчен кистереп,



«Татар хатыны ниләр күрми» спектакленнән күренеш

Сцена из спектакля «Татар хатыны ниләр күрми» («Судьба татарки»)





«Татар хатыны ниләр күрми» спектакленнән күренеш

Сцена из спектакля «Татар хатыны ниләр күрми» («Судьба татарки»)

Фатхии. Ее главная мечта – создать семью с любимым человеком и жить в счастье. Жизнь с грубым пьяницей Закиром, затем, после побега из дома, необходимость быть женой пожилого башкирского богача Султана; после смерти Султана от рук воров, замужество за его 11-летнего брата – ничего из этого не может дать Гульбану счастье. Писатель на примере трех моделей семьи показывает, что женщина, лишенная возможности выбора, несчастна. По канонам искусства цикл завершает трехкратное повторение. Значит, у Гульбану нет возможности для изменения своей жизни при жизни в татарском обществе по старым порядкам. Нет другого пути, кроме как «стать мужчиной». Писатель превращает героиню в Габдуллу, обрезав волосы и сменив одежду. Это настолько противоестественное превращение, что автор подчеркивает, что это принимается Гульбану как большой подвиг: «Она изумлена, осознав себя, и то, что сделала. Даже не верится… может, это сон? Или мечта…» [Ибраһимов Г. Татар хатыны ниләр күрми (Роман. Беренче басма) // Ми-

киемен алыштырып, Габдуллага әйләндерә. Бу шулкадәр гайре табигый әверелеш була, автор моның Гөлбану тарафыннан зур батырлык кебек кабул ителүен ассызыклый: «Ул үзен һәм башлаган фәүкыльгадә эшен аңлап, хәйран калмыш иде. Ышанасы килми... әллә бу төшемме? Әллә хыялмы ... дидер иде» [Ибраһимов Г. Татар хатыны ниләр күрми (Роман. Беренче басма) // Мирас. 2003. № 5. Б. 132]. Символик планда бу адым татар хатын-кызларын азат итүнең бердәнбер юлы – ирләр белән тигез сафка басу, аларның яшәү рәвешен өлге итеп алу кебек аңлашыла.

Ләкин Гөлбануның холкы-психологиясе Габдулла булып яшәүдән дә бәхет таба алмый: язучы аны туган өенә юнәлтә, монда хакыйкать ачылып, Гөлбану үз дөньясына, үз табигый көнитешенә әйләнеп кайта. Мифологик «әйләнеп кайту» мотивы кеше үз табигый тормышы белән яшәргә тиешлеген ассызыклый: татар хатын-кызы, хатын-кыз булып калган хәлдә, ирләр хокукларына ия булырга тиешлеккә игътибар юнәлтә. Татар хатынын гаилә корганда сайлау



«Татар хатыны ниләр күрми» спектакленнән күренеш
Сцена из спектакля «Судьба татарки»





«Татар хатыны ниләр күрми» спектакленнән күренеш
Сцена из спектакля «Судьба татарки»

рас. 2003. № 5. Б. 132]. В символическом плане это действие можно объяснить тем, что единственный путь освобождения татарской женщины – стать наравне с мужчинами, взять их порядок жизни как образец.

Все же характер Гульбану таков, что она не может найти счастье и в жизни в обличье Габдуллы: писатель возвращает ее в родной дом. Здесь открывается правда и Гульбану возвращается в свой мир, свою естественную жизнь. Мифологический мотив «вечного возвращения» подчеркивает то, что человек должен жить своей естественной жизнью; обращает внимание читателей на то, что татарская женщина, оставаясь женщиной, должна получить права наравне с мужчинами. Лишать татарскую женщину свободы выбора при создании семьи – противоестественно, это ошибочная традиция. Каноны, правила, придуманные кем-то, становятся препятствием счастью человека, приводят к трагическим последствиям. То, что Гульбану смогла немного вкусить свободы только в мужском обличье, смогла вернуться назад,

ирегеннән мәхрүм итү – гайре табигый, ялгыш гадәт буларак каралып, кемнәрдер уйлап тапкан канун-кагыйдәләрнең бәхеткә-сәгадәткә киртә коруы, фаҗигаләргә китерүе хакындагы фикерне ныгыта. Гөлбануның бары тик ир кешегә «әверелеп» кенә күпмедер ирекккә чыгуы, үз асылына кайта алуы әлеге иске тәртипләрнең җәмгыятькә бик нык-лап урнашкан булуын, шәхес ирегенә, димәк, милләт ирегенә буучыга, аның үсешен тоткарлаучыга әйләнүен сөйли.

«Яшьләр хәятыннан бер ләүхә» (1909) хикәясе Г. Ибраһимовның әдәби иҗатында өйрәнчек чор тәмамланганны хәбәр итә. Сюжет Сәлим исемле яшь егетнең Әстерханнан өч тапкыр Казанга килүен колачлый. Беренче килүе 1901 елда була, бу вакытта Сәлим – милләтне яратучы, бөтен барлыгын, тормышын милләт өчен корбан итәргә әзер «ялкынлы милли идеяле яшь бер адәм». Берничә ел үткәч Казанга килгәндә, «ул, тар «милләтчелек» даирәсеннән чыгып, «инсаният даирәсенә» күчкән, милләтчелекне ташлап, инсаниятче булган, «милләтем... татарым...»ны




«Яшьләр хәятыннан бер ләүхә» китабы тышлыгы. 1911

Обложка книги «Яшьләр хәятыннан бер ләүхә» («Из жизни молодежи»). 1911






«Яшьләр хәятыннан бер ләүхә» китабының титул бите. 1911

Титульная страница книги «Яшьләр хәятыннан бер ләүхә» («Из жизни молодежи»). 1911

к своей женской сути, показывает, что эти старые порядки глубоко укоренены в татарском обществе, превратились в силы, ограничивающие свободу, развитие личности, а значит, и нации.

Рассказ «Яшьләр хәятыннан бер ләүхә» («Из жизни молодежи», 1909) сигнализирует о завершении этапа ученичества в творчестве Г. Ибрагимова. Сюжет охватывает трехкратный приезд молодого человека из Астрахани в Казань. Первый приезд был в 1901 году, в это время Салим – патриот своего народа, пламенный защитник интересов нации, готовый жизнь положить ради своего народа. Через несколько лет во время приезда в Казань он уже прошел этап «узкого патриотизма», стал патриотом всего человечества, отбросив идеи «народ мой, татары», стал проповедовать идеи «родина моя – вся земля; народ мой – все человечество» [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 1: хикәяләр (1907–1929). Б. 481]. К третьему приезду герой отбросил и эти идеи, предстал перед читателями человеком, который заботится прежде

ташлап, «ватаным – бөтен җир йөзе... милләтем – бөтен бәни бәшәр» нәзариясенә иман китергән иде» [Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. Т. 1: хикәяләр (1907–1929). Б. 481]. Өченче килүендә герой бу фикерләреннән дә ваз кичкән, шәхси мәнфәгатьләрен («үзенең генә сәгадәте өчен тырышып, мал, байлык, гаилә вә гүзәл тормыш артыннан йөрүне» [Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. Т. 1: хикәяләр (1907–1929). Б. 483]) кайгыртучы, үзенең тормышын көйләү өчен, университетка укырга керергә теләүче булып күренә. Сәлимнең өч заманда уйлаган уй-фикерләре автор тарафыннан җентекле күзәтелә, әйтерсең лә татар җәмгыятендәге яшьләрнең өч тибы тергезелә, бәянлә, аларның фәлсәфи позицияләре ачыклана.

Әсәр ахырында Сәлим яңадан рухи үзгәреш кичерә: үзенең милләтче вакытын сагына, шул чакларын кайтарып алу хакында хыяллана. Автор аның өчен мәхәббәтнең билгеле бер идеягә, максатка хезмәт итү, яшәү мәгънәсе булуын ассызыклый. Шулай язучы Сәлим образында инкыйлаб һәм



«Яшьләр хәятыннан бер ләүхә» китабыннан фрагмент. 1911

Фрагмент книги «Яшьләр хәятыннан бер ләүхә» («Из жизни молодежи»). 1911





«Яшьләр хәятыннан бер ләүхә» китабыннан фрагмент. 1911

Фрагмент книги «Яшьләр хәятыннан бер ләүхә» («Из жизни молодежи»). 1911

всего о своих личных интересах, чтобы наладить жизнь, хочет поступить в университет [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 1: хикәяләр (1907–1929). Б. 483]. Мысли, чувства Салима во время трех его приездов в Казань внимательно изучаются писателем, будто здесь вырисовываются три типа представителей татарской молодежи, они оцениваются, раскрываются их философские позиции.

В конце произведения Салим вновь переживает духовный подъем, скучает по временам, когда был патриотом своего народа, мечтает вернуть то время хоть ненадолго. Автор подчеркивает, что для Салима любовь – это служение определенной идее, цели, смысл жизни. В образе Салима сконцентрированно выражено развитие мысли молодых представителей татарской интеллигенции, автор выводит на литературную арену своего современника, его духовные искания, беспокойства, колебания.

С января 1910 года Г. Ибрагимов активно сотрудничает с газетой «Йолдыз». Одна группа его публикаций

аннан соңгы елларда зыялы татар яшьләрендәге фикри үзгәрешләрне сурәтләү объекты ясый, үз заманы кешесен, аның рухи тынгысызлыгын, икеләнүләрен әдәбият мәйданына китерә.

1910 елның гыйнвареннан Г. Ибраһимов актив рәвештә «Йолдыз» газетасы белән хезмәттәшлек итә. Аның бер төркем язмалары татар җәмгыятендәге яңарышның төрле мәсьәләләрен көн тәртибенә куя. Икенче төркем язмалары әдәбият белеме һәм милли әдәбиятка кагыла.

Беренче төркем мәкаләләре тәнкыйди характерда: гомумән татар җәмгыятенең хәл-халәтендәге, мәдәни тормышындагы артталык галәмәтләре дә («Фикердә инкыйлаб», «Галлей киткәннән соң», «Нәүмид», «Рәссамлык», «Тәрҗемә һәм аның шартлары»), үзе йөреп кайткан Әстерхан, Саратов төбәгендәге татарларның яшәеше, көнитеше, мондагы кайбер күренешләр («Әстерханнан», «Нугай туе», «Мөтәнәбби йә мөтәмәһһед»), көлеп тә, ачынып та, бәян ителә.



«Йолдыз» газетасы
Газета «Йолдыз»





Һади Максуди – «Йолдыз» газетасының мөхәррире
Хади Максуди – редактор газеты «Йолдыз»

актуализировала разные вопросы возрождения, обновления татарского общества, другая – касается вопросов литературоведения и национальной литературы.

В статьях критического характера отражены факты отсталости в культуре и в целом в жизни татарского общества («Фикердә инкыйлаб», «Галлей киткәннән соң», «Нәүмид», «Рәссамлык», «Тәрҗемә һәм аның шартлары»); быт, некоторые явления из жизни татар Астраханского, Саратовского регионов, где он сам побывал, описаны со смехом и горечью одновременно («Әстерханнан», «Нугай туе», «Мөтәнәбби йә мөтәмәһһед»).

1910 год – время, когда Г. Ибрагимов серьезно начал заниматься историей татарской литературы, теорией литературы, критикой. Его публикации, представленные в газетах и журналах, ставят в центр внимания различные направления науки, литературы. Например, в статье, опубликованной в газете «Йолдыз» от 12 января 1910 года (№ 490), сделана попытка системно проследить за развитием татарской

1910 ел – Г. Ибраһимовның җитди рәвештә татар әдәбияты тарихы, теориясе, тәнкыйте белән шөгыльләнә башлау вакыты. Аның газета-журналларга тәкъдим ителгән язмаларында әдәбият фәненең төрле юнәлешләренә караган аерым мәсьәләләр игътибар үзәгенә алына. Мәсәлән, «Йолдыз»ның 1910 елгы 12 гыйнвар (490) санында басылган «Татар матбугаты» дигән мәкаләдә XX йөз башында яңа татар дөньяви әдәбиятының үсеш юлын тәртипле бәяләү омтылышы ясала. Ибраһимов фикеренчә, 1905–1909 еллар аралыгы – «каләм сынау дәвере», 1910 еллардан исә үз юлын тапкан милли әдәбиятның яңа үсеш дәвере башлана: «Ашны – ташка, канны – җанга оештыра белгән һәркем шагыйрь булды, шигырь язды, имза алды. Әдәбият кануннарының һичберенә ашна булмаган вә табган истигъдадтан мәхрүм булган адәмнәр хикәячелек кыйлды... Шулай итеп, татар көтепханәсе канунсыз, юлсыз, мәгънәсез язылган әсәр белән тулды. Ләкин... зарар юк. Бу дәвер безнең өчен тәҗрибә вә гыйбрәт дәвере иде... Хәзер каләмнәр сыналды.



«Йолдыз» газетасында басылган «Татар матбугаты» (1910) мәкаләсеннән фрагмент

Фрагмент статьи «Татар матбугаты» («Татарская печать») на страницах газеты «Йолдыз». 1910





«Йолдыз» газетасында басылган «Татар матбугаты» (1910) мәкаләсеннән фрагмент

Фрагмент статьи «Татар матбугаты» («Татарская печать») на страницах газеты «Йолдыз». 1910

светской литературы начала XX века. Ибрагимов считает 1905–1909 годы – «периодом пробы перо» в татарской литературе, а с 1910-х годов начинается новый этап развития национальной литературы: «Все, кто мало-мальски умел рифмовать, стали поэтами. Кто не знал даже о существовании литературных канонов, писали рассказы. Таким образом, библиотека татарской литературы наполнилась произведениями, написанными без правил, без рифм, без смысла. Но… это не страшно. Этот период стал для нас опытом… Теперь уже писатели прошли испытание. Авторы, которые пришли в литературу только в поисках новизны или по материальным соображениям, повернули в другую сторону. Люди без таланта, без всякой способности к писательству и совершенно несведущие в литературных правилах, были вынуждены отступить от литературы» [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Сигез томда. Т. 5: әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933). Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. Б. 5–6].

Тәрәкъкыйпәрвәрлек [*яңалык юлы*] һәвәсе яки икътисад иҗбаре [*матди файда алу мәҗбүрияте*] беләң генә мәйданга атылган каләм ияләре читкә борылды. Талантсыз, куәи каләмиясез вә әдәбият кануннарыннан хәбәрсез адәмнәр каләм мәйданыннан чигенергә мәҗбүр булдылар» [Ибраһимов Г. Татар матбугаты // Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. Т. 5: әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933). Б. 5–6].

Бу мәкаләдә Тукайны башка шагыйрьләрдән аерып алып, аның татар поэзиясендә тоткан урынына югары бәя бирелә: «Хәзер шигырь мәйданында иң шәүкәтле һәм галәбәле рольне мөхтәрәм Тукаев уйный. Шул дәрәҗә ки, татар шагыйре диелүгәчә, укучы зиһенендә Тукаев мәүҗүд була» [Ибраһимов Г. Татар матбугаты. Б. 76].

Күзәтүләрен дәвам итеп, Г. Ибраһимов «Әдәбият мәсьәләләре» дип аталган күләмле мәкалә яза, ул «Йолдыз»ның 1 апрель, 3, 8 июнь һәм 1911 елгы 10 февраль саннарында басыла. Башында ук: «Әдәбият нидән гыйбарәт? Аңа ниләр



Галимҗан Ибраһимов.
ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 5. С. б. 24

Галимджан Ибрагимов.
ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 5. Ед. хр. 24



В этой статье дается очень высокая оценка творчеству Тукая, автор выделяет его среди других писателей: «Сейчас в поэзии самую почетную роль играет уважаемый Тукаев. До такой степени, что если говорим татарский поэт, в сознании сразу возникает имя Тукаева» [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 5: әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933). Б. 76].

Продолжая свои наблюдения, Г. Ибрагимов пишет объемную статью «Вопросы литературы», которая была опубликована в газете «Йолдыз» (1 апреля, 3, 8 июня 1910 года и 10 февраля 1911 года). В самом начале ставится вопрос: «Что есть литература? Что в нее входит? Вместо ответа на эти вопросы можно предложить следующие положения, выработанные с помощью науки о словесности» [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 5: әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933). Б. 18]. Тем самым автор статьи отметил, что статья посвящена вопросам литературы. Труд состоит из нескольких частей. Первая – под названием «Тәгъриф» (ознакомление, определение), где ведется разговор о понятии «литература». Г. Ибрагимов отождествляет термин «әдәбият» (литература) с русским терминам «словесность и литература». По его мнению, «все, что создано посредством языка и пера, есть литература» [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 5: әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933). Б. 18]. Таким образом, в широком смысле слова в понятие «литература» включаются и научные, и философские, и литературные произведения.

В узком смысле слова «литература» означает и частные случаи этого большого явления. Г. Ибрагимов указывает на то, что произведения художественной литературы также обозначаются термином «литература»: «Часть литературы – это также все произведения – стих, роман, рассказ и драма, которые написаны с целью воздействия на чувства, мечты и описывают разные стороны жизни» [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 5: әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933). Б. 20]. Здесь подмечена основная особенность

керә? Бу сорауларга җавап урынына фәне әдәбият ярдәме илә (наука о словесности) шул түбәндәге бәяннарны тәкъдим итәргә мөмкин» [Ибраһимов Г. Әдәбият мәсьәләләре // Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. Т. 5: әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933). Б. 18] дип, автор мәкаләнең әдәбият фәненә багышланганын искәртеп куя. Хезмәт үзе берничә өлештән тора. Беренчесе «Тәгъриф» [*таныштыру, билгеләмә*] дип аталып, анда «әдәбият» төшенчәсе хакында сүз алып барыла. Г. Ибраһимов «әдәбият» сүзен руслардагы «словесность вә литература» терминнарына тәңгәлләштерә. Аныңча, «тел вә каләм аркылы мәйданга чыккан мосаннәфатның мәҗмугы [*иҗат ителгән әсәрләрнең барысы*] әдәбият дип аталадыр», «адәмнәр тарафыннан сөйләнеп вә язылып килгән асаре фикериянең һәммәсе шамил буладыр» [Ибраһимов Г. Әдәбият мәсьәләләре. Б. 18]. Шулай итеп, киң мәгънәсендә «әдәбият» төшенчәсенә фәнни, фәлсәфи, әдәби әсәрләр – барысы да кертеп карала.

Тар мәгънәсендә «әдәбият» төшенчәсенең аерым өлешләре, кисәкләре дә шушы сүз ярдәмендә аңлатыла. Шул исәптән, Г. Ибраһимов матур әдәбият әсәрләренең «әдәбият» төшенчәсе белән аталуын да күрсәтә: «әдәбият кәлимәсе, гали вә әгъләби истигъмальдә [*күп кулланy*], шигырь, нәзым, роман, хикәя вә драм кеби, хис вә хыялга тәэсир өчен языла торган вә хәятның төрле ләүхәләрен тасвирга гаид булган әсәрләрне ирадә кыйлынып йөртеләдер» [Ибраһимов Г. Әдәбият мәсьәләләре. Б. 20]. Билгеләмәдә әдәбиятның төп үзенчәлеге – тормышның төрле күренешләрен чагылдыруы, хис һәм хыялга тәэсир итүе искәртелә. Вазифасы хакында: «Кешенең хиссияте никадәр саф вә яхшы тәрбияләнгән, рухы никадәр тәгали иткән булса, әдәби вә шигъри әсәрләр аңа шул нисбәттән ләззәт вә тәэсир бирәләр. Болар хәятның түземсез газапларыннан вә төрле борчуларыннан юаныч бирә; талган күңелне күтәрә; сүнгән өмид вә гайрәтләрне кузгата; хәят парчаларын җанландырып күрсәтәдер», дип, автор әдәбиятның рухи, эстетик, иҗтимагый ролен югары саный.



литературы – отражение разных явлений из жизни и способность воздействовать на чувства и мечты. О функции литературы: «Насколько хорошо развита, чиста душевная составляющая человека, развит его дух, настолько сильно воздействуют на него поэтические произведения, доставляют удовольствие. Они дают утешение при нестерпимых страданиях и разных беспокойствах жизни, возрождают поникшую душу, зажигают погасшие надежды, показывают живые явления из жизни». Автор считает духовную, эстетическую и общественную роль литературы весьма важной.

Вторая часть называется «Халык мосаннәфаты» и открывается определением устного народного творчества. «Собрание произведений, распространенных среди народа и передающихся из уст в уста, сохранившихся только в памяти этого народа, а авторство их не известно, дошедшие до нас из древности, называется народное творчество». Он пишет о том, что среди татар нет должного внимания к народному творчеству, ищет общее между фольклором и историей народа. Например, говоря о сказках, разделяет их на два вида: сказки, дошедшие до нас с языческих времен, и сказки, связанные с исламом. В сравнении с русскими сказками говорит о том, что у нас нет исторических сказок, поскольку «чувство религии полностью победило чувство нации» [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 5: әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933). Б. 28].

Г. Ибрагимов называет четыре жанра устного народного творчества: 1) сказки; 2) песни и баиты; 3) пословицы; 4) загадки. В вышеприведенном обзоре мы видим, что в понятие «сказка» Г. Ибрагимов включал и легенды, и эпические произведения – дастаны.

Третья часть называется «Шигырь» («Поэзия»). Этим понятием Г. Ибрагимов обозначает литературные произведения. Выступает против того, чтобы считать поэзией только ритмизированные тексты. Относительно этого считает должным объяснить три понятия. То, что мы сегодня обозначаем как стихотворное произведение,

Икенче бүлек «Халык мосаннәфаты» дип атала, ул халык авыз иҗатына билгеләмә биреп ачыла. «Халык арасында авыздан-авызга күчеп йөри торган, фәкать шул халыкның зиһенендә генә сакланып килгән вә чыгаручысы мәҗһүл булган, борынгы заманнан калма әсәрләрнең мәҗмугына халык мосаннәфаты дип исем биреләдер». Ул татарларда халык иҗатына игътибар булмау хакында яза, милләт тарихы белән фольклор арасында уртаклык эзли. Мәсәлән, әкиятләр хакында сөйләгәндә, аларның ике төрен аера: мәҗүси дәвердән килгән әкиятләр, ислам дине белән бәйле әкиятләр. Рус әкиятләре белән чагыштырып, бездә тарихи әкиятләр булмавын әйтә, чөнки, ди ул, «дин хисе миллият хисен тәмам җиңгән» [Ибраһимов Г. Әдәбият мәсьәләләре. Б. 28].

Г. Ибраһимов халык авыз иҗатының дүрт жанрын атый: 1) әкиятләр; 2) җыр һәм бәетләр; 3) мәкальләр; 4) табышмаклар. Югарыдагы күзәтүдән без анын «әкият» төшенчәсенә риваять-легендаларны, дастаннарны да кертеп каравын күрәбез.

Өченче бүлек «Шигырь» дип атала һәм Г. Ибраһимов бу төшенчә белән әдәби әсәрне атый. Тезмә әсәрләрне генә шигырь дип санауга каршы чыга. Шуңа мөнәсәбәтле өч төшенчәне аңлатып китәргә тиеш таба. Без бүген шигъри әсәр, лирика дип йөртә торган берәмлекне нәзым-тезмә термины белән бирә: «вәзен вә кафия ригая ителеп, берничә мисрагътан ясала. Безнең гавам аны көйле, җыр һәм бәет дип тәгъбир кыйладыр» [Ибраһимов Г. Әдәбият мәсьәләләре. Б. 31]. Нәсер дип автор тезмә булмаган сөйләмне, чәчмә сөйләмне атый, фәлсәфә, техника, фән, эстетика кебек өлкәләргә караган язмаларны да шушы өлкәгә кертә.

Нәсер белән шигырьнең аермасын күрсәтеп, нәсердә «бер нәрсә хакында могайян вә мәхдүд мәгълүмат бирү, мантыйкый вә вакыйгый бер фикер салу вә бер дәгъваны дәлил илә исбат кыйлу касд кыйлына; нәсер үзенең яздыгы илә укучының гакыл вә мөхакәмәсенә [*хөкем, фикер йөртү*] мөрәҗәгать кыйладыр» дисә, шигырь «кешенең



лирика, Г. Ибрагимов обозначает понятием «нәзым-тезмә». Нерифмованное произведение, прозаическое, автор называет словом «нәсер» (эпос, проза), включая сюда и тексты по философии, технике, науке, эстетике.

Указывая на отличия прозы от поэзии, автор говорит: «В прозе основная задача – дать достоверную информацию о чем-либо, выразить мысль, доказать что-либо через приведение доказательств. Проза обращается к разуму читателя». Поэзия же затрагивает душу человека, обращается прежде всего к чувствам читателя, этим ведет его к идее [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 5: әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933). Б. 32]. Вместе с тем заявляет, что поэт должен быть свободен от проповедческих речей, тем самым отвергает морально-воспитательную функцию поэзии, веками считавшуюся основной.

Ставятся также вопросы: в чем ценность литературного произведения, как, по каким критериям ее можно оценить? «Пусть оно льет на нас прекрасные, возвышенные чувства, одухотворенность. Пусть вещи, казалось бы, обыденные, предстанут перед нами в новом, совершенно другом свете...» [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 5: әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933). Б. 33].

Художественную ценность произведения Г. Ибрагимов видит в трех признаках: красота, эмоциональность и образность. В качестве доказательства приводит примеры из татарской литературы.

Мысли Г. Ибрагимова касательно литературы и народного творчества, размещенные в книге «Вопросы литературы», помогают понять, с какой точки зрения он смотрел на историю литературы, на отдельное творчество, произведение. Теоретическое основание его концепции было заложено в этом труде.

Нужно отметить, что Г. Ибрагимов относился резко критически к татарской литературе своего времени. Стихотворения З. Башири, М. Укмаси он объявил совершенно непригодными, в творчестве М. Гафури и Н. Думави,

хиссиятенә, куәи хыялиясенә кагылу вә шул як илә үзенең идеясенә алып баруны юл тотадыр» [Ибраһимов Г. Әдәбият мәсьәләләре. Б. 32]. Шуның белән бергә, «шагыйрь вәгазь вә тәгълимнән азат» булырга тиеш дип, әдәби әсәрнең гасырлар буе беренче саналган әхлак тәрбиясе бурычын кире кага.

Әдәби әсәрнең кыйммәте нәрсәдә? аны нинди үлчәүгә салып бәяләргә кирәк? дигән сораулар да куела. «Ул безгә назик вә мөәссир хисләр, гали моң, матур ләүхәләр түксен! Безгә гади күренгән нәрсәләрне бөтенләй башка итеп күз алдыбызга салсын. Шуның өчен дә истигъдадлары икърар кыйлынган олугъ шагыйрьләрнең хакыйкый шигырьләрендә табигатьнең моң, мөәссир вә матур мәнзарәләре, үзенең хиссияте шәхсиясе, әүлахе руханиясе мөһим урын тоталар» [Ибраһимов Г. Әдәбият мәсьәләләре. Б. 33]. Г. Ибраһимов әсәрнең сәнгатьлелеген өч билгедә: матур, хисле һәм образлы булуда күрә. Татар әдәбиятыннан мисаллар китереп исбатлый.



Зариф Бәшири
(1888–1962)
Зариф Башири
(1888–1962)





Күмәк фото. ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 5. С. б. 68
Коллективная фотография. ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 5. Ед. хр. 68

считал Ибрагимов, хоть есть хорошая рифмованная речь, нет собственно поэзии, то есть вышеупомянутых трех признаков. В произведениях С. Рамиева есть и эмоциональность, и образность, но не хватает красоты. Стихи, которые соответствуют всем трем критериям, он находит у Тукая. Что касается общего состояния татарской литературы, Г. Ибрагимов указывает в числе основных недостатков нехватку глубины и узость тематики.

Вместе с литературой Г. Ибрагимов начал на профессиональном уровне заниматься проблемами татарского языка и его преподавания. В «Автобиографии», написанной в 1929 году, он называет такие направления научной деятельности до 1917 года: «а) теория татарского литературного языка и его применение; б) методика татарского языка; в) теория и принципы татарской литературы. В газетах и журналах, выходящих в то время, опубликовал множество статей, очерков. Крупные труды были напечатаны в виде отдельной книги. Например, «Татар сарыфы» («Морфология

Г. Ибраһимовның әдәбият һәм халык иҗатына карылышлы «Әдәбият мәсьәләләре»ндә шәрехләнгән фикерләре алга таба әдәбият тарихына, аерым иҗатка, әсәргә нинди күзлектән якын килүен аңларга ярдәм итә. Аның нәзари концепциясенең нигезе шушы хезмәттә салына, зур үзгәрешләр кичермичә, киңәйтелеп-тирәнәйтелеп бара.

Әйтергә кирәк, Г. Ибраһимов үз чоры татар әдәби барышына кискен тәнкыйди якын килә. З. Бәшири, М. Укмасый шигырьләрен бөтенләй яраксызга чыгара, М. Гафури һәм Н. Думавида тезмә сөйләм ярыйсы булса да, «шигърият», ягъни әлеге өч сыйфат юк дип саный. С. Рәмиев шигырьләрендә хис тә, образлылык та бар, ләкин нәзым камил түгел – матурлык җитми дип белдерә. Өч яктан да канәгатьләнерлек шигырьләрне Г. Тукайда таба. Татар шигъриятенең гомуми хәленә килгәндә, тирәнлек, тематик киңлек җитмәү төп кимчелек итеп күрсәтелә.

Әдәбият белән янәшә, Г. Ибраһимов татар теле һәм аны укыту проблемасы белән профессиональ дәрәҗәдә



Миргазиз Укмасый
(1884–1948)
Миргазиз Укмаси
(1884–1948)





Нәҗип Думави
(1883–1933)
Наджип Думави
(1883–1933)

татарского языка», первое издание, Казань, 1911; пятое издание, 1918), «Татар нәхүе» («Синтаксис татарского языка», 1911), «Татар имлясы» («Татарская орфография», 1914), «Әдәбият кануннары» («Каноны литературы», первое издание, 1916; третье издание, 1919), «Татар телен ничек укытырга?» («Методика преподавания родного языка», 1916) и др.» [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 5: әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933). Б. 19].

Первой статьей в этом направлении стала «Татар теле һәм татарча язу хакында бер-ике сүз» («Несколько слов о татарском языке и письме»), опубликованная в газете «Йолдыз» 30 марта 1910 года (№ 521), где подчеркивается важность изучения и развития языка для письма на том татарском языке, который народ способен будет понять. В той же газете 12 апреля 1911 года (№ 669) Г. Ибрагимов опубликовал рецензию на книгу Шаехгаттара Иманаева «Татар теленең нәхүе вә сарыфы» («Синтаксис и морфология татарского языка»). «Даже если со всех других сторон книга будет совершенна,

кызыксынып китә. 1929 елда язылган «Автобиография»-сендә ул 1917 елга кадәрге фәнни эшчәнлек юнәлешләрен түбәндәгечә күрсәтә: «...түбәндәге юнәлештә гыйльми тикшеренү эше башлап җибәрдем: а) татар әдәби теле теориясе һәм аны куллану; б) татар теле методикасы; в) татар әдәбияты теориясе һәм принциплары. Шул заманда чыгып килгән газеталарда һәм журналларда күп кенә мәкаләләр, очерклар бастырдым. Зур хезмәтләрем аерым китап булып чыктылар. Мәсәлән, «Татар сарыфы» (беренче басма, Казан, 1911; бишенче басмасы 1918 елда), «Татар нәхүе» (1911), «Татар имлясы» (1914), «Әдәбият кануннары» (беренче басмасы 1916, өченче басмасы 1919 елда), «Татар телен ничек укытырга?» (1916) һәм башкалар» [Галимҗан Ибраһимов: хатлар һәм документлар. Б. 19].

Бу юнәлештәге беренче мәкаләсе булган «Татар теле һәм татарча язу хакында бер-ике сүз» дигән, «Йолдыз»ның 1910 елгы 30 март (521) санында басылган текстта телне өйрәнүнең һәм үстерүнең халык аңларлык татарча язу



«Татар телен ничек укытырга?» китабы тышлыгы. 1916

Обложка книги «Татар телен ничек укытырга?» («Методика преподавания родного языка»). 1916





«Татар телен ничек укытырга?» китабының титул бите. 1916

Титульная страница книги «Татар телен ничек укытырга?» («Методика преподавания родного языка»). 1916

есть одно обстоятельство, которое уменьшает ценность книги наполовину, – это то, что правила, описанные здесь, весьма далеки от литературы. Этот недостаток свойственен не только данной книге, но и всем трудам по синтаксису и морфологии, изданным и распространенным ранее. Еще ни одно пособие по синтаксису не смогло выразить свое отношение к литературе, свое единство с литературой. Хотя, конечно, так быть не должно. Морфологии и синтаксисы пишутся с целью продвижения языка и литературы» [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Сигез томда. Т. 8: төрки һәм татар теле белеме буенча хезмәтләр (1910–1930). Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. Б. 24–25].

В предисловии к первому изданию «Морфология татарского языка» (1911) вновь повторены слова: морфология и синтаксис предназначены для развития родного языка и литературы [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 8: төрки һәм татар теле белеме буенча хезмәтләр (1910–1930). Б. 29].

«Морфология татарского языка» и «Синтаксис татарского языка» были подготовлены как учебные пособия по

өчен мөһимлеге ассызыклана. Шул ук газетаның 1911 елгы 12 апрель (669) санында Г. Ибраһимов Шәехгаттар Иманаевның «Татар теленең нәхүе вә сарыфы» дигән китабына рецензия тәкъдим итә: «Башка һәр яктан мөкәммәл булган тәкъдирдә [дә], китапның ярым кыйммәтен бетерә вә гамәлдән чыгара торган җәһәте – бондагы кагыйдәләрнең әдәбияттан тәмам ерак торуыдыр. Бу – бер монда гына түгел, моңарчы таралган башка сарыф вә нәхүләргә дә гомуми булган бер кимчелектер. Моңарчы һичбер нәху үзенең әдәбиятка мөнәсәбәтен, аның илә тәмам багъланган икәнен күрсәтә алмады. Вәкыйгъда алай тиеш түгел иде. Сарыф вә нәхүләр тел вә әдәбият өчен языла» [Ибраһимов Г. Яңа китап // Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. Т. 8: төрки һәм татар теле белеме буенча хезмәтләр (1910–1930). Б. 24–25].

Үзенең «Татар сарыфы» (1911) китабының беренче басмасына кереш сүзендә дә «сарыф белән нәхү тел вә әдәбият өчен генә» языла дигән сүзләр кабатлана [Ибраһимов Г.




«Татар нәхүе» китабы. 1911

Книга «Татар нәхүе» («Синтаксис татарского языка»). 1911





«Татар нәхүе» китабы. 1917, 1919 елгы басмалар

Книга «Татар нәхүе» («Синтаксис татарского языка»). Издания 1917 и 1919 года

родному языку для мектебов и медресе, отпечатаны в издательстве «Гасыр». К 1910-м годам татарский язык был введен в программу мектебов и медресе как отдельный предмет наравне с арабским языком. Но продвижению дела мешало отсутствие учебной литературы. Первые учебные пособия испытали сильное влияние арабских и персидских грамматик и были тяжелы для восприятия. Книги же Г. Ибрагимова были написаны внятно, в соответствии с современными требованиями, все правила языка просто и легко объяснялись на примерах из родного языка, что обеспечило популярность этих книг среди учебных заведений. Эти труды оцениваются как заложившие основы классическому татарскому языкознанию [Хакимов Б.Э. Деятельность Галимджана Ибрагимова в области татарского языкознания: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2005. 29 с.].

Интеллигенция того времени приняла эти пособия на ура. Вскоре появились рецензии в газетах и журналах. Например, отзывы Дж. Валиди «Татар сарфы вә нәхүе» в

Мөкаддимә // Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. Т. 8: Төрки һәм татар теле белеме буенча хезмәтләр (1910–1930). Б. 29].

«Татар сарыфы» (сарыф – морфология) һәм «Татар нәхүе» (нәхү – синтаксис) мәктәп-мәдрәсәләрдә ана теле дәресләре өчен кулланма итеп эшләнә, «Гасыр» нәшриятында басыла. 1910 елларга татар теле предмет буларак мәктәп-мәдрәсәләргә кертелә, гарәп теле дәресләре белән беррәттән укытыла башлый, әмма дәреслекләр булмау бу эшкә комачаулый. Басылып чыккан беренче дәреслекләрдә исә шул ук гарәп-фарсы грамматикаларының йогынтысы аларны кабул итү эшен авырайта. Г. Ибраһимов китапларының заман таләпләренә туры килүе, татар теле кагыйдәләрен телнең үз материалында гади һәм ачык аңлатуы аларның бик тиз татар уку йортларына кереп китүен тәэмин итә. Бу китаплар классик татар тел белеменә нигез салган хезмәтләр буларак бәяләнә [Хакимов Б.Э. Деятельность Галимджана Ибрагимова в области




«Татар сарыфы» китабы. 1911, 1913 елгы басмалар

Книга «Татар сарыфы» («Морфология татарского языка»). Издания 1911 и 1913 года






«Татар сарыфы» китабы. 1917 елгы басма

Книга «Татар сарыфы» («Морфология татарского языка»). Издание 1917 года

журнале «Шура» (1911, № 22), Г. Сагди «Татар сарфы» в том же журнале (1912, № 3), Хаерби «Татар сарфы вә нәхүе» в газете «Йолдыз» (1911, 1 ноября) и др. отличаются основательностью, детальностью. В 1912 году в журнале «Шура» (№ 3, 226–267 с.) Г. Ибрагимов публикует статью под названием «Тәшәккер йөзендән (Җаваплар)» («С благодарностью (Ответы)») и выражает свое мнение по поводу замечаний и предложений, высказанных в рецензиях, подробно разбирает каждое замечание, которое либо принимает, либо нет.

По нашему мнению, эта публикация позволяет понять и характер Г. Ибрагимова, и причину появления столь критических статей: с одной стороны, свидетельствует о высоких требованиях, предъявляемых себе и другим, с другой – указывают, что он считал критику действенным средством усовершенствования печатных изданий. Одновременно с этим видно и чрезмерное увлечение Г. Ибрагимова критикой, его выпады иногда кажутся совершенно безосновательными.

татарского языкознания: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2005. 29 с.].

Үз заманы зыялылары әлеге кулланмаларны хуплап каршы алалар. Тиз арада төрле газета-журналларда рецензияләр пәйда була. Мәсәлән, Ж. Вәлидинең «Шура» да (1911 ел, № 22) «Татар сарфы вә нәхүе», Г. Сәгъдинең шул ук журналда (1912 ел, № 3) «Татар сарфы», Хәербинең «Йолдыз»да (1911, 1 ноябрь) дөнья күргән «Татар сарфы вә нәхүе» һ.б. язмалар җентекле, нигезле булулары белән аерылып торалар. 1912 елда Г. Ибраһимов «Шура» журналында (№ 3, 226–267 бб.) «Тәшәккер йөзендән (Җаваплар)» исемендәге мәкалә бастыра һәм рецензияләрдәге киңәш-тәкъдимнәргә карата үз мөнәсәбәтен белдерә, кайсы очракны кабул итә яки килешми – шуларны җентекләп тикшереп уза. Безнең фикеребезчә, бу язма Г. Ибраһимовның холкын да, аның үзенең тәнкыйть мәкаләләрен дә аңларга юл күрсәтә: бер яктан, үзенә һәм башкаларга карата зур таләпләр куюы хакында сөйли, икенчедән, тәнкыйтьне алга таба



Җамал Вәлиди
(1887–1932)
Джамал Валиди
(1887–1932)





Габдрахман Сәгъди
(1889–1956)
Габдрахман Сагди
(1889–1956)

Введение татарского языка, татарской литературы как отдельных дисциплин в программы мектебов и медресе активизировало процесс создания учебников по этим предметам. В достаточно короткий срок были написаны и изданы многочисленные учебники и учебные пособия, книги для чтения. В 1910 году и Г. Тукай подготовил и издал хрестоматию – первый сборник авторских произведений под названием «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» («Уроки национальной литературы в школе»). Здесь представлены произведения самого Г. Тукая, а также стихотворения и отрывки из прозаических произведений Г. Исхаки, Ф. Амирхана, М. Укмаси, З. Хади, Р. Фахретдина, Ф. Карими и др.

В 1910 году Г. Ибрагимов пишет рецензию на эту хрестоматию и публикует под названием самой хрестоматии в газете «Йолдыз» 4 января 1911 года (№ 628). Хотя и начинает разговор с того, что отмечает нужность такого рода изданий, Г. Ибрагимов ставит Тукаю в упрек излишнее увлечение проповедничеством, дидактизм, назидательность

файдалану, киләсе басмаларны камилләштерү чарасы итеп каравына дәлил булып килә. Бер үк вакытта Г. Ибраһимовның тәнкыйтьләү белән мавыгып китүләре, еш кына нигезсез тешләүләре турында да нәтиҗә соралып тора.

Мәктәп-мәдрәсәләргә татар теле, татар әдәбияты предметларының кертелүе дәреслекләр төзү эшен гаять тә активлаштыра. Тиз арада күпсанлы дәреслекләр, кулланмалар, уку китаплары төзелә, басылып чыга. 1910 елда Г. Тукай да авторлары мәгълүм әдәби әсәрләрдән төзелгән беренче хрестоматиясен – «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» дип исемләнгән китабын нәшер итә. Анда Г. Тукайның үз әсәрләре, Г. Исхакый, Ф. Әмирхан, М. Укмасый, З. Һади, Р. Фәхретдин, Ф. Кәрими һәм башка татар әдипләренең шигырьләре һәм проза әсәрләреннән өзекләр урын алган.

Г. Ибраһимов 1910 елда аңа рецензия яза, хрестоматиянең исеме белән «Йолдыз»ның 1911 елгы 4 гыйнвар (628) санында бастырып чыгара. Сүзне мондый уку китапларының кирәклегеннән башласа да, ул Тукайны текстлар



Г. Тукайның «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» китабы. 1910

Книга Г. Тукая «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» («Уроки родной литературы в школе»). 1910





Гаяз Исхакый (1878–1954)

Гаяз Исхаки (1878–1954)



Риза Фәхретдин (1859–1936)

Риза Фахретдин (1859–1936)

в выборе текстов, обращает внимание на то, что некоторые произведения по духу не являются татарскими.

В том же году Г. Ибрагимов опубликовал в газете «Йолдыз» рецензии на сборник Г. Тукая «Күңел җимешләре» («Плоды души», 5 апреля, № 666) и произведение «Мияубике» (21 июня, № 699). Мнение Г. Ибрагимова о том, что произведение не получилось в полном смысле слова стихотворением, выраженное во второй публикации, сильно задело Тукая: в номере этой же газеты от 30 июня он резко ответил на критику публикацией «Аз гына төзәтү» («Некоторые правки»). Названные две публикации стали началом охлаждения отношений Г. Тукая и Г. Ибрагимова, причиной взаимных нападок на страницах газет.

В журнале «Шура» № 8 за 1911 год (апрель) и № 9 за 1912 год (май) Г. Ибрагимов опубликовал две статьи: «Без – татармыз» («Мы – татары») и «Без кем?» бәхәсе» («Спор о том, кто мы»). Написаны они относительно споров, отразившихся на страницах этого журнала в 1910 году в рубрике

сайлаганда артык вәгазьчелеккә, үгет-нәсыйхәтчелеккә бирелеп китүдә гаепли кайбер әсәрләрнең рухы татарча булмауга игътибар итә.

Шушы ук елда Г. Ибраһимов «Йолдыз»да Г. Тукайның «Күңел җимешләре» җыентыгына (5 апрель, 666 сан) һәм «Мияубикә» әсәренә (21 июнь, 699 сан) рецензияләр язып бастыра. Икенче язмада әсәрнең шигырь булып чыкмавы хакындагы фикер Г. Тукайның күңеленә тия – ул шушы ук газетаның 30 июнь санында «Аз гына төзәтү» исеме белән кискен генә җавап бирә. Әлеге ике бәхәсле язма алга таба Г. Тукай белән Г. Ибраһимовның арасы суынуга, матбугат битләрендә хаксызга бер-берсен тәнкыйтьләүләргә сәбәп була.

«Шура» журналының 1911 елгы 8 (апрель) һәм 1912 елгы 9 (май) саннарында Г. Ибраһимов ике мәкалә бастыра: «Без – татармыз» һәм «Без кем?» бәхәсе». Алар әлеге журналда 1910 елда «Тел ярышы» рубрикасында барган бәхәсләргә нисбәтле язылган. XX йөз башы – татар җәмгыятенең милли үзбилгеләнү вакыты, бу чорда матбугатта милләтнең



Г. Тукайның «Күңел җимешләре» китабы. 1911

Книга Г. Тукая «Күңел җимешләре» «Плоды души»). 1911





Г. Тукайның «Мияубикә» китабы. 1911

Книга Г. Тукая «Мияубике». 1911

«Тел ярышы» («Мастера спора»). Начало XX века – время самоопределения татарского этноса, когда в обществе активно обсуждался вопрос и развивались споры на тему «По какому пути следует развиваться нации?». Одни были за развитие в общетюркском культурном русле и за этноним «тюрки», другие артикулировали этноним «татары» и ратовали за развитие самостоятельной национальной единицы. Публикации Г. Ибрагимова написаны с точки зрения второй позиции. Об этнониме «татар» он пишет следующее: «Он – наш и он совершенно не противоречит тому, что мы являемся частью тюрков. ...Дела свои называем татарскими делами, сами мы – татары, язык наш – татарский, литература – татарская литература; все, что нами достигнуто, – татарские достижения; культура, которая создается, будет татарской культурой» [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Сигез томда. Т. 7: тарихи хезмәтләр (1911–1927). Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. Б. 10]. Г. Ибрагимов придерживался этой линии до конца жизни.

нинди юл белән үсәргә тиешлеге хакында сөйләшүләр бара. Берәүләр гомумтөрки мәдәният эчендә хәрәкәтне һәм «төрки» атамасын яклап чыкса, икенчеләр «татар» исемен һәм мөстәкыйль милли үсеш юлын булдыруны хуплый. Г. Ибраһимовның язмалары икенче позициядән торып язылганнар. Татар атамасы турында ул болай ди: «Ул – безнеке, һәм ул безнең төрек милләтеннән булуымызга каршы түгел. (...) Эшләремез татар эше дип атыймыз; үземез – татар; телемез – татар теле; әдәбиятымыз – татар әдәбияты; эшләгән һәммә эшемез – татар эшләре; туачак мәдәниятемез татар мәдәнияте булачак» [Ибраһимов Г. Без – татармыз // Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. Т. 7: Тарихи хезмәтләр (1911–1927). Б. 10]. Гомеренең соңгы көннәренә кадәр Г. Ибраһимов шушы фикереннән кайтмый.

1911–1912 елларда Г. Ибраһимов әдәби тәнкыйть өлкәсендә актив эшли, аның тәнкыйть мәкаләләре һәрчак текстлардагы кимчелекләрне җентекләп күрсәтүе белән аерылып тора. Мәсәлән, «Йолдыз»ның 1911 елгы 15 ноябрь




«Шура» журналы
Журнал «Шура»



Г. Ибраһимов
Шәһит Әхмәдиев белән.
ЯһМММҮ. Ф. 65. Тасв. 5. С. б. 46

Г. Ибрагимов
с Шахитом Ахмадиевым.
ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 5. Ед. хр. 46



В 1911–1912 годах Г. Ибрагимов активно работает в области литературной критики. Его критические статьи отличаются подробным, детальным разбором недостатков текста. К примеру, в статье «Хаят», опубликованной в газете «Йолдыз» 15 ноября 1911 года (№ 757) речь идет о повести Ф. Амирхана «Хаят», в статье «Зур романнар» («Большие романы»), опубликованной в той же газете 13 марта 1912 года (№ 805), – о романе Ф. Амирхана «Урталыкта» («В середине»). Несмотря на то, что Г. Ибрагимов в целом дает высокую оценку творчеству Ф. Амирхана, заявляет, что в произведении есть и плоские места: «Картины, которые он рисует, не предстают перед читателем во всей полноте, живо. Первая любовь юных душ здесь получилась совсем уж пресной. Также есть сомнения по поводу естественности типа (типажа) Хаят. Уважаемый Фатих эфенди и здесь, как и в других своих произведениях, кроме разве что «Татар кызы» («Татарка»), позволил своему мастерству и искусству подавить естественное течение процесса, то есть здесь искусство

(757) санында басылган «Хәят» язмасында Ф. Әмирханның шул исемдәге повесте, 1912 елгы 13 март (805) санында дөнья күргән «Зур романнар» язмасында әдипнең «Урталыкта» романы хакында сүз бара. Ф. Әмирхан иҗатын югары бәяләвенә карамастан, Г. Ибраһимов әсәрдә «сай чыккан җирләр дә күп» дип белдерә: «Аның картиналары бөтен хәяты илә тулып, җанланып күз алдына килми. Монда яшь күңелләрнең беренче мәхәббәте сыек чыга. Хәят тибының табигый икәнлеге хакында да бик зур шөбһә бар. Дәхи Фатих әфәнде, үзенең «Татар кызы»на башка булган һәрбер әсәрләрендәге кеби, бусында да сәнгать вә каләм йөртергә осталык илә табигый агышны, каләмнең табигый барышын күмеп ташлый, ягъни сәнгать табигатьне җиңә. Бу исә реальныйлыкка дәгъва иткән әдипкә мактаулы сыйфат түгел. Әсәргә «милли хикәя» диелгән. Мин моның яңлышлыгы хакында кул кисеп бәхәсләшә алам. Бер роман, бер хикәянең «милли» булуы өчен, татарча языйлып, мәүзугъ итеп татарларны алган булуы гына җитми, бәлки аның



Фатих Әмирхан
(1886–1926)

Фатих Амирхан
(1886–1926)






Фатих Әмирханның
«Хәят» китабы.
1911

Книга
Фатиха Амирхана «Хаят».
1911

победило природу. Это не делает честь писателю, претендующему на реальность, реализм. Произведение названо «милли хикәя» («национальный рассказ»). Руку даю на отсечение, это ошибочное определение. Чтобы назвать рассказ или роман национальным, недостаточно только того, что они написаны на татарском языке и о татарах, нужно, чтобы татарскость звучала в каждом слове, а герои должны быть насыщены татарским духом...» [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 5: әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933). Б. 58–59]. С таким мнением о прекрасном классическом произведении татарской литературы начала XX века «Хаят» согласиться сложно.

В февральских номерах газеты «Идель» за 1912 год, издававшейся в Астрахани, Г. Ибрагимов начал публикации частей о творчестве Сагита Рамиева наиболее спорного своего научно-критического труда «Татар шагыйрьләре» («Татарские поэты»). Полное издание труда было осуществлено в Оренбурге в 1913 году отдельной книгой и вызвало резкое

мәркәзендә татарлык аңкып торырга, каһарманнар татар рухы илә мөкәммәл рәвештә сугарылган булырга кирәк...» [Ибраһимов Г. «Хәят» // Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. Т. 5: әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933). Б. 58–59]. XX йөз башы татар әдәбиятының гүзәл классик әсәре булган «Хәят» турындагы әлеге фикерләр белән килешү авыр.

1912 елның февраль саннарында Әстерханда нәшер ителгән «Идел» газетасында Г. Ибраһимов үзенең иң бәхәсле фәнни-тәнкыйди хезмәтен – «Татар шагыйрьләре»нең С. Рәмиев иҗаты турындагы өлешен бастыра башлый. Тулы килеш хезмәт 1913 елда Оренбургта аерым китап булып дөнья күрә һәм татар мәдәни җәмгыяте тарафыннан гаять тискәре кабул ителә. Хезмәтнең Тукай каты авыру вакытта, үлеменә берничә ай калгач нәшер ителүе зур шау-шуга, мәсьәләнең әхлакый, кешелеклелек ягын үзәккә куюга сәбәп була.

«Татар шагыйрьләре» милли шигърият мәйданындагы төп көчләрдән булган өч шагыйрь иҗаты мисалында



Фатих Әмирханның «Урталыкта» китабы. 1912

Книга Фатиха Амирхана «Урталыкта» («В середине»). 1912





Фатих Әмирханның «Татар кызы» китабы. 1909

Книга Фатиха Амирхана «Татар кызы» («Татарка»). 1909

неприятие татарского культурного общества. К тому же книга увидела свет во время тяжелой болезни Тукая, за несколько месяцев до его смерти, что вызвало пересуды в обществе, выпятило моральную, человечную сторону вопроса.

Труд «Татарские поэты» написан на примере творчества трех поэтов, заслуживших всеобщее признание в татарском обществе, и является поиском ответа на вопрос «Что есть поэзия?». «Все, что воздействует на наши дух и мечты, вызывает эмоциональный отклик, есть поэзия. Стихотворение создается не столько языком и умом, сознанием, столько духом, душой человека, его мечтами и чувствами. Чтобы сделать поэтическое произведение совершенным, необходимо облечь тему в поэтические слова» [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 5: әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933). Б. 81], говорит автор и разбирает произведения трех татарских поэтов, выстраивая их в ряд по уменьшению значимости: С. Рамиев, Дэрдменд, Г. Тукай.

«шигырь нәрсә?» дигән сорауга җавап эзләп язылган. «Безнең рух вә хыялыбызга тәэсир итәчәк, хиссиятебезне, тәэссоратыбызны кузгатачак һәрбер нәрсә – шигырь. Шигырь телдән яки гакыл вә зиһеннән түгел, бәлки адәмнең рухыннан, күңеленнән, хыял вә хисеннән туа. Бер шигырьнең камил шигырь булып чыгуы өчен шагыйрьнең бер нәрсәдән тәэсир итәчәк рәвештә шигъри сүзләр эченә салуы лазем» дип [Ибраһимов Г. Татар шагыйрьләре // Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. Т. 5: Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933). Б. 81], автор сайлап алынган шагыйрьләр иҗатына да шушы кыйммәтләр яссылыгында якын килә һәм аларны С. Рәмиев, Дәрдемәнд, Г. Тукай рәвешендә тезә.

Китапта С. Рәмиев, Дәрдемәнд иҗатлары шактый тулы, һәм образлар дөньясы, һәм фикри көче, сурәт-алымнар, яңгыраш-вәзен ягыннан җентекле тикшерелә. Аерым алганда, С. Рәмиев шигърияте халык өчен түгел, бәлки элитар иҗат дип бәяләнеп, Г. Ибраһимов аның шигырьләрендәге



Сәгыйть Рәмиев
(1880--1926)
Сагит Рамиев
(1880–1926)




ایدل

«Идел» газетасы
Газета «Идель»

В книге творчество С. Рамиева и Дэрдменда разобраны достаточно подробно и в плане системы образов, используемых приемов, и в плане новизны. В частности, поэзия С. Рамиева оценивается не столько как творчество для народа, а называется элитарным творчеством. Г. Ибрагимов отмечает внутренний огонь его произведений, сильную эмоциональность как наиболее сильные стороны творчества, в то же время указывает на то, что язык произведений не всегда поспевает за чувствами. «Эта эмоциональность, этот огонь Сагита слишком сильны, душа нетерпеливо и неестественно стремится куда-то, причем настолько, что такое стремление духа язык уже не успевает облечь в понятные читателю и красивые, естественные слова» [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 5: әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933). Б. 78]. Таким образом, Г. Ибрагимов заявляет, что творчество С. Рамиева настолько сильно в плане эмоционального воздействия и заложенного в нем смысла, насколько слабо в плане языка и речи. Далее анализируется

эчке рухи ялкынның куәтле, ашкынулы булуын иң мөһим хасиятләрдән дип күрсәтә, әмма сөйләмнең хис артыннан җитешеп бара алмавын билгели: «Сәгыйтьнең бу тәэссераты, бу ялкыны артык куәтле таша, күңел чыдамсыз һәм гайре табигый ашкына, бу шу дәрәҗәдә ки, рухның ул куәтле, хәтта тиле ашкынуын, ниһаясез куәтле изтирабны икенчеләргә ачык әйтеп бирергә сүз җитештерә алмый, тел аларны матурлап, табигый ясап чыгарырга өлгерә алмый» [Ибраһимов Г. Татар шагыйрьләре. Б. 78]. Шул рәвешле, шагыйрьнең иҗаты мәгънә һәм хис ягыннан никадәр көчле һәм тирән булса, тел-сөйләм җәһәтеннән кимчелекле, диелә. Алга таба С. Рәмиевнең пейзаж, мәхәббәт, гражданлык лирикасы анализланып, автор укучысын аның чын шагыйрь икәнлеге хакындагы фикергә китерә.

Дәрдемәнд иҗатының фәлсәфи тирәнлеге белән янәшә, Г. Ибраһимов аның форма камиллеген дә югары күтәрә: «Чөнки аңарда чынлап та яңа рух сизелә (...) нининдер әдәби мәдәнилек, чын каләм сәнгате, матур өслүб, җыйнак вә



Дәрдемәнд (1859–1921)

Дэрдменд (1859–1921)





Г. Тукай, С. Рәмиев, Ш. Гайфи. Әстерхан. 1911

Г. Тукай, С. Рамиев, Ш. Гайфи. Астрахань. 1911

пейзажная, любовная, гражданская лирика поэта, и автор приводит читателя к мысли, что С. Рамиев – истинный поэт.

Что касается творчества Дэрдменда, Здесь Г. Ибрагимов высоко ценит философскую глубину его произведений, облеченных в совершенную форму: «Потому что у него чувствуется истинный дух… литературный вкус, истинное мастерство слова, красивая форма, короткие и емкие фразы, легкость письма и чистое поэтическое чувство, соединенное с грустной мыслью...» [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 5: әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933). Б. 96]. В ходе анализа отдельных произведений достаточно полно раскрываются отголоски экзистенциальной философии, общечеловеческие и личные ценности, выраженные в творчестве поэта. Этот материал Г. Ибрагимова по творчеству Дэрдменда имеет полное основание считаться трудом, где дана глубокая оценка творчества поэта.

Разговор о творчестве Г. Тукая Г. Ибрагимов начинает с критики его художественного языка. Анализ отдельных

кыска тәгъбирләр; җиңел вә шома йөри торган каләм һәм хөзен катыш тәфәккер [*хәсрәт катыш фикер*] илә самими шигъри тойгы...» [Ибраһимов Г. Татар шагыйрьләре. Б. 96]. Аерым шигырьләрне анализлау барышында шагыйрь иҗатындагы экзистенциаль фәлсәфә, гомумкешелек һәм шәхси кыйммәтләр шактый тирән ачыклана, Г. Ибраһимовның әлеге материалы Дәрдемәнд иҗатына тулы бәя биргән хезмәтләрдән дияргә нигез бар.

Г. Тукай иҗаты турында сүзне Г. Ибраһимов аның тел-сөйләмен тәнкыйтьләүдән башлый. Аерым шигырьләргә тукталуы да шагыйрь әдәби фикеренең кимчелекләрен ачыклау төсендә алып барыла. Г. Ибраһимов «Тукаев шагыйрьме, түгелме?» дигән сорау куя да, гомумиләштереп, аңа мондый җавап бирә: «Вәзен вә кафияне яхшы чыгарып, оста тел вә вә яхшы инша белән язылган һәрбер нәзымны шигырь дип караган, шу мәнзумәдәге фикер вә фәлсәфәнең шәплеге, күплеге игътибары белән ул нәзымчының мәртәбәсен күтәрә торган һәрбер укучы ул сөальгә, әлбәттә,



Эш бүлмәсе
Рабочий кабинет





«Аң» журналындагы эш өстәле
Рабочий стол в редакции журнала «Анг»

произведений также выстроен в виде раскрытия недостатков литературной мысли поэта. Г. Ибрагимов ставит вопрос: Тукай – поэт или нет? Обобщая, дает следующий ответ: «Читатель, который ценит, прежде всего, рифму, язык произведения, заложенные в него мысли и мнения, несомненно, будет считать его поэтом. Так как у Габдуллы эфенди все это присутствует с избытком».

Но те, кто хорошо подготовлен, чтобы отличить поэзию от простого рифмованного текста, содержащего моральные предписания, у кого развит художественный вкус, вряд ли ответят на вышеуказанный вопрос однозначно… Даже если посчитают его поэтом, то не всегда, не все его произведения назовут поэзией, но только малую часть творчества» [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 5: әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933). Б. 128].

Вскоре появилось множество статей, выступающих против такой оценки творчества одного из самых любимых татарским народом поэтов начала XX века. Среди них есть и

иҗаб белән җавап бирәчәк. Чөнки Габдулла әфәндедә болар артыгы белән бар.

Ләкин назик шигърият илә, фикер вә әхлактан-фәләннән бәхәс кылган мәнзумәне аера алырлык табигый тәмйизе вә бу икене үзләренең хакыйкый кыйммәте белән күрсәтерлек әзерлеге булганнар каршында ул югарыгы сөаль һичбер вакыт ихтиляф вә мөназарәдән имин кала торган мәсьәләләрдән түгелдер. (...) шагыйрь булганда да, һәр җирдә, һәр язуында түгел, бәлки бөтен язуларының бик аз өлешен тәшкил итәчәк кадәресендә генә шагыйрь диячәкләр» [Ибраһимов Г. Татар шагыйрьләре. Б. 128].

XX йөз башы татар җәмгыятендә иң күренекле фигуралардан булган, халык сөеклесе Тукайга бирелгән бу бәягә каршы җавап биргән күпсанлы мәкаләләр пәйда була. Араларында Җ. Вәлидинең «Вакыт» газетасында дөнья күргән шул ук исемдәге мәкаләсе кебек (1913 ел, 24–26 июль, № 1257–1259) дәлилле, нигезле язмалар да бар.


وقت

«Вакыт» газетасы
Газета «Вакыт»




وقت

«Вакыт» газетасы
Газета «Вакыт»

обстоятельные, основательные публикации, например статья Дж. Валиди под тем же названием «Татарские поэты», увидевшая свет в газете «Вакыт» от 24–26 июля 1913 года (№ 1257–1259).

Валиди, например, обвиняет Ибрагимова в том, что тот хочет видеть поэзию только лишь идеальной, элитарной. Относительно татарской литературы говорит следующее: «у нас самое большое место занимает общеизвестный третий тип стихотворного творчества. Иными словами, у нас то, что называется стихотворением, служит выражению какого-нибудь мнения, если можно так сказать, служит определенной цели» [Җамал Вәлиди: әдәби-тарихи һәм тарихи-документаль җыентык. Казан: Җыен, 2010. Б. 252]. Основываясь на этом, он опровергает порядок выстраивания татарских поэтов, предложенный Ибрагимовым. Порядок Валиди: Г. Тукаев, Дэрдменд, С. Рамиев, что он и доказывает. Статья Валиди была принята татарской интеллигенцией очень положительно.

Әйтик, Вәлиди Г. Ибраһимовны шигърияткә бары тик элитар, «идеальный» итеп кенә күрергә теләүдә гаепли, татар әдәбиятына мөнәсәбәтле, болай ди: «... бездә шигырь намене мәйданга килгән асар эчендә иң күп урынны соңгы табәканың таный торган шигыре аладыр. Ягъни бездә шигырь атлы нәрсә нинди булса да бер фикергә, әйтергә яраса, бер мәсләккә хезмәт итәдер» [Вәлиди Җ. «Татар шагыйрьләре» // Җамал Вәлиди: әдәби-тарихи һәм тарихи-документаль җыентык. Казан: Җыен, 2010. Б. 252]. Шушы фикергә таянып, ул өч шагыйрьне Ибраһимов бәяләгән тәртиптә урнаштыру белән килешми: Г. Тукаев, Дәрдемәнд, С. Рәмиев итеп тезә һәм фикерен дәлилли. Вәлиди мәкаләсе зыялылар тарафыннан хуплап каршы алына.

Казанда яшәгән бу елларда (1909–1912) Г. Ибраһимовның әдәби иҗат активлыгы аеруча көчәя. Истәлекләрдән аның һәрчак эшләп утыруы, мәшгульлеге күренә. Ул үзенең революциягә кадәрге иҗатында күренекле урын тоткан



Апанаевлар номеры, Казан. Хәзерге Мәскәү урамы, 60 нчы йорт
Номера Апанаевых. Казань, ул. Московская, 60





Эш бүлмәсе
Рабочий кабинет

В годы, прожитые в Казани (1909–1912), творческая деятельность Г. Ибрагимова была особенно активной. Из воспоминаний видно, что он постоянно работал, был чем-то занят. Здесь Ибрагимов написал романтические рассказы («Яз башы» («Начало весны»), «Диңгездә» («На море»), «Йөз ел элек» («Сто лет назад»), «Сөю – сәгадәт» («Любовь – счастье»), «Уты сүнгән җәһәннәм» («Геенна без огня»), «Карак мулла» («Мулла – вор») и др.) и роман «Яшь йөрәкләр» («Молодые сердца», 1912), занимающие особое место в его дореволюционном творчестве.

Рассказ «Начало весны» является произведением, в котором в равной степени описаны природные явления и человеческие переживания, созданы невероятно сильные по выразительности пейзажи, в сюжетную канву вписаны народные легенды. Этим он и ценен. Рассказ показывает увлечение писателя немецким романтизмом, а также то, что автор видит народность литературы прежде всего в воспроизведении окружающей среды, видов родной природы,

романтик хикәяләрен («Яз башы», «Диңгездә», «Йөз ел элек», «Сөю – сәгадәт», «Уты сүнгән җәһәннәм», «Карак мулла» һ.б.) һәм «Яшь йөрәкләр» (1912) исемле романын яза.

«Яз башы» (1910) табигать күренешләрен һәм кеше кичерешләрен янәшә куеп тасвирлаган, гаҗәеп көчле табигать сурәтләре тудырган, сюжет тукымасына халык легендаларын урнаштырган әсәр буларак үзенчәлекле. Хикәя язучының алман романтизмы белән кызыксынуын, әдәбиятның миллилеген тирәлекне һәм табигатьне (туган җир рәсемен) тергезүдә, милли көнитештә еш очрый торган ситуацияләргә нигезләнүдә һәм халык легенда-риваятьләре ярдәмендә тарихи хәтерне мифлаштыруда күрүен дәлилли.

Әсәр 11 яшьлек шәкертнең, җәйге каникулга кайткач, туган авылында уздырган беренче көнен тасвирлый. Сагынышкан ана белән баланың очрашуы, малайлар белән уйнау, күл буена бару, анда табигатьнең кинәт үзгәрүе: давыл чыгу, малайларның куркып качулары, Салихның егылуы




«Яз башы» китабы. 1912

Книга «Яз башы» («Начало весны»). 1912





«Яз башы» китабы. 1987

Книга «Яз башы» («Начало весны»). 1987

основании сюжета на ситуациях, часто встречающихся в повседневной народной жизни, в мифологизации памяти посредством легенд и преданий.

В рассказе описывается первый день 11-летнего шакирда в родной деревне, куда он приехал на летние каникулы. Встреча соскучившихся матери и сына, игра с мальчишками, поход к озеру, случившаяся тогда резкая смена погоды – неожиданно поднявшийся сильный ветер, испуг мальчишек и их бег домой, падение Салиха, – все это служит выражению одной мысли: человек – дитя природы. Когда природа спокойна и добра, человеку хорошо; а когда природа показывает силу и мощь, человек тут же чувствует всю свою беспомощность. Этот рассказ, рассматривающий человека неотъемлемой частью природы, объясняющий изменения настроения и состояния тем, что он живет в одном ритме с природой, выражает философские (натурфилософские в данном случае) воззрения писателя.

Рассказ «На море» (1911) воссоздает размышления, даже ощущения романтического героя о смысле жизни

кебек үсә барган вакыйгалар бер фикерне ассызыклый: кеше – табигать баласы, табигать рәхимле һәм матур булганда, аңа рәхәт, табигать көчен күрсәтсә, кеше үзен аның каршында көчсез итеп сизә башлый. Кешене табигатьнең аерылгысыз өлеше итеп караучы, кәеф–халәт үзгәрүне шәхеснең табигать белән бер ритмда яшәвенә бәйләп аңлатучы хикәя әдипнең фәлсәфи (натурфилософик) гомумиләштерүләре белән үрелеп китә.

Романтик геройның яшәү мәгънәсе турындагы ваемын диңгез пейзажы белән янәшәлектә гәүдәләндергән «Диңгездә» (1911) хикәясе ике төрле дөнья моделе тудыра, хикәяләүче «мин»нең хисси-эмоциональ дөньясын – реаль тормышка, диңгезнең һәм күкнең иркенлеген – җир тормышына каршы куя. Шушы каршылыкта романтизм фәлсәфәсе, кеше күңеленең гомумән биеккә, яктыга, матурлыкка, иркенлеккә омтылып, ашкынып яшәве хакындагы фикер ачыклана. Герой диңгез һәм күк киңлекләрен кеше табигатендәге идеаль дөнья турындагы хыялга юл бирүче



«Диңгездә» китабы тышлыгы. 1911

Обложка книги «Диңгездә» («На море»). 1911





«Диңгездә» китабының титул бите. 1911

Титульная страница книги «Диңгездә» («На море»). 1911

на фоне морского пейзажа, рисует две модели мира: чувственно-эмоциональный мир «Я» рассказчика и реальный мир, противопоставляет свободу, бесконечность неба и широту моря земной жизни. В этом противопоставлении раскрывается философия романтизма: стремление человеческой души ввысь, к свету, красоте, свободе. Герой ощущает просторы неба и моря, которые приводят к мечтам об идеальном мире, свойственным природе человека: «Смотришь и забываешь и себя, и свой мир, мечты уводят тебя в другие миры, наполненные красотой, добром, поэзией, новую божественную вселенную» [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 1: хикәяләр (1907–1929). Б. 66].

Герой рассказа – интеллигентный юноша, недовольный городской жизнью. Он разочарован своим окружением, хочет жить в природе: «Хочется жить… тысячу, миллион лет прожить. Не той жалкой жизнью плоти, другой жизнью, красивой, святой, великой жизнью» [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 1: хикәяләр (1907–1929). Б. 69]. Желание это не имеет

итеп тоя: «Карыйсың да үзеңне, дөньяңны онытасың, хыялың гүя сине икенче дөньяларга, матурлык, изгелек белән, шигърият белән тулган яңа илаһи галәмнәргә алып китә» [Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. Т. 1: Хикәяләр (1907–1929). 66 б.].

Хикәянең герое – шәһәр тормышыннан канәгать булмаган зыялы егет, тирәлектән бизгән, аның табигать кочагында «Яшисе... мең, миллион ел яшисе килә. Ләкин моңарчы булган кызганыч тән яшәве белән түгел, башкача бер яшәү белән, матур, изге, бөек яшәү белән яшисе килә» [Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. Т. 1: Хикәяләр (1907–1929). 69 б.]. Бу теләк – милли табигатьле түгел, ул гомумән кешегә хас сыйфат кебек тәкъдим ителә. Ибраһимов укучысын кешенең илаһи табигате, аның хөр, көнкүреш ваклыкларыннан азат яшәргә омтылышы хакында уйланырга чакыра.

Диңгез буйлап ерак сәфәргә чыккан герой юлда бердәнбер улына кунакка баручы Нурый карт белән таныша, юл



«Диңгездә» китабы. 1922

Книга «Диңгездә» («На море»). 1922





«Диңгездә» әсәренә иллюстрация. Рәссам – Р. Шәмсетдинов. 1987.

Иллюстрация к рассказу «Диңгездә» («На море»). Автор – Р. Шамсутдинов. 1987

национальной окраски, а свойственно человеку в общем. Ибрагимов предлагает читателю поразмыслить над вопросами божественной природы человека, о его стремлении жить свободно и выше повседневных мелочей.

Герой, предпринявший дальнее путешествие по морю, в пути знакомится со стариком Нури, который едет в гости к своему единственному сыну, и всю дорогу слушает его увлекательные рассказы о приключениях во время хаджа его самого, отцов и дедов. В связи с тем, что на следующий день на море поднялась буря, вспоминает поверья, связанные с морем. Автор таким образом переносит на плоскость национального видения описание исторических легенд и преданий, приключений, небылиц. Писатель находит способ придания европейскому романтизму, структуре чистого романтизма национального (татарского) звучания.

Стремление использовать легенды и предания, отдельные события, сохранившиеся в народной памяти, для указания на отставание татарского общества, патриархальные

буена аның үзе, бабалары хаҗда күргәннәр хакында мавыктыргыч хикәятләрен тыңлый. Икенче көнне көчле давыл чыгу диңгез белән бәйле ышануларны искә төшерә. Шулай тарихи легенда-риваятьләр, маҗаралы, хыялый хәлләр сурәтләүне милли күзаллаулар яссылыгына күчерә. Язучы Европа романтизмы, саф романтизм структурасын милли төсмергә ману юлын таба.

Легенда-риваятьләрне, халыкның тарихи хәтерендәге аерым вакыйгаларны татар җәмгыятенең артталыгын, патриархаль тәртипләр белән яшәвен үзенә күрсәтү өчен файдалану омтылышы «Йөз ел элек» (1911), «Карак мулла» (1911) хикәяләрендә күзәтелә. Ләкин әсәрләрдәге максатларга тәңгәл рәвештә иҗтимагый-публицистик башлангычның алга чыгуы аларның әдәби-эстетик тәэсир көчен, югарыда карап үткән саф романтик хикәяләр белән чагыштырганда, шактый ук киметә.

Мәхәббәтне югары күтәрү мотивы Г. Ибраһимовның өйрәнчек хикәяләрендә үк («Гыйшык корбаннары»нда




«Карак мулла» китабы. 1912
Книга «Карак мулла» («Мулла – вор»). 1912





Галимҗан Ибраһимов.
ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 5. С. б. 10
Галимджан Ибрагимов.
ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 5. Ед. хр. 10

порядки, которым до сих пор руководствуется общество, хорошо видно в рассказах «Сто лет назад (191) и «Мулла – вор» (1911). Но в соответствии с целями произведения вывод на первый план общественно-публицистического начала ощутимо убавляет их литературно-эстетическую силу в сравнении с указанными выше чисто романтическими произведениями.

Мотив превозношения любви виден уже в ученических рассказах Г. Ибрагимова. Например, в «Гыйшык корбаннары» («Жертвы любви») утверждается, что смысл жизни, счастье – в любви. В том, что двое влюбленных не могут быть вместе, писатель обвиняет и жизнь, и правила-каноны, действующие в татарском обществе. Основная мысль произведения видна уже с первых предложений: любовь – источник счастья, удовольствия человека, смысл его жизни; потеря любви ведет к смерти. Такая же сильная, даже великая любовь божественной природы описана в объемном, 8-главном философском рассказе Г. Ибрагимова «Любовь –

яшәүнең мәгънәсе – бәхет-мәхәббәттә, дип раслана, бер-берсен яраткан ике гашыйкның бергә була алмавында язучы тормышны да, татар дөньясына хас кагыйдә-канун-нарны да гаепли. Әсәрдәге төп фикер беренче җөмләләрне укуга ук табыла: мәхәббәт – кешегә бәхет, ләззәт чыганагы, яшәү мәгънәсе ул, аны җую үлемгә илтә) күзәтелгән бул-са, шундый ук көчле, олы, илаһи табигатьле мәхәббәт аның күләмле, 8 бүлектән торган «Сөю – сәгадәт» (1911) фәлсәфи хикәясендә яшәү мәгънәсе – яшәеш кануны белән бәйләнә, үлем белән төгәлләнүче гомернең рәхәте, ләззәте, кешене рухи сафландыру, югарыга күтәрү чарасы – мәгънәсез тор-мышка нур бирүче кыйммәт дәрәҗәсенә куела. Аның герое, карт шагыйрь, гомеренең узуына хафалана, бакча, кояш сим-воллары аша кеше тормышына, яшәү тәртибенә бәя бирә. Яшәүнең чикле, фани булуы, яңадан дөньяга килү мөмкин түгеллек үкенеч сәбәбен тәшкил итә. Тормыш үзе өмет һәм өметсезлек чикләрендә тирбәлү булып аңлашыла: «Үткән хәятымны ачык күз алдыма китерсәм, ике хәл ярылып ята:



«Сөю – сәгадәт» китабы тышлыгы. 1912

Обложка книги «Сөю – сәгадәт» («Любовь – счастье»). 1912





«Сөю – сәгадәт» китабының титул бите. 1912

Титульная страница книги «Сөю – сәгадәт» («Любовь – счастье»). 1912

счастье». Здесь любовь связана со смыслом жизни, с канонами бытия, провозглашается наслаждением, удовольствием смертного человека, великой ценностью, средством, позволяющим человеку духовно очиститься, возвыситься, придать свет бессмысленной бренной жизни. Герой рассказа – старый поэт – переживает о прошедшей жизни, через символы сада, солнца оценивает судьбу человека, порядок бытия. Ограниченность, конечность жизни, мирская суета, невозможность родиться снова являются причиной сожаления. Сама жизнь объясняется переходным, неустойчивым состоянием между безнадежностью и надеждой: «Когда ясно представляю себе свою прошедшую жизнь, ясно вижу два состояния: одно – бескрайняя надежда, второе – постоянное крушение этой надежды» [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 1: хикәяләр (1907–1929)... Б. 107]. Надежды двигают жизнь, постоянно возникая у человека, заставляют его двигаться вперед, бороться за осуществление замыслов и мечтаний, удерживают его на земле.

берсе – ниһаясе булмаган өмет, икенчесе – шул өметнең бертуктаусыз җимерелә, юкка чыга баруы» [Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. Т. 1: Хикәяләр (1907–1929). Б. 107]. Шулар яшәешне хәрәкәткә китерә, бертуктаусыз пәйда булучы өметләр кешене алга барырга, уй-хыялларын тормышка ашыру өчен көрәшергә мәҗбүр итәләр, аны җирдә «тотып торалар».

Гомер ахырына җиткән, үткән көннәрен яңадан бер кат күздән кичереп, аннан матурлык, бәхет эзләүче шагыйрь йолдыз кебек янган сәгадәтләр арасында кояшка тиңе – беренче мәхәббәтен аерып чыгара. Бу мәхәббәт илаһи тасвирлана, бөек бер хис итеп күрсәтелә. Татар романтик-модернистик прозасында кабул ителгәнчә, сөйгән яр фәрештә дип атала, урыны белән синоним булган *мәләк* сүзе дә кулланыла. Шушы алым һәм «Х. туташ» турында сөйләүне сер пәрдәсе белән каплау әсәрдәге хатын-кызны символ дәрәҗәсенә куя. Хикәя ахырында герой: «Сөюдә генә чын сәгадәт!» – дип белдерә. Ике кеше арасындагы мөнәсәбәтләр булудан бигрәк, мәхәббәт хисе кеше күңеленең чистару, бөеккә һәм биеккә ашкыну халәте кебек шәрехләнә.

Әсәрнең кеше гомере, аның чикләнгәнлеге хакындагы бүлек белән башлануы карт шагыйрь сөйләгән тарихны Риза исемле егетнең мәхәббәт кыйссасы, аның тормыш мизгеле түгел, бәлки гомумән кеше язмышында очрарга тиеш булган могҗиза итеп карауны сорый. Язучы кеше гомер юлының структурасын төзи, траекториясен сыза, аны кояш чыкканнан – батканга, яшьлектән – саргаюга кадәр узган юл кебек күзаллый. Шушы юлда очрарга мөмкин бәхет – Мәхәббәт, Яшәештән килгән бүләк. Яшәеш моделендә исә, һәр кояш чыккан – кеше яши башлаган ноктадан, мәхәббәткә тап булу мөмкинлеге дә пәйда була. Хикәя үзе татар әдәбиятында фәлсәфи әсәрләр язу тәҗрибәсенең беренчеләреннән була.

Дөньяның фәлсәфи сурәте Г. Ибраһимовның «Уты сүнгән җәһәннәм» (1911) хикәясендә гомумән тормыш закончалыклары аша түгел, бәлки милли җәмгыятьтәге



Подходя к концу жизни, еще раз просматривая свои давно прошедшие дни, поэт, который ищет в них красоту и счастье, выделяет первую любовь, горящую, словно солнце, среди звезд его счастливых мгновений. Эта любовь описана как божественная, показана великим чувством. Как принято в татарской романтико-модернистской прозе, любимая называется ангелом, «фәрештә», местами употреблено синонимичное слово «мәләк». Этот прием и покрывание завесой тайны рассказа о «Х. туташ» поднимает женщину до уровня символа. В конце рассказа герой объявляет, что истинное счастье лишь в любви. Любовь здесь толкуется не столько как чувство двух людей, а скорее как состояние очищения человеческой души, стремление ее ввысь и к великому.

То, что произведение начинается с рассказа о жизни, об ее ограниченности, заставляет думать о том, что рассказ, поведанный старым поэтом, не только история любви юноши по имени Риза, не только страница его жизни, а чудо, которое должно быть в жизни каждого человека. Писатель выстраивает структуру человеческой жизни, рисует траекторию его пути: представляет его как путь солнца между восходом и закатом, от юности к старости и угасанию. Счастье, которое может встретиться человеку на этом пути – любовь, является подарком жизни. В модели жизни в каждой начальной точке – восходе солнца – появляется возможность встретить любовь. Этот рассказ является первым опытом в татарской литературе по написанию философских рассказов.

В рассказе Г. Ибрагимова «Геенна без огня» (1911) философская картина мира показана уже не с позиции общечеловеческой жизни, а через ситуацию национального общества: писатель делает основой сожаления, экзистенциальных философских переживаний низкий уровень образования в татарских медресе, тяжелый путь достижения целей для татарской молодежи. Рассказ выстроен как поток сознания основного героя – размышления вечером. Сюжет – воспоминание дневных событий жизни героя. В дом деревенского

хәл-ситуация белән бәйләп күрсәтелә: әдип татар мәдрәсәләрендәге белем дәрәҗәсенең түбән, татар яшьләренең үз максатларына ирешү юлы авыр булуны үкенеч, сызлану (экзистенциализм) фәлсәфәсенең сәбәбе ясый. Ул төп герой – хикәяләүченең кич белән уйлану агышы кебек язылган, сюжеты геройның көндез булган хәлләрне искә төшерүе рәвешен ала. Авыл мулласы Садыйк өенә үзе белән бергә укыган Гыйльман Каһиров килә. Бай малайларыннан булган Садыйкка самовар куеп, гел җәберсетелеп йөргән Гыйльман, мәдрәсәдән китеп, русча укыган. Садыйк каршысында танымаслык хәлгә килгән Гыйльманны – «яңа тарантаска җигелгән ике яхшы кара атны, әйбәт киемле кучерны, арбага ята төшеп утырган бөтенләй аурупача киенгән алтын күзлекле русны», «халыкның зур түрәсен» «земски начальникны» күреп шакката. Шулай мәгърифәтчеләр яратып кулланган каршылык калкып чыга. Мәдрәсә белеме бу каршылыкта белемсезлеккә тиң. Автор Садыйк-философ авызыннан кешеләрне ике төркемгә бүлә: язмышны үзгәртүчеләр һәм аңа буйсынучылар.

Садыйкның максаты татар егетләренең күбесенеке төсле үк: «...мин бик бай хыяллы, хәяттан бик күп нәрсә өмет итүче адәмнәрнең берсе идем. Төрле мәдрәсәләрдә укыганнан соң, үзеңне үзгәртү, мәдәниләштерү, дөнья фәннәре тәхсиль итеп, иҗтимагый эшләрнең бере артыннан йөри торган бер халык хезмәтчесе булу минем баш теләгем иде» [Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. Т. 1: Хикәяләр (1907–1929). Б. 128]. Ләкин йомшак характерлы егет «сәҗдә кыла торган идеалына» ирешми, мәдрәсә белеме белән канәгатьләнү, мулла булу – камилләшүдән, мәдәниләшүдән туктау дигән фикер белдерелә: «Бүген Каһиров килеп, аның нәкъ шул мин уйлаган юлда, шул йолдызга таба баруын, миннән күп түбән җирдән күтәрелеп, һаман егылмавын күргәч кенә, бөтен дәһшәте белән, ул хыяллар уянып, җанланып чыктылар»; «...мин, күктән, гарештән егылып, әллә кая төпкә, аска, коточкыч түбәнгә



муллы Садыка приехал его однокашник Гильман Кагиров, который всю свою бытность прислуживал шакирдом медресе, ставил самовары сынам богачей, в том числе Садыку, подвергался унижениям; после медресе учился по-русски. Садык был изумлен, увидев нового Гильмана – «русского в очках в золотой оправе, полностью одетого по-европейски, сидящего немного повалившись набок в повозке; кучера в хорошей одежде; двоих хороших лошадей, впряженных в новый тарантас»; «большого народного начальника», «земского начальника». Таким образом, выпячивается противоречие, так излюбленное просветителями. В этом противостоянии образование медресе равносильно невежеству. Автор устами Садыка-философа делит людей на две группы: те, кто переписывает свою судьбу, и те, кто подчиняется ей.

Цели у Садыка были те же, что и у большинства татарских юношей: «...я был мечтателем, тем, кто ждет от жизни очень многого. Основным желание было – после получения образования в разных медресе, обучения светским наукам стать служителем народа, занятым каким-нибудь общественным делом» [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 1: хикәяләр (1907–1929). Б. 128]. Но юноша со слабым характером не смог достичь желанного идеала и заявляет, что довольствие знаниями, полученными в медресе, бытность муллой – это значит остановиться в совершенствовании, развитии культуры. «Сегодня, когда увидел, что Гильман идет именно по тому пути, по которому хотел пройти я, именно к той звезде, к которой я стремился, поднявшись с места, намного ниже меня, и все еще не падает, все эти мечты и желания всей своей силой вновь проснулись во мне»; «...я упал с неба, с самого высокого неба и оказался внизу, в ужасающей глубине», – рассуждает Садык [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 1: хикәяләр (1907–1929). Б. 126].

Автор переводит философию в общечеловеческую плоскость. Сравнивает циклы жизни человека со временами года. В этом случае ограниченность обозначает не завершение жизни смертью, а время осмысленной, целеустремленной

киткәнмен» [Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. Т. 1: Хикәяләр (1907–1929). Б. 126].

Автор фәлсәфәне гомумән кеше тормышына күчерә. Кеше гомерен табигатьтәге ел фасыллары белән чагыштыра. Бу очракта чиклелек гомернең үлем белән төгәлләнүен түгел, бәлки максатчан яшәү вакытын белдерә. Тормышны үзгәртү вакыты – яшьлек уза, аны файдаланып калырга кирәк дигән идея, гомумән кешегә карата әйтелсә дә, мәгърифәтчел яңгырый. Шушы вакыт узганнан соңгы ара – «уты сүнгән җәһәннәм» (ул С. Рәмиевнең билгеле шигыреннән цитация итеп китерелә), бу гыйбарә хикәянең исеменә чыгарылган, күрәсең, гомумән яшәешне бәяләү өчен дә хезмәт итә. Идеалны җую, үлем киләсенә төшенү кебек үк, кешене сызлануга сала: «Үзеңнән үзең риза булмаучылык ниһаясенә җитә, рухны бөтенләй ниндидер бер коры сызлау, нинди зәһәрле бер әрнү, ачы бер истирап каплый». Кеше тормышын идеалга омтылыш кына мәгънәле ясый. Шул рәвешле, Г. Ибраһимов иҗатында да XX йөз башы татар



Газиз Гобәйдуллин (1887–1937)

Газиз Губайдуллин (1887–1937)





«Яшь йөрәкләр» китабы тышлыгы. 1913

Обложка книги «Яшь йөрәкләр» («Молодые сердца»). 1913

жизни. Проходит молодость – время изменения жизни, переписывания своей судьбы, его нужно успеть использовать. Эта идея, хоть и адресована человеку вообще, звучит вполне просветительски.

После юности следует «Геенна без огня» (цитация из известного стихотворения С. Рамиева). Это выражение вынесено в качестве заголовка рассказа, видимо, автор считает его оценкой жизни в целом. Потеря идеала, как и осознание смерти, подвергает человека страданию: «Недовольство самим собой достигает предела, дух закрывает какое-то тупое страдание, непреходящая боль, горечь». Только стремление к идеалу может придать смысл человеческой жизни. Таким образом, в творчестве Г. Ибрагимова ясно и на философской основе выразилась основная идея татарской литературы начала XX века: необходимо трудиться на ниве прогресса и национального ренессанса.

Драгоценным венцом творчества Г. Ибрагимова выступает роман «Молодые сердца» (1912) – отличается среди

әдәбиятының төп идеясе – халыкны үстерүгә, милләтне алга җибәрүгә хезмәт итү кирәклеге турындагы фикер бик ачык һәм фәлсәфи нигездә формалаша.

Г. Ибраһимов иҗатында йөзек кашы булган романтик әсәр – «Яшь йөрәкләр» романы (1912) – XX йөз башында иҗат ителгән олы эпик жанр үрнәкләре арасында фәлсәфи-психологик характеры белән аерылып тора, «мәүзугының яңалыгы, мөндәриҗәсенең киңлеге, алган каһарманнары, тел-өслүбенең яңа һәм үткенлеге белән башкалардан, шөбһәсез, аерым урын тота иде» [Габдрахман Сәгъди: фәнни-биографик җыентык / төз. Д. Заһидуллина, Ч. Гыйлаҗева. Казан: Җыен, 2008. Б. 138]. Роман басылып чыгуга, тәнкыйтьчеләр анда «фәлсәфи дулкыннар», «эчке рухи дулкыннар» (психологизм) көчле икәнлекне ассызыклыйлар. Әсәргә беренчеләрдән булып җентекле анализ ясаган, бик югары бәя биргән Газиз Гобәйдуллин романның иң мөһим сыйфаты дип шул «рухның дулкынын» сурәтләүне күрсәтә дә [Газиз Г. Яшь әдәбиятыбызда – «Яшь йөрәкләр» // Аң.



Яшь йөрәкләр» китабының титул бите. 1913

Титульная страница книги «Яшь йөрәкләр» («Молодые сердца»). 1913






«Молодые сердца» китабы. 1980

Книга «Молодые сердца». 1980

крупных эпических произведений татарской литературы начала XX века философско-психологическим характером: «Новизной темы, широтой содержания, героями, новым и проникновенным языком, несомненно, занимал совершенно особое место» [Габдрахман Сәгъди: фәнни-биографик җыентык / төз. Д. Заһидуллина, Ч. Гыйлаҗева. Казан: Җыен, 2008. Б. 138]. Как только роман был опубликован, критики подчеркнули, что в произведении сильны «философские волны», «психологизм». Газиз Губайдуллин, одним из первых детально проанализировавший произведение, очень высоко его оценивший, называет психологизм самым важным признаком романа [Газиз Г. Яшь әдәбиятыбызда – «Яшь йөрәкләр» // Аң. 1913. № 11. Б. 194]. Хусни Карим, автор обзора татарской литературы за 1913 год, называет «Молодые сердца» самым мастерски написанным произведением года [Кәрим Х. Әдәбиятта үзгәреш көтелә // Аң. 1913. № 18. Б. 314].

Сюжет романа воссоздает жизнь своей эпохи. На примере двух семей, проживающих в деревне, особенно Джалаша

1913. № 11. Б. 194]. 1913 ел татар әдәбиятына күзәтү ясаган Хөсни Кәрим аны елның иң оста әсәре дип атый [Кәрим Х. Әдәбиятта үзгәреш көтелә // Аң. 1913. № 18. Б. 314].

Сюжет бирелеше белән роман үз чоры тормышын тергезә. Авылда яшәгән ике күрше гаилә, бигрәк тә Җәләш мулла, аның балалары Зыя, Сабир мисалында, язучы «аталар» һәм «балалар» каршылыгын тудыра, аталары дөрес дип тапкан яшәү рәвешенең балалар омтылышларына тәңгәл килмәве хакында сөйли. Бу каршылыкны әдәбият теориясенә караган «Әдәбият кануннары» хезмәтендә Г.Ибраһимов үзе үк күрсәтеп уза, аны искелек һәм яңалык көрәше дип билгели. Ләкин бу көрәш нәтиҗәсендә «балаларның» омтылышлары тормышка ашмаган кебек, «аталар» төзегән тәртипле көнитеш тә җимерелә. Әйтерсең, язучы көрәшнең, башланган вакытында, зур нәтиҗәләргә китермәскә мөмкин икәнлеген сөйли. Шул ук вакытта тарих мәйданына чыккан яшь буынның зур максатлар куеп, тормышны тамырдан үзгәртергә омтылып яшәвен ассызыклый. Шуңа күрә дә иң беренче рецензия язучылардан булган Җ. Вәлиди романга милли идея белдерелү ягыннан якын килә һәм үзе идеаль һәм реаль геройлар итеп караган Зыя белән Сабирны әдипнең «хыялында ялтыраган йолдызлар» [Вәлиди Җ. «Яшь йөрәкләр» // Вакыт. 1913, 28 февраль] дип атый. Ибраһимов татар тормышын бары тик яшьләр, «йолдызлар» гына үзгәртә алачакны ассызыклый.

Гомумән, әсәр бик тә үзенчәлекле, татар прозасы фонында яңалык булган күп хасиятләргә ия. Милли әдәбиятта психологик роман жанрын ачып җибәрүче тәүге әсәрләрдән санала [Миңһаҗева Р.Ә. Галимҗан Ибраһимов иҗатында руссочыл традицияләр. Б. 330]: психологизм тудыру алымнары буларак файдаланылган аң агышы, төшләргә күпләп мөрәҗәгать итү, кешенең озак вакытка сузылган чиктәш халәтен тасвирлау аны реальлек чикләреннән алып чыга. Әсәрдә ерак фон төсендә һәрвакыт «Алла – кеше» мөнәсәбәте катнаша. Геройлар – мөселманнар, әсәрдә үзәк геройлардан булган Зыяның Алла белән сөйләшүләре әһәмиятле



муллы, его детей Зии и Сабира, писатель показывает проблему отцов и детей, говорит о том, что образ жизни отцов совершенно не соответствует стремлениям детей. Это противоречие сам же Г. Ибрагимов определяет в своем труде «Каноны литературы», посвященном теории литературы, обозначая его борьбой нового со старым. Но, как и то, что в результате такой борьбы не воплощаются в жизнь стремления детей, так и рушится порядок жизни, выстроенный отцами. Писатель будто говорит о том, что борьба не принесет больших результатов, причем уже тогда, в самом начале. Одновременно с этим подчеркивает стремление молодого поколения, только вышедшего на историческую сцену, жить, ставя перед собой большие цели, стремясь перестроить всю жизнь, проведя коренные преобразования. Именно поэтому один из первых авторов рецензий на роман Дж. Валиди подходит к анализу произведения с позиции передачи национальной идеи и героев, обозначенных им как реальный Сабир и идеальный Зия, называет «звездами, мелькающими в мечтах писателя» [Вәлиди Җ. «Яшь йөрәкләр» // Вакыт. 1913, 28 февраль]. Г. Ибрагимов подчеркивает здесь, что жизнь татарского общества могут изменить только молодые люди «звезды».

В целом произведение достаточно своеобразное, имеет множество новых признаков, выгодно отличающих его на фоне татарской прозы начала XX века. Считается первым в татарской литературе, положившим основу развитию жанра психологического романа [Миңһаҗева Р.Ә. Галимҗан Ибраһимов иҗатында руссочыл традицияләр // Галимҗан Ибраһимовның иҗат дөньясында. Казан, 2012. Б. 330]: использованные как приемы передачи психологизма поток сознания, обращение к снам, описание длительного пограничного состояния человека выводят произведение за границы реальности. В виде дальнего фона в произведении всегда участвует отношение «Бог – человек». Герои здесь – мусульмане, и разговоры одного из основных героев романа – Зии – с Богом занимают важное место. В финале произведения

урын били. Зыя үлгәннән соң, әсәрнең финалында Кәрим мәхдүмнең зиратта сөйләгән сүзләре кыска гына дин фәлсәфәсен кабатлап уза: яшәү һәрвакыт үлем белән тәгалләнә – бу илаһи канун; без җир йөзендә мөсафирлар гына – билгесез мәңгелеккә китәбез; тормышың башкалар өчен никадәр кыйммәтле, үлемең шулкадәр хәсрәтле; Алладан киләбез һәм аңа әйләнеп кайтабыз. Соңгысы Коръәннән аллюзия ярдәмендә кабатлана: «Ялгыз... Ялгыз бер юаныч бар: «Инна лилләһи вә инна иләйһи раҗигун!». Яшәүнең ахыргы максаты ислам динендәгечә аңлатып узыла. Шуның янәшәсенә язучы тормыштагы максатны урнаштыра: «Ул, яшим, ди иде. Яшәве гомум өчен иде. Ул «алгы көненең күгендә өмит йолдызының ялтыравын...» күрә вә бөтен вөҗүде белән шуңа таба ашкына иде... Аның җаны бөек әмәлләр белән тулы булып, күңелендәге:

– Язмыш уң биреп, гомер вафа итсә, шул халыкның авыр көненә бер үзгәреш бирермен, томанлы вә караңгы хәятына бер нур тудырырмын!... – дигән өмете тышка бәреп чыгарга якынлаша иде» [Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. Т. 2: Яшь йөрәкләр. Казакъ кызы. Б. 316]. Шулай татар тормышын үзгәртү – халыкның томанлы һәм караңгы яшәешенә нур бирү дип шәрехләнә.

Язучы геройлар тарихын кешенең тирәлек, җәмгыять, язмыш белән мәңгелек каршылыктагы яшәешенә мисал дәрәҗәсенә күтәрә. Кеше мохиттә яши, мохиттән азат була алмый дигән фикер әсәрнең башлангыч уйланмасын тәшкил итә. Дөрес, чыгарма төсендә әдип бик сирәк кешеләрнең үз язмышларын үзгәртә алуын әйтә, ләкин боларның гадәттән тыш кеше икәнлекләрен дә искәртергә онытмый. Романда сурәтләнгән геройлар язмышы мохиттән азат булырга омтылыш белән бәйләнгән. Мохит чикләреннән чыккан, аны җиңгән шәхесләр генә җәмгыятьне, милләтне үзгәртә ала дигән фәлсәфә хасил була.

Г. Ибраһимов геройлар язмышына салган, бүген шактый каршылыклы кабул ителә торган фәлсәфә дә үзенчәлекле: мохитнең тар рамкаларыннан бары тик түбәнгә төшеп кенә



слова, произнесенные Каримом махдумом над могилой Зии, в обобщенном виде повторяют религиозно-философскую составляющую романа: жизнь всегда завершается смертью – это божественный закон; мы лишь странники на этой земле – уходим в неизвестную вечность; насколько твоя жизнь ценна для других, настолько сильна горечь твоего ухода; все мы от Бога и все вернемся к Нему. Последнее утверждение повторяется в виде аллюзии к Корану: «Одиноко... есть одно лишь утешение: «Инна лилләһи вә инна иләйһи раҗигун!». Конечная цель существования объясняется в духе ислама. Рядом с этим писатель размещает цель земной жизни: «Он говорил, живу. Жизнь его была для всех. Он видел сияние звезды надежды в будущем и всем своим существом стремился к ней... Душа его была полна великих стремлений, а надежда его – если судьба будет благосклонна, а жизнь позволит, то хоть как-то попробую изменить тяжелую жизнь народа, зажечь свет в его темной и туманной жизни – билась в нем, стремясь вырваться наружу» [Ибраһимов Г. Әсәрләр: 8 томда. Т. 2: Яшь йөрәкләр. Казакъ кызы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. Б. 316]. Таким образом, изменение жизни татарского общества интерпретируется как придание света его темной, мрачной жизни.

Писатель возносит жизнь героев своего произведения до модели жизни человека в вечном противоречии с обществом, судьбой. Человек живет в обществе, он не может быть свободным от влияния своего окружения – эта начальный замысел произведения. Правда, в виде исключения писатель говорит о том, что очень немногим удается изменить свою судьбу, при этом отмечает, что это были необычные, даже невероятные люди. Жизнь героев, описанных в романе, связана со стремлением избавиться от влияния окружения. Формируется философское заключение: только те личности, сумевшие вырваться из своей среды, победившие ее, могут изменить общество, нацию.

Философия, заложенная Г. Ибрагимовым в жизнь и судьбу своих героев, воспринимаемая сегодня далеко

котылырга мөмкин (чагыштыру өчен: Ш. Камал мохиттән азат булу мөмкин түгеллекне исбатласа, Г. Исхакый моны үз тирәлегеңнән югарырак күтәрелеп башкарырга мөмкин дигән фикерне куәтли). Язучы моның төрле вариантларын берәм-берәм укучы күз алдыннан уздыра. Мохит мәҗбүриятеннән беренче булып котылган герой – Сабир крестьян булып китә. «Минем үз малым, үз дөньям булыр. Минем алдар хыялым тараер. Мин үз эшемне эшләп, үземә һәм үземнең ирегемә үзем хуҗа булырмын. Азат булырмын. Миңа шул җитә дә» [Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. Т. 2: Яшь йөрәкләр. Казакъ кызы. Б. 60], – ди ул. Мәдрәсәдә укыган мулла малае өчен җир эшкәртеп көн күрү, укымаган кызга өйләнү – үз дәрәҗәсеннән, мохитеннән түбән төшү булса, Сабир өчен ул бәхеткә ирешү юлына әверелә.

Җәләл мулла өчен котылу – югалу, читкә китү, качу булып чыга. «...көне килер, мин дә бу тормышны бәреп ташлармын һәм дөньяга да, Фәхригә дә үземнең кем икәнемне күрсәтермен», – дигән Мәрьям өчен хөкем ителү, сөрген мохиттән аеручы сәбәпкә әйләнә. «...бу мохиткә, бу сәнгать белмәс тупас табигатьләр эченә ялгыш ташланганмын» дип уйлаучы Зыяны үлем газаплардан азат итә. Физик үлем белән чикләнмичә, әдип Сәлим язмышында «рухи үлем» вариантын күрсәтә. Мохит белән ризалашу – иманны-идеалны югалту – кайберәүләр өчен үлемгә тиңләштерелә.

Әсәрдә кешегә каршы куелган мохит – күпмедер күләмдә трансцендентальлеккә ия төшенчә. Ул кешене әйләндереп алган тирәлеккә дә, җәмгыятькә дә тәңгәл түгел. Мәгънәдәш сүз төсендә язучы «язмыш»ны файдалана. Романның иң башында китерелгән, әсәргә сер өстәүче ике төш – төш эчендәге төш – шушы мәгънәне аңлауга юнәлеш күрсәтә. Төштә Мәрьям киләчәктә булачак хәлләрне: Зыяның солдатка алынуын, ире – Фәхри булганны, үзенең аны үтерүен, Зыя белән тиңсез мәхәббәтләрен, шуны югалтуларын күрә. Димәк, болар – язмышка язылган, булырга тиеш хәлләр. Төш эчендә авторның алда әйтеләчәк фәлсәфи фикерләре дә белдерелә. Төшнең беренче сәхифәсендә



неоднозначно, весьма своеобразна: избавиться от тесных рамок среды можно только опустившись ниже (для сравнения: Ш. Камал доказывает невозможность избавления от влияния среды: Г. Исхаки же придерживается мысли, что избавление возможно только путем поднятия выше своей среды). Писатель предлагает вниманию читателя несколько вариантов такого поведения. Герой, избавившийся от предписаний окружения, становится крестьянином: «У меня будет свое имущество, свой мир. Обманчивая мечта станет меньше. Но я буду занят своим делом, стану хозяином самому себе и своей свободе. Свободным стану. Мне и этого достаточно» [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 2: Яшь йөрәкләр. Б. 60], – говорит Сабир. Если для молодого человека с образованием медресе жить землей, жениться не необразованной девушке считается падением вниз, то для Сабира это становится способом достижения счастья.

Для Джаляла муллы избавление – это бегство, исчезновение, уход. Для Марьям, которая надеялась, что «...придет день, и я отброшу эту жизнь, и миру и Фахри покажу, кто я на самом деле», – это приговор и ссылка. Зию, рассуждающего в духе «Я ошибочно оказался среди этих грубых, не знающих искусство натур», освобождает от мук смерть. Не ограничиваясь смертью физической, на примере судьбы Салима писатель показывает смерть духовную: согласие с окружением, отречение от своих идеалов для некоторых равноценно прекращению земного существования.

В произведении окружение, противопоставленное человеку, в какой-то степени обладает трансцендентностью. Это не только окружающий человека мир, и не общество. В качестве синонима писатель использует понятие «судьба». Два сна, приведенные в начале произведения и придающие ему загадочность, сон внутри сна, показывают путь к пониманию этого смысла. Во сне Марьям видит грядущие события: вот Зию призвали в армию, вот ее мужем стал Фахри, она его убила, неравная любовь с Зией, все эти потери. Значит, это судьба, а события должны случиться. Через сон

дөньяны караңгылык, «гомуми үлем тарафыннан берьюлы» йотылудан курку каплый – аны азан тавышы юкка чыгара. Яшәүнең чиклелеге китергән газапны ислам өйрәтүе җиңә, ди автор. Бу фикер Зыяны күмү вакыйгасы белән кисешә.

Төштә китерелгән, Мәрьямнең револьвер алганнан соңгы халәтен тасвирлау тагын бер фикерне ныгыта: язмышны үзгәртү теләге – иң көчле теләк, иң олы омтылыш. Бу алга таба күп геройлар тормышы мисалында кабатланачак.

Өченче фикер мәхәббәтнең – олы бәхет, яраткан кешенең Алла дәрәҗәсендәге кадерле зат булуын белдерә. Мәрьям белән Зыя арасындагы мәхәббәтне гайре табигый дәрәҗәдә, олы һәм көчле хис буларак сурәтләп, автор һәрдаим аның кешегә бәхет китерүен ассызыклап килә.

Романда милли фәлсәфәгә шактый киң урын бирелә, ул Зыя образы белән бәйле. Романтик герой Зыя музыкага гашыйк, көйне нечкә тоемлаучы итеп сурәтләнә. Үз заманында Г. Гобәйдуллин Зыя образына карата «гыйсъянчы» төшенчәсен куллана. Тәнкыйтьче Зыяның «зәгыйфь,



Г. Ибраһимовны кулга алу хакындагы хәбәрнең күчермәсе. 1913 ел, 19 апрель.

ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 2. С. б. 10

Копия известия об аресте Г. Ибрагимова. 19 апреля 1913.

ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 2. Ед. хр. 10





Г. Ибраһимовны кулга алу хакындагы 369 санлы карарның күчермәсе. 1913. ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 2. С. б. 11

Копия постановления № 369 об аресте Г. Ибрагимова. 1913. ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 2. Ед. хр. 11

также выражаются философские размышления автора, которые будут высказаны позднее. В первой части сна мир накрывает тьма, страх всеобщей смерти, его разгоняет звук азана. Автор говорит, что исламское учение помогает победить страдания от осознания конечности жизни. Эта мысль созвучна событиям похорон Зии.

Описание состояния Марьям во сне, когда она взяла в руки револьвер, подкрепляет еще одну мысль автора: желание изменить судьбу – самое сильное из человеческих желаний, самое сильное стремление. Эта мысль повторяется в дальнейшем неоднократно на примере жизни многих героев.

Другая мысль: любовь есть великое счастье, а любимые дороги нам, как дорог и важен Бог в жизни человека. Описывая любовь между Марям и Зией как великую силу, даже противоестественную, автор постоянно подчеркивает, что любовь дарует человеку счастье.

В романе большое внимание уделяется национальной философии в связи с образом Зии. Романтичный герой

хатыннар табигатьле мәңгелек трагедия әһеле» булуын да җәмгыять-мохиттән күрә: «Ул 1905 елларның буранлы инкыйлаблары арасыннан чыккан адәм, ул еллар аны инкыйлабчы ясамыйча, матурлык сөюче, «музыкателист» ясаганнар. Анда матурлык коры матурлык кына түгел, гыйшык, милләт вә табигыя берлә бергә манчылган рухи бер матурлыктыр» [Газиз Г. Яшь әдәбиятыбызда – «Яшь йөрәкләр». 194 б.]. Бу бәядә татар җәмгыятенең нечкә күңелле, рухи бай, талантлы яшьләр үстереп җиткерүе дә, аларга үз сәләтләрен милләт файдасына хезмәткә куярлык шартлар тудырылмау да ассызыклана.

Г. Ибраһимов татар милләтенең хәлен шулай ук мохит чикләреннән чыга алмаган бердәмлек буларак бәяләп уза. Зыя исә – шушы язмышны, мохитне үзгәртү юлын тапкан кеше. Татарда сәнгатьне, мәхәббәтне тыю мохит кысалары, чикләүләре кебек аңлашыла. Милли фәлсәфә болай шәрехләнә ала: үсештән туктаган милләтләрне сәнгать уята, кузгата, алга җибәрә.



Г. Ибраһимовның төрмәгә озатылуы турындагы документның күчермәсе. 1913 ел, 19 апрель. ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 2. С. б. 10а

Копия документа о направлении Г. Ибрагимова в тюрьму. 19 апреля 1913. ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 2. Ед. хр. 10а





21 нче санлы белдерүнең күчермәсе. 1913. ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 2. С. б. 13

Копия объявления № 21. 1913. ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 5. Ед. хр. 13

Зия описывается как человек тонкой души, влюбленный в музыку, тонко чувствующий мелодию. В свое время Г. Губайдуллин использовал понятие «бунтарь» по отношению к Зие. «Слабый, вечный трагический герой женской сущности», это обусловлено влиянием общества, окружения, считает критик: «Это человек, рожденный бурным революционным 1905 годом, но эти годы сделали его не революционером, а любителем красоты, «музыкателистом». Красота Зии не просто красота внешняя, а красота духа, соединенная с влюбленностью, национальностью и естественной природой» [Газиз Г. Яшь әдәбиятыбызда – «Яшь йөрәкләр»... Б. 194]. В этой оценке видно, что татарское общество уже смогло вырастить поколение духовно богатых, тонких, талантливых молодых людей, но еще не создало условия, чтобы они могли всем своим талантом служить во имя прогресса своего народа.

Г. Ибрагимов также оценивает татарскую нацию как общность, неспособную преодолеть ограничения своей среды. Зия – человек, нашедший путь изменения судьбы, среды

Шулай итеп, бу әсәрдә инде мәгърифәтчелеккә һәм романтизмга хас структураларның тамырдан үзгәрүе, трансформацияләнүе аермачык. Милли үзаң үсү, милләт язмышы өчен борчылу татар әдәбиятын колачлап ала да милләткә хезмәт итү, әдәби сүзнең көченә, акыл-фикергә ышану һ.б. мотивларны беренче планга этәрә. Әлеге материалда гареб һәм шәрык фәлсәфәсенең үзара мөнәсәбәтләре, «сөйләшү», диалогка керүе, раслау яки кире кагу да ачык билгеләнә. Мондый синтез фәлсәфи яктан татар әдәбиятын баета, тирәнәйтә, милли кыйбла эзләү проблемасын киң мәйданга чыгара.

Бу әсәрләр Г. Ибраһимовны татар прозаикларының алгы сафында баручы итеп таныта; алар халык телендә дә, әдәби җәмәгатьчелек тарафыннан да җылы бәяләнәләр. Менә шундый бер вакытта ул Казаннан китәргә карар кыла.

Каюм Мостакаев истәлекләренә караганда, Киевта укытучылык урыны булырга мөмкин икәнлекне ишеткәч, Г. Ибраһимов бик теләп риза була һәм 1912 елның көзендә



Каюм Мостакаев
(1883–1974)

Каюм Мустакаев
(1883–1974)





Галимҗан Ибраһимов.
Киев. 1912.
ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 5. С. б. 12

Галимджан Ибрагимов.
Киев. 1912.
ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 5. Ед. хр. 12

при помощи силы искусства. Ограничения искусства, любви, принятые в татарском обществе, понимаются автором как рамки среды. Национальная философия может быть выражена таким образом: именно искусство пробуждает двигаться вперед нации, которые остановились в своем развитии.

Таким образом, это произведение явственно показывает трансформацию просветительских и романтических структур. Размышления об укреплении национального самосознания, беспокойство о судьбе народа охватывают всю татарскую литературу того времени и выдвигают на первый план мотивы служения народу, веру в силу художественного слова, разума и др. На этом материале ясно определяются взаимоотношения западной и восточной философии, их диалог, утверждение и опровержение тех или иных положений. Такого рода синтез обогащает татарскую литературу, расширяет ее проблематику, выводит на литературную арену проблему поиска ориентиров в деле национального прогресса.

шунда китеп бара. Биредә аңа берничә татар студентына татар теле һәм әдәбияты укытырга, 3–4 балага шулай ук татарча башлангыч белем бирергә тәкъдим ясала, үзенә дә гимназия аттестаты алырга әзерләнү өчен шартлар тудырыла. Ул хосусый укытучы белән белемен күтәрүне дәвам итә, университет профессорлары укый торган ачык лекцияләргә йөри, «Казакъ кызы» романын өр-яңадан язарга керешә.

Безнең фикеребезчә, Г. Ибраһимовның беренче һәм икенче тапкыр да Казаннан Киевка китеп бару сәбәпләреннән берсе дә «Татар шагыйрьләре»нең татар җәмәгатьчелегендә үзенә карата каршылыклы караш уятуы булырга мөмкин. Чөнки аның Тукай иҗатына берьяклы тискәре мөнәсәбәте үзенең аралашу даирәсе белән дә конфликтка кертә. Бу фаразны Г. Баттал [Баттал Г. Миражга алданган язучы // Галимҗан Ибраһимов: мәкаләләр, истәлек-хатирәләр. Б. 343–344], М. Гайнетдинов [Гайнетдинов М. Г. Ибраһимов һәм Ф. Кәрими // Галимҗан Ибраһимов һәм хәзерге заман:



Киев шәһәре күренеше. XX йөз башы.
Вид города Киев. Начало XX века





Галимҗан Ибраһимов. Киев. ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 5. С. б. 7
Галимджан Ибрагимов. Киев. ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 5. Ед. хр. 7

Вышеназванные произведения обеспечили место писателю Г. Ибрагимову в авангарде татарских прозаиков; они были тепло встречены и простыми читателями, и литературным сообществом. И именно в это время Г. Ибрагимов решил покинуть Казань.

Судя по воспоминаниям Каюма Мустакаева, Г. Ибрагимов как только узнал о возможности занять место учителя в Киеве, тут же решился и осенью 1912 года уехал. Здесь ему было предложено преподавать татарский язык и литературу нескольким татарским студентам и 3–4 детям дать начальное татарское образование, да и для самого Ибрагимова были созданы все условия для подготовки к получению аттестата гимназии. Он продолжает самообразование с помощью частного учителя, посещает открытые лекции университетских профессоров, снова возвращается к написанию романа «Казакъ кызы» («Дочь степи»).

По нашему мнению, одна из причин отъезда Г. Ибрагимова из Казани в Киев – это негативная реакция татарского

туына 115 ел тулуга багышланган фәнни конфереция материаллары. Б. 58] хезмәтләрендә дә очратабыз.

Киевтан Казанга юлланган мәкаләләре Г. Ибраһимовның уку-укыту мәсьәләләре белән шөгыльләнүен ташламавы турында сөйли. Әйтик, «Мәктәп» журналының 1913 елгы 1 (гыйнвар) санында «Мәктәптә әдәбият» исемле мәкаләсе басыла. Биредә аның тел-әдәбият укытуны бербөтен система итеп санавы күренә: ул бер-берсенә ялганган, үсә баручы биш өлешне имла (фонетика), сарыф (морфология), нәхү (синтаксис), әдәбият кануннары һәм әдәбият тарихы кебек тезә. Фикер болай дәлилләнә: «Мәгълүм ки, әдәбият әсәрләрдән, әсәрләр җөмләләрдән, җөмләләр сүзләрдән, сүзләр тавышлардан ясала. Димәк, тел вә әдәбиятның иң кечкенә кисәге, иң саф вә җиңел мәртәбәсе – сүзләр ясый торган тавышлардыр. Шуңа күрә дә тел вә әдәбияты тәгълимиянең бисмилласы балага сүзләрне тәшкил итә торган тавышларның кагыйдәдә ничек сурәтләнүеннән, ягъни имлядан башлана...» [Ибраһимов Г. Мәктәптә әдәбият //




«Мәктәп» журналы
Журнал «Мектеп»



общества на статью «Татарские поэты» и противоречивая реакция на ее автора. Односторонняя отрицательная оценка творчества Г. Тукая, данная Г. Ибрагимовым в указанной статье, приводит к конфликту даже с собственным кругом общения. Эта гипотеза высказана в трудах Г. Баттала [Галимҗан Ибраһимов: мәкаләләр, истәлек-хатирәләр / төз. Р. Акъегет. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. Б. 343–344], М. Гайнутдинова [Галимҗан Ибраһимов һәм хәзерге заман: тууына 115 ел тулуга багышланган фәнни конференция материаллары. Казан: Фикер, 2002. Б. 58].

Статьи, направляемые Г. Ибрагимовым в Казань из Киева, говорят о том, что он не бросил заниматься вопросами образования. Скажем, в № 1 журнала «Мәктәп» («Школа») за январь 1913 года была опубликована статья Г. Ибрагимова «Мәктәптә әдәбият» («Литература в школе»). Здесь видно, что он считает преподавание языка и литературы единой системой, выстраивает структуру дисциплины из пяти взаимосвязанных частей: фонетики, морфологии, синтаксиса, канонов литературы и истории литературы. Обоснование таково: «Как известно, литература состоит из произведений, произведения – из предложений, предложения – из слов, слова – из звуков. Следовательно, самая маленькая, самая чистая часть литературы и языка – звуки, которые образуют слова. Именно поэтому основа, азы теории литературы и языка начинаются с правил произношения этих звуков, то есть с фонетики…» [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 5: әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933). Б. 70].

Что касается истории литературы, примечательно, что Г. Ибрагимов довольно широко трактовал это предмет: «В татарском народе принято так, если что есть под названием литература, то это все – и прошлое, и настоящее – нужно объять и изучить. Где корни татарского языка, каковы его начала, пути развития? Где начало татарской литературы, под воздействием каких сил она развивалась? Какие эпохи пережила в своем развитии? Каковы

Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. Т. 5: Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933). Б. 70.].

«Әдәбият тарихы» дигәндә, Г. Ибраһимовның бу предметны шактый киң күзаллавы игътибарга лаек: «татар дигән кавемдә әдәбият исеме белән ни нәрсә булса, ул шуның һәммәсен – үткәнен-хәзергесе илә кочаклап ала да тикшерергә тотына. Татар теленең тамырлары кайда, аның башы, тәкямел юллары ничек? Татар әдәбиятының башлануы ни рәвештә, нинди куәтләр тәэсирендә? Ул нинди дәверләр кичергән? Бу дәверләрнең көчле фәгъгальләре [*факторлары*], сәбәпләре, нәтиҗәләрениләр? Бу әдәбиятта нинди мәсләкләр, нинди әдипләр, шагыйрьләр ни эшләгән вә эшли? Аларның әсәрендә баш хасиятләре, имтиязлары, мәртәбәләре нидән гыйбарәт? Менә шул сөальләрне алдына куя да, фәнни рәвештә тикшереп, җаваплар бирә» [Ибраһимов Г. Мәктәптә әдәбият. Б. 72].

Чыннан да, бу елларда татар уку йорларында тел-әдәбиятны бергә бәйләп, биш баскычлы укыту тәртибе


مكتبده ادبيات.

«Мәктәп» журналында басылган «Мәктәптә әдәбият» (1913) мәкаләсеннән фрагмент

Фрагмент статьи «Мәктәптә әдәбият» («Уроки литературы в школе») (1913) на страницах журнала «Мектеп»





«Мәктәп» журналында басылган «Мәктәптә әдәбият» (1913) мәкаләсеннән фрагмент

Фрагмент статьи «Мәктәптә әдәбият» «Уроки литературы в школе») (1913) на страницах журнала «Мектеп»

основные факторы этих эпох, причины, результаты? Какие писатели, поэты работали и работают сейчас в этой литературе? В чем заключается основная мысль их произведений? Вот эти вопросы ставит перед собой и, изучая в научном плане, дает ответы» [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 5: әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933). Б. 72].

Действительно, в те годы установился порядок слитного, 5-ступенчатого преподавания татарского языка и литературы в татарских учебных заведениях [Заһидуллина Д.Ф. Әдәбият кануннары һәм заман (татар әдәбият нәзариясенең барлыкка килүе һәм үсеш баскычлары). Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. Б. 122–129].

Среди статей, присланных из Киева, немало с общественно-политической направленностью. В сообщениях «Мәдрәсә чуалулары» («Беспорядки в медресе»), «Канлы төһмәт» («Кровавое обвинение»), «Канлы төһмәтнең нәтиҗәсе» («Результат кровавого обвинения»), опубликованных в 1913 году

урнаша [Заһидуллина Д.Ф. Әдәбият кануннары һәм заман (татар әдәбият нәзариясенең барлыкка килүе һәм үсеш баскычлары). Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. Б. 122–129].

Киевтан җибәрелгән мәкаләләр арасында иҗтимагый-сәяси характерлы язмалар шактый күп. «Мәдрәсә чуалулары», «Канлы төһмәт», «Канлы төһмәтнең нәтиҗәсе» кебек 1913 елны «Йолдыз»да, «Аң»да басылган хәбәрләрдә татар шәкертләренең мәдрәсәләрне үзгәртү таләбе белән чуалышлары, кабат әйләнеп кайтып, бәяләнә, Киевта патша хөкүмәте яһүд Мендель Бейлиска каршы оештырган суд процессы яктыртыла, көнкүреш җинаятенең патша хакимияте тарафыннан милләтара мөнәсәбәтләр яссылыгына күчерелүе билгеләнә. Әлеге язмалар Г. Ибраһимовның сәяси чыныга баруы турында да сөйли.

Г. Ибраһимов Киев университетындагы «Мөселман студентлар түгәрәге»нең җыелышларына йөри, һәм шул сәбәпле полиция күзәтүе астына эләгә. 16 студент белән бергә аны 1913 елның 17 апрелендә кулга алалар,



Киев университеты күренеше. XX йөз башы.
Киевский университет. Начало XX века





Г. Ибраһимовның Киев төрмәсеннән чыккач Х. Еникеев белән төшкән фотосы.1913. ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 5. С. б. 16

Фотография Г. Ибрагимова с Х. Еникеевым после освобождения из киевской тюрьмы. 1913. ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 5. Ед. хр. 16

в газете «Йолдыз», журнале «Анг», заново переосмысливаются беспорядки шакирдов с требованием изменения порядка преподавания в медресе, освещается судебный процесс над евреем Менделем Бейлисом в Киеве, организованное царским правительством, отмечается, что бытовое преступление было перенесено на межнациональную плоскость царским правительством. Эти публикации свидетельствуют о политической закалке Г. Ибрагимова.

В Киеве Г. Ибрагимов посещал заседания кружка мусульманских студентов, по этой причине был взят под надзор полиции. 17 апреля 1913 года его вместе с 16 студентами арестовали, комнату обыскали и среди бумаг обнаружили прокламацию, оставленную для Халиуллы Еникеева, и конверт с брошюрами, написанными против царского режима [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 9: хатлар һәм документлар. Б. 230–246]. Об этом было сообщено в татарской печати (газеты «Кояш», «Вакыт»), что вызвало определенный резонанс в татарском обществе.

бүлмәсендә тентү ясала, кәгазьләре арасында Хәлиулла Еникиевкә дип калдырылган прокламация һәм патша хөкүмәтенә каршы язылган брошюролар салынган конверт табыла [Опись рукописей и книг частной библиотеки Г. Ибрагимова, отобранных во время обыска 17 апреля 1913 г. в г. Киеве // Галимҗан Ибраһимов. Әсәрләр: тугыз томда. Т. 9: Хатлар һәм документлар. Б. 230–246]. Бу хакта татар матбугатында («Кояш», «Вакыт» газеталарында) хәбәрләр басыла, әлеге вакыйга татар җәмгыятендә билгеле бер резонанс тудыра.

Киев губерна төрмәсенең ялгыз камерасында Г. Ибраһимов 13 июньгә кадәр утыра, әмма, сәяси яктан ышанычсыз саналып, 1917 ел инкыйлабларына кадәр даими полиция күзәтүе астында яши. Азат ителеп, июньнең 20 ләрендә инде ул Казанга кайтып җитә, берничә көннән туган авылына юнәлә. Һәр җәй Галимҗанның печән әзерләргә кайтуы, гаиләсенә булышуы хакында шулай ук истәлекләрдә әйтелгән.



Киев шәһәрендә тентү вакытында Г. Ибраһимовның шәхси китапханәсеннән алынган кулъязмалары һәм китаплары турындагы 10 нчы санлы беркетмәнең күчермәсе. Беренче бите. 1913.
ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 2. С. б. 23

Первая страница копии протокола № 10 обыска комнаты Г. Ибрагимова в Киеве с указанием изъятых из его личной библиотеки книг и рукописей. 1913.
ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 2. Ед. хр. 23





10 нчы санлы беркетмә күчермәсенең икенче бите. 1913.
ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 2. С. б. 23

Вторая страница копии протокола № 10. 1913.
ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 2. Ед. хр. 23

В одиночной камере Киевской губернской тюрьмы Г. Ибрагимов просидел до 13 июня, но, будучи «политически неблагонадежным», жил под постоянным надзором полиции до революции 1917 года. После освобождения он уехал в Казань, уже в 20-х числах июня. Через несколько дней направился в родную деревню. В воспоминаниях также указано, что Галимджан каждое лето приезжал в родные края, помогал семье во время сенокоса.

К. Мустакаев упоминает письмо Г. Ибрагимова, отправленное из Казани, и пишет, что, оценивая прошедшие события, писатель говорил: «Каюм, нисколько не жалею, что мое проживание в Киеве закончилось таким образом. Те события, заключение стали для меня школой. По правде говоря, весьма полезной школой. У меня глаза раскрылись. Многие вещи и людей я начал видеть лучше, понимать вернее...» [Галимҗан Ибраһимов: мәкаләләр, истәлек-хатирәләр. Б. 87].

Действительно, после киевских событий наблюдается поворот в творчестве писателя: усиление социальных

К. Мостакаев Г. Ибраһимовның Казаннан җибәргән хатын телгә ала, һәм анда, булып узган вакыйгаларны бәяләп, болай дип язуын искә төшерә: «Каюм, Киевтагы хәятымның шулай очлануына аз гына да кайгырмыйм. Андагы эшләр, утырып чыгу минем өчен бер мәктәп булды. Дөресен әйткәндә, файдалы мәктәп. Күзем ачыла төште. Күп нәрсәне һәм кешеләрне дөресрәк күрә, дөресрәк таный башладым...» [Каюм Мостакаев. Киевта // Галимҗан Ибраһимов: мәкаләләр, истәлек-хатирәләр. Б. 87].

Чыннан да, Киев вакыйгаларыннан соң әдип иҗатында борылыш – социаль мотивларның, хезмәт кешесенең хәлен сурәтләү омтылышының көчәюе күзәтелә: «Карт ялчы» (1913), «Көтүчеләр» (1913), «Табигать балалары» (1914), «Мәрхүмнең дәфтәреннән» (1914) кебек хикәяләр һәм, аеруча Беренче рус революциясендә татар халкы вәкилләренең катнашуын сурәтләгән «Безнең көннәр» романы (беренче редакциясе, 1914) язучы иҗатындагы әнә шул үзгәрешләрнең ачык мисаллары булып тора.



«Карт ялчы» китабы. 1925

Книга «Карт ялчы» («Старый батрак»). 1925





«Карт ялчы» китабына иллюстрация. 1969. Рәссам – Г. Усманов

Иллюстрация к книге «Карт ялчы» («Старый батрак»). 1969. Автор – Г. Усманов

мотивов, стремления описать, передать состояние человека труда. Рассказы «Карт ялчы» («Старый батрак»), «Көтүчеләр» («Пастухи»), «Табигать балалары» («Дети природы»), «Мәрхүмнең дәфтәреннән» («Из тетради покойного»), особенно роман «Безнең көннәр» («Наши дни», первая редакция была опубликована в 1914 году), описывающий участие представителей татарского народа в первой русской революции, являются ярким примером указанного поворота.

Рассказ «Старый батрак» (1912) воссоздает образ простого деревенского человека. Рассказчик Сафар описывает встречу со старым и немощным Шигабеком, всю жизнь тяжело трудившегося, тем не менее жившего полуголодным и постоянно подвергавшимся унижениям, он высказывает свое отношение к этому. Тем самым автор обращает внимание читателя на социальное противоречие. В рассказе «Пастухи» вместе с описанием чрезвычайно трудных жизненных условий простого люда нашли место и размышления

«Карт ялчы» (1912) хикәясендә автор гади кеше, авыл кешесе образы тудыра, картайган һәм көчсезләнгән Шаһибәк картның авыр хезмәт белән, ач-ялангач һәм рухи түбәнсетелеп яшәвен хикәяләүче – мин ролен башкаручы яшь егет Сәфәрнең шушы хәлләргә мөнәсәбәт белдерүе рәвешендә корып, укучы игътибарын социаль каршылыкка юнәлтә. «Көтүчеләр» (1913) хикәясендә, гади кешеләрнең гадәттән тыш авыр көнитешен тасвирлау белән янәшә, әдәбият, сәнгать, фәннең кешелек җәмгыятендәге роле, иҗтимагый вазифасы турында уйланулар урын алган.

«Көтүчеләр» – үзенең символик табигате белән татар әдәбият белемендә иң зур бәхәсләр уяткан әсәрләрдән. Символ дәрәҗәсендә кулланылган әсәр исеме татар галимнәре тарафыннан төрлечә шәрехләнеп, үзенчәлекле бәяләнде. Туры мәгънәсе сюжетка нигез булган, үз заманы татар тормышыннан чиклəп алынган сурәт белән бәйле. Төп герой Вахит һәм аның әтисе Әптерәш карт – авылда иң ярлы кешеләр, көтүчеләр. Коточкыч авыр тормыштан



«Табигать балалары» кульязма дәфтәренең тышлыгы.
ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 1. С. б. 34

Обложка рукописной тетради «Табигать балалары» («Дети природы»).
ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 1. Ед. хр. 34





«Табигать балалары» әсәренең кульязмасы.
ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 1. С. б. 34

Рукопись произведения «Табигать балалары» («Дети природы»).
ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 1. Ед. хр. 34

о роли литературы, искусства, науки в человеческом обществе, их социальной функции.

По своей символической природе рассказ «Пастухи» – одно из тех произведений, которое вызвало оживленные споры в татарском литературоведении. Название рассказа было интерпретировано татарскими учеными по-разному. Прямое значение названия связано с сюжетом, основой которого стала реальная жизнь татар своего времени. Основной герой Вахит и его отец Аптряш старик – самые бедные люди деревни, пастухи. Молодой парень, дошедший практически до сумасшествия от тяжелейшей жизни, не сумев смириться со злобным отношением людей, ушел из деревни, оставив своего больного отца переходить из дома в дом, из рук в руки.

Писатель связывает изменения в Вахите с увиденным им изображением Иисуса, которое висело на стене больницы. Тяга к миру изобразительного искусства была настолько сильной, что молодой человек перешагнул религиозные и общественные границы: оставшись в городе, получил

акылдан язу хәленә килгән яшь егет, кешеләрнең усал мөнәсәбәтен күтәрә алмыйча, авырып яткан әтисен өйдән-өйгә йөрергә калдырып, авылдан качып китә.

Язучы Вахиттагы үзгәрешләрне шифаханә диварына эленгән Гайсә сурәте белән бәйли. Рәсем дөньясына тартылу шулкадәр көчле була ки, егет иҗтимагый һәм дини чикләүләрне атлап уза: шәһәрдә калып белем ала, гаилә кора, балалар үстерә. Бер яктан, күңеле рәсем сәнгате үрнәкләре урнаштырылган залларга тарткан Вахитның кичерешләре гомер буе Әптерәш карт һәм аның кебек меңләгән кешеләрнең газаплы тормышы тирәсендә әйләнә. Икенче яктан, егет үз тормышын гына яхшы якка үзгәртүгә ирешә, Әптерәш карт исә кеше өстендә ач-ялангач көн күрергә дучар. Вахит аңа ярдәм итәр өчен берни дә эшләми. Шуннан чыгып, А. Яхин әсәр исемендә «ярдәмне кемнәндер көтеп торучылар» мәгънәсен аерып чыгара [Яхин А.Г. Әдәбият: унберьеллык мәктәпнең 6–7 класслары өчен дәреслек-хрестоматия. Казан: Мәгариф: 1993. Б. 28–29].



«Көтүчеләр» китабы. 1922

Книга «Көтүчеләр» («Пастухи»). 1922





«Көтүчеләр» китабыннан фрагмент. 1922

Фрагмент книги «Көтүчеләр» («Пастухи»). 1922

образование, создал семью, растит детей. С одной стороны, переживания Вахита, всю жизнь стремившегося в залы с картинами, связаны с Аптряшом и теми тысячами людей в таком же положении. С другой стороны, молодой человек сумел изменить только свою жизнь, его отец, Аптряш, вынужден жить в голоде и нищете. Вахит не делает решительно ничего, чтобы облегчить ему жизнь. Исходя из этого, А.Г. Яхин видит в названии рассказа такой смысл: «те, кто ждет помощи от других» [Яхин А.Г. Әдәбият: Унберьеллык мәктәпнең 6–7 класслары өчен дәреслек-хрестоматия. Казан: Мәгариф, 1993. Б. 28–29].

Писатель показывает две картины, которые исключительно взволновали героя: на одной изображен Иисус, на другой – старик, чем-то напоминающий отца Вахита. Размышления молодого человека развиваются в следующем направлении: «Вещай, Иисус! Ты много думал о несчастье людей, о том, как их можно вывести к счастью; скажи, к какому мнению ты пришел, какой результат получил?

Язучы героен чиктән тыш дулкынландырган ике картинаны ассызыклап күрсәтә: аның берсендә Гайсә пәйгамбәр, икенчесендә исә әтисен хәтерләткән карт тасвирланган. Егетнең уйлары исә мондый юнәлештә үсә: «Сөйлә, Гайсә! Син адәмнәрнең бәхетсезлеге, аларны рәхәтлеккә чыгару турында күп уйладың; әйт, нинди фикергә, нинди нәтиҗәгә килдең? Кан түгү бетәчәкме? Милләте, дине башка булганлык өчен дошманлашуларның бер чиге булачакмы? Әйт, боларга ирешүдә син күп уйлавыңның нәтиҗәсендә нинди юлны кыскарак таптың?» [Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. Т. 1: Хикәяләр (1907–1929). Б. 185]. Әлеге монологлар, аң агышы әсәрдә тулы бер катлам хасил итә. Шуларны күздә тотып Р. Ганиева әсәр исемен халык (көтү) белән идарә итүче, аңа юл күрсәтеп, әйдәп баручы мәгънәсендәге «көтүче»-коткаручы сүзе белән бәйли [Ганиева Р.К. «Тирән тамырлар» (Галимҗан Ибраһимов иҗаты мәктәптә) // Мәгърифәт. 1997, 14 март]. Язучы үзе дә Әптерәш картның үлгән хәбәрен ишеткән Вахит уйларында шушы мәгънәне калкытып куя: «Сезнең юлыгыз хата түгелме? Сез, үзегезгә тапшырылган көтүнең җәфалануы өчен үзегезнең мәсьүл икәнлегегезне игътираф итеп, адәм балаларына башка юллар эзләргә, башка көтүчеләр, башка илчеләр табарга чакырмыйсызмы?» [Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. Т. 1: Хикәяләр (1907–1929). Б. 187], хикәянең соңгы җөмләләрендә кабат шушы мәгънәгә әйләнеп кайта. Алай гына да түгел, таныла торган деталь – абзарга, маллар арасына ташлану (Гайсә пәйгамбәр дөньяга килгән урын кебек үк, Әптерәш карт та мал абзарында җан бирә) детале аша кабат Гайсәне һәм Әптерәш картны янәшә куя. Әлеге образларны Вахит рәсемнәрдән «укыган» сорау берләштерә: «Дөньяң шундый матур, без ник болай бәхетсез соң, Ходаем!!» [Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. Т. 1: Хикәяләр (1907–1929). Б. 188]. Хикәядә әлеге сорауга төрле җавап вариантлары тоемлана.

Ассоциацияләр остасы булып җитешкән Ибраһимов-язучы, шулай да, хикәянең төп фикерен барлау өчен ачкыч



Прекратится ли кровопролитие? Кончится ли когда-нибудь вражда только из-за разной религиозной или национальной принадлежности? Скажи, какой путь ты выбрал самим коротким?» [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 1: хикәяләр (1907–1929). Б. 185]. Такие монологи – потоки сознания – образуют в произведении целый пласт. Имея их в виду, Р.К. Ганиева трактует название рассказа «Пастухи» как «пастырь» [Ганиева Р.К. «Тирән тамырлар» (Галимҗан Ибраһимов иҗаты мәктәптә) // Мәгърифәт. 1997, 14 март]. Сам писатель также подчеркивает это значение в раздумьях Вахита, услышавшего новость о смерти Аптряша, своего отца: «Не ошибочен ли ваш путь? Игнорируя свою ответственность за страдания паствы, доверенной вам, не призываете ли род человеческий искать другие пути и других пастырей?» [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 1: хикәяләр (1907–1929). Б. 187]. Более того, писатель вводит узнаваемую деталь – хлев, и посредством ее опять сопоставляет Иисуса и старика Аптряша: Иисус был рожден в хлеву, а Аптряш старик распрощался там с жизнью. Эти образы объединяет вопрос, который Вахит почерпнул из произведений искусства: «Мир так прекрасен, а мы так несчастны, Господи. Почему?» [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 1: хикәяләр (1907–1929). Б. 188]. В рассказе есть намеки на несколько вариантов ответов на означенный вопрос.

Мастер ассоциаций Г. Ибрагимов все же оставляет ключ к пониманию основной мысли рассказа. Обычно в его произведениях идея связана с каким-нибудь противоестественным событием, именно это явление, заставляющее вздрогнуть, служит формированию философии писателя. В этом произведении так же. Событие, которое ни в какой системе – религиозной, моральной, общечеловеческой – никак не может получить положительную оценку, противоестественное событие, уход Вахита, бросившего своего отца, показывает путь к формированию философии автора: «Человеку подвластна только своя жизнь, изменить можно лишь свою жизнь». Эта мысль в рамках татарского возрождения начала XX века кажется настолько удивительной, что

калдыра. Гадәттә, аның әсәрләрендә идея гайре табигый хәл-вакыйга белән бәйләнеп китә, нәкъ менә шушы сискәндерерлек күренеш язучы фәлсәфәсен формалаштыруга хезмәт итә. Бу әсәрдә дә шулай. Мәдәни, дини булсын, әхлакый, гомумкешелек булсын, бернинди гадәт-кагыйдәләргә сыймый торган хәл – Вахитның әтисен ташлап китүе авторның фәлсәфәсен формалаштыруга юл күрсәтә. «Тормыш-яшәештә һәр кеше бары тик үз шәхси тормышын гына үзгәртә ала» дигән фәлсәфә XX йөз башы татар яңарышы кысаларында шулкадәр гаҗәп тоела күрсәң, шуның өчен дә язучы аны шик астына ала, капма-каршы фәлсәфи фикерләр дә тоемланырлык әдәби структура төзи.

1913 елның 16 сентябрендә Ибраһимов яңадан Казанга килә, Ә. Хәсәни чакыруын кабул итеп, «Аң» журналына җаваплы сәркатип булып эшкә урнаша.

Әхмәтгәрәй Хәсәни (1888–1933) – нашир, драматург, тәрҗемәче, 1907 елны китап басмаханәсе оештыра, 1909 елдан ул «Гасыр» исеме белән атала. «Шәрык клубы»н



Әхмәтгәрәй Хәсәни хатыны Зәйнәп белән

Ахметгирей Хасани с женой Зейнап





Әхмәтгәрәй Хәсәнинең Зәйнәпкә язган хаты

Письмо Ахметгирея Хасани жене Зейнап

и сам писатель сомневается в ней, выстраивает структуру, допускающую противоположные философские заключения.

16 сентября 1913 года Г. Ибрагимов вновь приехал в Казань. По приглашению А. Хасани устроился ответственным секретарем журнала «Анг».

Ахметгирей Хасани (1888–1933) – издатель, драматург, переводчик. В 1907 году организовал типографию, которая с 1909 года известна под названием «Гасыр». Один из организаторов «Восточного клуба». С 15 декабря 1912 года начал выпускать журнал «Анг», который регулярно выходил до марта 1918 года дважды в месяц. Решение об издании журнала было принято в доме семьи Хасани 26 июля 1912 года. Рассчитывалось, что журнал объединит представителей татарской молодежи, выступающих за национальное возрождение. Это событие отражено в доносе Т. Мамлиева от 31 июля 1912 года: «Татарский литературный кружок собрался 26 июля в доме Хасани на Евангелистской улице. Собрание решило в скором времени начать издавать

оештыручыларның берсе. 1912 елның 15 декабреннән «Аң» журналын чыгара башлый, ул 1918 елның мартына кадәр айга ике тапкыр басылып килә. Журнал чыгару карары Хәсәниләр йортында 1912 елның 26 июлендә кабул ителә, ул татар яшь милләтчеләрен берләштерәчәк басма буларак күзаллана. Вакыйга Т. Мамлиевның 1912 елның 31 июлендә язылган доносында түбәндәгечә теркәлеп калган: «Татар әдәбият түгәрәге июльнең 26-сында Евангелистовский урамда Хәсәнев йортында җыелды. Җыелыш тиз көннән калын рус журналлары шикелле бер әдәби, сәяси журнал чыгарырга карар бирде. Бу журнал яшь татар милләтчеләрен берләштерергә тиеш булачак. Журнал Хәсәневлар исеменнән чыгачак. Җыелышта булган кешеләр: Гәрәй, Барый Хәсәневлар, Фуат Туктаров, Габдулла Гыйсмәтуллин, Габдулла Тукаев, Фатих Әмирхан, учитель Гафур Коләхмәтов, Исмәгыйль Аитов, Гыйльметдин Шәрәф, Галимҗан Ибраһимов, Габдеррахман Кәрәм» [Мансуров Г. Татар провокаторлары. М., 1927. Б. 51].




«Аң» журналын чыгару өчен тупланган кәгазьләр папкасы. 1912 ел, 12 сентябрь

Собрание бумаг по ходатайству Ахмедгирея Хасани об издани в г. Казани журнала «Анг». 12 сентября 1912





Фуад Туктаров (1880–1938)
Фуад Туктаров (1880–1938)

литературный, политический журнал по типу русских толстых журналов. Этот журнал должен будет объединить молодых татарских националистов. Журнал будет издаваться от имени Хасани. В собрании присутствовали: Гирей, Бари Хасановы, Фуат Туктаров, Габдулла Гисматуллин, Габдулла Тукай, Фатих Амирхан, учитель Гафур Кулахметов, Исмагил Аитов, Гильмутдин Шараф, Галимджан Ибрагимов, Габдрахман Карам» [Мансуров Г. Татар провокаторлары. М., 1927. Б. 51].

«Литературный, научный, политический и общественный журнал с иллюстрациями», название которому дал Г. Тукай, с 15 декабря 1912 года и до марта 1918 года объединял вокруг себя самых талантливых представителей татарского народа того времени: с журналом сотрудничали Ф. Амирхан, Г. Ибрагимов, Г. Рахим, Г. Губайдуллин, Г. Кулахметов, Х. Атласи, Дж. Валиди, Ш. Камал, Ф. Агиев, С. Сунчелей, С. Рахманкули и др. В журнале вместе с художественными произведениями постоянно печатались статьи, посвященные

Исемен Г. Тукай тапкан «әдәби, фәнни, сәяси вә иҗтимагый рәсемле журнал» 1912 елның 15 декабреннән 1918 елның мартына кадәр айга ике тапкыр басыла килеп, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Г. Рәхим, Г. Гобәйдуллин, Г. Коләхмәтов, Һ. Атласи, Җ. Вәлиди, Ш. Камал, Ф. Агиев, С. Сүнчәләй, С. Рахманколый кебек иң талантлы иҗатчыларны үз тирәсенә берләштерә. Журналда даими рәвештә, әдәби әсәрләр белән беррәттән, фәнни, сәясәт, икътисад мәсьәләләренә багышланган мәкаләләр, сәнгать, театр, музыка өлкәсендәге яңалыкларга күзәтүләр, тарих һәм дин, мәгариф һәм тәрбия, матбугат торышы, аерым шәхесләргә кагылышлы язмалар тәкъдим ителә. «Аң» авторлары татар укучысын дөнья мәдәниятендә барган процесслар белән таныштыруны махсус башкара, исеменә тугры калып, журнал татар кешесенең аңын, дөньяга карашын үзгәртүгә хезмәт итә.

Г. Ибраһимов 1909 елда Казанга күченеп килүгә Ә. Хәсәни белән дустанә мөнәсәбәтләр урнаштыра. Аның күпчелек китаплары Хәсәниләрнең «Гасыр» нәшриятында басыла.



Гафур Коләхмәтев (1881–1918)

Гафур Кулахметов (1881–1918)





«Гасыр» нәшрияте бинасы

Здание издательства «Гасыр»

научным, политическим, экономическим проблемам; обзоры на новые произведения музыки, изобразительного искусства, спектакли; публикации, освещающие исторические события, состояние религиозной жизни, образования, периодической печати. Авторы журнала «Анг» стремились знакомить татарского читателя с процессами в мировой культуре, служить расширению сознания, миропонимания татарского человека.

Г. Ибрагимов установил дружеские отношения с А. Хасани еще в 1909 году, как только приехал в Казань. Многие его книги были напечатаны в типографии А. Хасани «Гасыр». В письме от 3 января 1913 года из Киева, адресованном Х. Кайбышеву, Ибрагимов упоминает о том, что Хасани и Ф. Амирхан приглашали его к официальному сотрудничеству в журнале [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 9: хатлар һәм документлар. Б. 69].

Как только начал работать в журнале, Г. Ибрагимов добился внесения некоторых изменений в «Анг». Уже в

1913 елның 3 гыйнваренда Х. Кайбышевка Киевтан язган хатында, Ибраһимов Хәсәнинең һәм Ф. Әмирханның үзен «Аң» журналына рәсми язышырга чакыруын телгә ала [Галимҗан Ибраһимов. Әсәрләр: тугыз томда. Т. 9: Хатлар һәм документлар. Б. 69].

«Аң»да эшли башлауга, Ибраһимов журналга кайбер үзгәрешләр кертүгә ирешә. Үз җаваплылыгында чыгарылган беренче санда ук ул «Фәнни вә фәлсәфи мәсьәләләр», «Хатын-кыз галәменнән» дигән бүлекләр ача. Беренче бүлеккә язылган кереш сүзендә фәнни материаллар урнаштыруның мөһимлеге ассызыклана, икенче бүлек алдынгы татар хатын-кызлары хакында мәгълүмат бирү, татар җәмгыятендә хатын-кызның урыны, хәле кебек актуаль мәсьәләне тикшерү бурычы куя. Бу санда – «Милләтне ничек аңлыйсыз?», алдагысында «Яңа елда ни телисез?» дигән анкеталар белән эшләү башлана. Чыннан да, күрсәтелгән юнәлешләрдә журнал нык үзгәреш кичерә: аның битләрендә көн кадагына



«Аң» журналы
Журнал «Анг»







«Аң» журналында басылган «Хатын язмышы» (1913) мәкаләсеннән фрагментлар

Фрагменты статьи «Хатын язмышы» («Судьба женщины», 1913) на страницах журнала «Анг»

первом номере, в котором ответственным секретарем был Г. Ибрагимов, возникли рубрики: «Научные и философские вопросы», «Из мира женщин». В предисловии к первой рубрике подчеркнута мысль о необходимости печатать научные материалы, а основная задача второй рубрики – дать сведения о передовых татарских женщинах своего времени, исследовать такие актуальные вопросы, как место и роль женщины в татарском обществе. В первом номере была размещена анкета «Милләтне ничек аңлыйсыз?» («Как вы понимаете нацию?»), в следующем – «Яңа елда ни телисез?» («Чего вы ждете от нового года?»). Действительно, в указанных направлениях журнал претерпел серьезные изменения: к обсуждению актуальных вопросов дня был привлечен довольно большой круг читателей.

Не ограничиваясь работой в журнале, Г. Ибрагимов вместе с Габдельбари Батталом составил хрестоматию в качестве пособия для уроков орфографии, синтаксиса,

суккан мәсьәләләр турында сөйләшүгә киң катлау укучылар тартыла.

Журналда эшләү белән чикләнмичә, Г. Ибраһимов Габделбарый Баттал белән бергәләп төрле сыйныфларда орфография, морфология, синтаксис, язу дәресләрендә гамәли файдалану өчен материаллар тупланмасы буларак хрестоматия төзи, ул 1914 елда «Яңа әдәбият» исеме белән басылып чыга. Китап җиде бүлектән тора: «Туган як», «Җәй», «Көз», «Кыш», «Табигатьтәге могҗизалы хәлләр», «Бәйрәм», «Иртә». Монда Г. Исхакый, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан прозасыннан өзекләр, Ш. Камал, Ф. Кәрими, Закир Һади, Ф. Агиев, Г. Тукай, Дәрдемәнд, С. Рәмиев, М. Гафури шигырьләре урын ала.

Г. Ибраһимов уку-укыту эшенә кагылышлы һәр материалында диярлек татар уку йортларында укытуны әхлак тәрбиясенә буйсындыру белән килешмәвен белдерә: «Әдәпле бала ... дигән бер черек нәзария безнең актык кыюлыгыбызны каплый, соң көчебезне сүндерә – безне, һичбер



Г. Ибраһимов белән Габделбари Баттал тарафыннан төзелгән «Яңа әдәбият» дәреслеге. 1914

Учебник «Яңа әдәбият» («Новая литература»), составленный Г. Ибрагимовым и Г. Батталом. 1914







Г. Ибраһимов төзегән «Яңа әдәбият» дәреслегенең беренче (1918) һәм икенче (1919) китаплары

Первая (1918) и вторая (1919) книги учебника Г. Ибрагимова «Яңа әдәбият» («Новая литература»)

чистописания в разных классах. Хрестоматия была издана в 1914 году под названием «Яңа әдәбият» («Новая литература»). Книга состоит из семи разделов: «Туган як» («Родной край»), «Җәй» («Лето»), «Көз» («Осень»), «Кыш» («Зима»), «Табигатьтәге могҗизалы хәлләр» («Чудесные явления природы»), «Бәйрәм» («Праздник»), «Иртә» («Утро»). В сборник включены отрывки из произведений Г. Исхаки, Г. Ибрагимова, Ф. Амирхана, стихи Ш. Камала, Ф. Карими, Закира Хади, Ф. Агиева, Г. Тукая, Дэрэменда, С. Рамиева, М. Гафури.

Практически в каждом материале, посвященном вопросам образования, Г. Ибрагимов высказывает свое несогласие с тем, что в учебных заведениях процесс обучения полностью подчинен морально-этическому воспитанию: «Какое-то гнилое создание под гордым названием «воспитанный ребенок»... уничтожает нашу смелость, гасит наши последние силы – нас, тех, кто не сделал ничего предосудительного, грешного, заставляет краснеть перед всеми и каждым, стоять, потупив взгляд... учит немоте, рабству» [Ибраһимов

гөнаһ эшләмәдегебез хәлдә, һәркем алдында кызарып, түбән карап торырга ... телсезлеккә, коллыкка өйрәнергә мәҗбүр итә» [Ибраһимов Г. Тәрбиядә хөррият вә шәхсыять нигезләре // Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. Т. 6: Публицистика (1907–1932). Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. Б. 106]. «Тәрбиядә хөррият вә шәхсыять нигезләре» дигән («Аң» журналының 1914 елгы 6 санында (20 март) басыла) мәкаләсендә ул шушы традициягә каршы куела алырлык нигез хакында уйлана. Мәктәпнең төп максатын түбәндәгечә билгели: «мәктәпнең баш максаты укучыларны шәхси вә иҗтимагый хәятка әзерләмәк һәм аларга тормыш көрәшендә егылып тапталмас өчен зарур булган куәтне бирмәктер» [Ибраһимов Г. Тәрбиядә хөррият вә шәхсыять нигезләре. Б. 108]. Милли тәрбия дигән төшенчә кулланып, аны «шәхси тапкырлыкка, тәвәккәллеккә, инициативага сәләтлелек, омтылыш һәм ихтыяр көчләрен үстерү» белән бәйли.

Журналда эшләгән вакытта Г. Ибраһимов тагын бер зур проект нигезли – «Аң»ның абунәчеләре өчен «Альбом



«Альбом (сәнаигы нәфисә мәҗмугасы)»ның тышлыгы. 1915
Обложка «Альбома изобразительных искусств». 1915





«Альбом (сәнаигы нәфисә мәҗмугасы)»ның титул бите. 1915
Титульная страница «Альбома изобразительных искусств». 1915

Г. Әсәрләр. Т. 6: публицистика (1907–1932). Б. 106]. В статье «Тәрбиядә хөррият вә шәхсыять нигезләре» («Основы свободы и личности в воспитании»), опубликованной в журнале «Анг» 20 марта 1914 года (№ 6), Г. Ибрагимов задумался об основах, которые можно противопоставить этой сложившейся традиции. Он определяет цель школы таким образом: «подготовка учеников к личной и общественной жизни и обеспечение их такой силой, которая позволит им устоять в жизненной борьбе» [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 6: публицистика (1907–1932). Б. 108]. Используя понятие «национальное воспитание», он говорит о личной находчивости, способности к риску, инициативе, развитии стремлений и силы воли.

Во время работы в журнале Г. Ибрагимов основал еще один крупный проект – сборник под названием «Альбом» для абонентов журнала «Анг» (сборник произведений изобразительного искусства). По техническим причинам издание было осуществлено только в феврале 1915 года.

(сәнаигы нәфисә мәҗмугасы)» исеме белән рәсем сәнгате әсәрләре тупланган альбом әзерли (басма техник сәбәпләр аркасында соңга калып, 1915 елның февралендә генә басылып чыга). Аның сүз башында Ибраһимовның әдәбият-сәнгать хакындагы уйланулары-эзләнүләре чагылыш таба.

Хезмәттә башлап «нәрсә ул сәнгать әсәре» дигән сорауга җавап бирелә. «Хәят вә табигатьнең төрле күренешләре һәм андагы көчләрнең бәрелешүеннән туган төрле хәдисләр безнең йөрәгебездә бер тәэсир, бер хис, бер мәгънә уйгаталар. Менә шул хис, шул мәгънә, шул тәэсир йөрәктә кала алмый, ул дөньяга чыгарга сорый, табигать бу сорауга җавап бирә: сәнгатькярләр аны башкаларда да шул тәэсирне уйгатачак бер рәвеш белән ифадә кыйлалар – шагыйрь, әдип бер поэма, бер хикәя вә бер роман яза, шул юл белән йөрәгендәге мәгънә вә хисләр, сүзләр аркылы, җанлы сурәткә әйләнәләр дә, язучының күңелендәге мәгънәне тере, гәүдәле кыяфәт белән укучының күз алдына китереп бастыралар, бу сурәт, бу кыяфәт шагыйрь вә



«Альбом (сәнаигы нәфисә мәҗмугасы)»ннан

Из «Альбома изобразительных искусств»





«Альбом (сәнаигы нәфисә мәҗмугасы)»ннан

Из «Альбома изобразительных искусств»

В предисловии к этому альбому отразились соображения Г. Ибрагимова по поводу литературы и искусства.

В первую очередь в статье дан ответ на вопрос «Что есть искусство?». «Разные виды природы и жизни, явления, ряженные от взаимодействия их сил, производят на нас определенное впечатление, пробуждают в наших сердцах разные чувства, рождают новые смыслы. Вот эти чувства, эти смыслы не могут остаться лишь в наших сердцах, а просятся в мир, и природа отвечает этому желанию: люди искусства выражают их с той точностью, что эти чувства и мысли возникают у зрителя, кто видит произведения, с той же силой и мощью. Поэты, писатели создают поэму, рассказ или же роман, таким образом сокровенные чувства и мысли их сердец посредством слов достигают совершенно одушевленного вида и во всех красках предстают перед читателем…» [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 6: публицистика (1907–1932). Б. 179]. В этом определении чувствуются отзвуки обозначенных Г. Ибрагимовым ранее воззрений на природу творчества.

әдип күңелендәге мәгънә вә тәэсирне укучының йөрәгенә бирә...» [Ибраһимов Г. Альбом мөнәсәбәте белән бер-ике сүз // Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. Т. 6: Публицистика (1907–1932). 179 б.]. Бу билгеләмәдә элегрәк белдерелгән карашларның яңгырашын тоймау мөмкин түгел.

Сәнгатьне табигый ихтыяҗ: берәүнең үзендәге хис һәм тәэсирне башкаларга җиткерү, икенчеләрнең аны тыңлау теләге белән бәйләсә дә, Ибраһимов сәнгать әсәрендә фикер, мәгълүмат булуны кире какмый. Аныңча, әсәр турыдан-туры тормыш-чынбарлык тәэсирендә дөньяга килергә мөмкин, анда тормыш-чынбарлык үзенә якын төстә сурәтләнә ала. Ләкин турыдан-туры күчереп куела икән – бу сәнгать әсәре дип бәяләнергә тиеш түгел. «Хәят вә табигатьтәге көчләрнең бәрелешүеннән вөҗүдкә килгән нинди булса бер хәдисә сәнгатькярнең йөрәгендә бер тәэсир уйгата. Бу тәэсир туачак сәнаигы нәфисәнең орлыгыдыр». Ләкин бу орлык «сәнгатькярнең рухани галәме тарафыннан тәрбия кыйлынып», «йөрәктән күтәрелеп, хыял



«Альбом (сәнаигы нәфисә мәҗмугасы)»ннан

Из «Альбома изобразительных искусств»





«Альбом (сәнаигы нәфисә мәҗмугасы)»ннан

Из «Альбома изобразительных искусств»

Даже если связывать искусство с природной потребностью одних выразить обуреваемые их чувства и переживания, а других – слушать и внимать, Г. Ибрагимов не отрицает наличия мысли, информации в произведениях искусства. По его мнению, произведение может стать прямым результатом впечатления от жизненной действительности и эта жизнь может быть описана как есть. Но если события и явления жизни переносятся в произведение искусства напрямую, без изменений, это не может называться искусством. «Явления, рожденные от взаимодействия сил природы и жизни, производят на нас определенное впечатление, пробуждают в сердцах людей искусства определенные чувства, рождают новые смыслы. Эти чувства – семена будущих произведений». Эти семена, «получив достойный уход со стороны духовного составляющего автора, поднимаются от сердца ввысь, к грезам, там, под благодатным солнцем мечты растет, развивается, наконец, созревает в мире грез, затем остается только выйти в мир». Здесь Ибрагимов раскрывает основу, суть искусства: «искусство

дөньясына менә, аның яхшы һавасы, якты кояшы астында сабак чыгара, яфрак яра, ниһаять, хыял дөньясында бөтен сурәте белән эшләнеп тәмам була да, аның тик дөньяга чыгасы кала». Шушы урында Ибраһимов сәнгатьнең асылын ачыклый, «ул – сәнгатькярнең рухани галәменең матди сурәттә гәүдәләнүеннән гыйбарәт» [Ибраһимов Г. Альбом мөнәсәбәте белән бер-ике сүз. Б. 187].

Г. Ибраһимов фикеренчә, сәнгать әсәре булу өчен тормышны күрсәтү генә җитми, шул тормышның рухын, җанын ачарга кирәк. Бер үк вакытта сәнгать милли максатларга да хезмәт итә ала: «Бер милләтнең сәнаигы нәфисәсендә асыл табигате ачылып җитә ала. Тик сәнаигы нәфисә генә бер кавемнең эчке йөзе, аның табигатенең маһиятен ача ала» [Ибраһимов Г. Альбом мөнәсәбәте белән бер-ике сүз. Б. 191]. Борынгы Мисыр, Юнан тарихын, Италиянең Яңарыш дәверен – барысын да сәнгать әсәрләре аша аңлап-төшенеп, өйрәнеп була, ди. Һәм татар әдәбиятының милләткә хезмәте мәсьәләсенә кагыла:



«Альбом (сәнаигы нәфисә мәҗмугасы)»ннан

Из «Альбома изобразительных искусств»





«Альбом (сәнаигы нәфисә мәҗмугасы)»ннан

Из «Альбома изобразительных искусств»

состоит в материальном воплощении идеального мира человека искусства» [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 6: публицистика (1907–1932). Б. 187].

По мнению Г. Ибрагимова, чтобы стать произведением искусства, мало отразить только явления окружающей действительности, нужно открыть дух, душу этой жизни. Одновременно искусство может служить и национальным целям: «В художественном искусстве народа может полностью раскрыться его природа, суть. Лишь искусство способно показать истинное лицо, натуру народа» [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 6: публицистика (1907–1932). Б. 191]. Историю древнего Египта, Рима, итальянское Возрождение – все это можно изучить через их искусство. Далее затрагивает вопросы служения литературы татарской нации: «Ее [татарскую нацию] спасет от полного исчезновения, от поглощения бурным культурным потоком других народов только собственное искусство, способное сыграть на самых тонких струнах ее души», «люди искусства станут единственным спасителем

«Аны – яныбыздан шаулап аккан мәдәният диңгезенә кереп, татар өчен мәңге юк булуыннан, мәдәни халыкларга йотылуыннан фәкать аның үз йөрәгендәге эчке тамырларын тибрәтәчәк милли сәнгать кенә алып калыр», «сәнгатькярләребез дә миллиятнең бердәнбер азыгы булырлар» [Ибраһимов Г. Альбом мөнәсәбәте белән бер-ике сүз. Б. 199–200].

Шулай итеп, Г. Ибраһимов аңлатуында әдәбиятның сурәтләү объекты – язучының рухи дөньясы; тормыш-чынбарлык исә – авторга тәэсир иткән, иҗат эшенә этәргән бер көч. Инде сәнгатьнең вазифасы мәсьәләсенә килсәк, ул милләт рухын, халык йөрәген ачып бирүдән гыйбарәт.

«Аң»да тулысынча үз тәртипләрен урнаштыра башлаган Г. Ибраһимов 1914 елның 13 февралендә кинәт кенә кабат Киевка китеп бара. Бер айга якын Киевта тора, 14 мартта Одесса аша Севастополь, Ялта шәһәрләрендә туктап, Сухумига барып чыга, 17 марттан 16 июльгә кадәр шунда яшәп, 23 июльдә Казанга, 26 августта туган авылына кайта.



Киев шәһәре күренеше. XX йөз башы

Вид города Киева. Начало XX века





Г. Ибраһимов тарафыннан Киев губернасы жандарм идарәсе җитәкчесенә язылган расписканың фотокүчермәсе. 1913 ел, 13 июнь. ЯҺММУ. Ф. 65. Тасв. 2. С. б. 18

Фотокопия расписки Г. Ибрагимова руководству Киевского губернского жандармского управления. 13 июня 1913. ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 2. Ед. хр. 18

[буквально: пищей] нации» [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 6: публицистика (1907–1932). Б. 199–200].

Таким образом, по мнению Г. Ибрагимова, объект литературы – духовный, идеальный мир писателя; а окружающая действительность жизни – это лишь толчок к творчеству, сила, побуждающая автора к творению. Что касается вопросов функций искусства, то они состоят в раскрытии национального духа, национальной идеи, народной души.

Г. Ибрагимов, который полностью начал устанавливать в журнале «Анг» свои порядки, 13 февраля 1914 года вновь неожиданно уехал в Киев. Около месяца жил в Киеве, 14 марта, проехав через Одессу, Севастополь, Ялту, оказался в Сухуми. Там он жил с 17 марта до 16 июля, 23 июля вернулся в Казань, а 26 августа поехал в родное Султанмуратово.

В письме от 25 апреля, адресованное Хусни Кариму, Г. Ибрагимов останавливается и на причинах, побудивших его к отъезду: «Людям показалось странным, что я бросил хорошее жалованье и достойную работу. Многие

25 апрельдә Хөсни Кәримгә язган хатында ул үзенең китү сәбәпләренә кагыла: «Казаннан зарарсыз гына жалованье, мәсьүлиятле эшне ташлап китү халыкка ят күренде. Моны күпләр төрлечә хәмел иттеләр. Син дә «Аң»нан китү дигән шикелле карыйсың. Юк, алай түгел, мин «Аң»нан китмәдем, Казаннан киттем. «Аң»ны Кавказда, Киевтә, Мәскәүдә, һич булмый икән, Әстерхан, Уфада чыгарырга булса иде, мин аны ташламас идем. Мин Казанда шул мәгълүм мохиттә тора алмыйм, Казан үзенең Печән базары, Болагы, Балык базары белән, аннан бигрәк тә эшсез, имансыз, фасыйк яшьләре, баштанаяк мәгънәсез интригалар эченә чорналып беткән «хадиме милләт»ләре белән мине гаҗәп туйдырды. Бер ел үтте, Казанның биргән начар тәэсире йөрәктән чыкты – Гәрәйнең «Аң»га чакыруын кабул итә бирдем. Ләкин Казан һаман шул Казан, яшел хадимнәр һаман шул иде. «Аң»ны ташлауны мин кызгандым, ләкин Казанда торуның имкяны калмагач һәм кеше чишәлмәс төсле хисне өздем дә – вәссәлам» [Галимҗан



Ялта шәһәре күренеше. XX йөз башы
Вид города Ялта. Начало XX века






Ялта шәһәре күренеше. XX йөз башы
Вид города Ялта. Начало XX века

трактовали это по-разному. Ты тоже рассматриваешь это как уход из «Анг». Нет, совершенно не так, я не бросил «Анг», я уехал из Казани. Если бы «Анг» издавался на Кавказе, в Киеве, Москве, даже в Астрахани или Уфе, я бы не покинул его. Я не могу жить в этом окружении в Казани. Казань вконец надоела своими Сенным базаром, Булаком, Рыбным базаром, особенно молодыми безбожными бездельниками, погрязшими в бессмысленных интригах «слугами нации». Прошел год, отрицательное впечатление от Казани немного выветрилось, и я принял предложение Гирея в [журнал] «Анг». Но Казань – это та же Казань, молодые «слуги» все те же. Я сожалею, что пришлось бросить «Анг», но когда стало невозможно находиться в Казани, я разорвал чувства, казалось бы, не разрываемые, и уехал» [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 6: публицистика (1907–1932). Б. 81].

В справке Казанского губернского жандармского управления о наблюдении за Г. Ибрагимовым также отмечено, что

Ибраһимов. Әсәрләр: тугыз томда. Т. 9: Хатлар һәм документлар. Б. 81].

Казан губернасы жандарм идарәсенең Г. Ибраһимов артыннан күзәтү турындагы справкасында да әдипнең Ә. Хәсәни белән дустанә аерылышуы билгеләнә. Казаннан китү сәбәбе итеп Г. Ибраһимовның үзенең әдәби иҗат белән шөгыльләнү теләген күрсәтүе әйтелә (чыннан да, Кара диңгез буенда язучы «Безнең көннәр» романын иҗат итә). Шушы справкада әдипнең 1914 елның 29 гыйнварендә Әхмәтҗан Мостафин өендә узган яшерен җыелышта катнашуы, анда исә 1914 елның язында мөгаллимнәр съезды оештыру мәсьәләләренең тикшерелүе дә телгә алына. Г. Ибраһимовның үз артыннан күзәтүне, «яңадан кулга алыну куркынычын сизгән» булуы да мөмкин [Хәсәнов М.Х. Галимҗан Ибраһимов. Тормыш һәм иҗат юлы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1964. 83 б.]. Шул ук вакытта инде 1910 еллардан әдипнең үпкә авыруы белән җәфалануы билгеле. Диңгез буена сәяхәтнең сәбәбе сәламәтлек белән бәйле дигән фаразның да фактик җирлеге бар.


Протоколъ №

Беркетмә фотокүчермәсе.
1913 ел, 18 апрель.
ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 2. С. б. 24

Фотокопия протокола.
18 апреля 1913.
ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 2. Ед. хр. 24





«Табигать балалары» китабы. 1919
Книга «Дети природы». 1919

Г. Ибрагимов расстался с А. Хасани полюбовно. В качестве причины, пробудившей его покинуть Казань, указано желание вплотную заняться литературным творчеством (действительно, на берегу Черного моря Ибрагимов написал роман «Наши дни»). В этой же справке указано, что Г. Ибрагимов 29 января 1914 года принял участие в тайном собрании, состоявшемся в доме Ахметзяна Мустафина, где обсуждался вопрос об организации съезда учителей весной 1914 года. Также возможно, что Г. Ибрагимов заметил слежку за собой, опасался нового ареста [Хәсәнов М.Х. Галимҗан Ибраһимов. Тормыш һәм иҗат юлы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1964. Б. 83]. В то же время известно, что с 1910-х годов он уже болел туберкулезом. Так что есть основание и для версии, что причина путешествия к морю – проблемы со здоровьем.

2 октября 1914 года Г. Ибрагимов снова приехал в Казань, начал заниматься свободным творчеством. Были написаны рассказы «Дети природы» и «Из тетради покойного».

1914 елның 2 октябрендә әдип кабат Казанга килеп урнаша, монда ирекле иҗат эше белән шөгыльләнә. Бу чорда «Табигать балалары» һәм «Мәрхүмнең дәфтәреннән» хикәяләре языла. Кеше һәм җәмгыять тормышында сәнгать-мәдәниятнең роле хакындагы фикерләр «Мәрхүмнең дәфтәреннән» (1914) хикәясендә яңа югарылыкта тәкъдим ителә. Романтик сюжетны язучының хикәяләүче герое – карт шагыйрь күңелендә барган эчке каршылык барлыкка китерә. Ул тормыш мәгънәсен эзләүдән туа: «Мин хәят эзләдем, хәятта мәгънә эзләдем, хәятның барлык рәхәтләрен фида кыйлдырырлык мәртәбәдә изге була алырлык бер идеал эзләдем. Моны кем эзләмәгәндер, ләкин табучы булганмы?» [Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. Т. 1: Хикәяләр (1907–1929). Б. 206] – ди карт шагыйрь.

Г. Ибраһимов бу хикәядә башка әсәрләрендә белдерелгән идеяләрне бер-бер артлы кире кага. Яшәү идеалы, җир йөзендәге бәхет – матур кызларда, мәхәббәттә дип ышанган чагы да була карт шагыйрьнең. Ләкин ул аннан ваз кичә.




Табигать балалары» китабы. 1920

Книга «Табигать балалары» («Дети природы»). 1920





«Мәрхүмнең дәфтәреннән» исемле хикәядән фрагмент. 1920

Фрагмент рассказа «Мәрхүмнең дәфтәреннән» («Из тетради покойного»). 1920

Раздумья о роли искусства, культуры в жизни человека и общества предложены в рассказе «Из тетради покойного» (1914) с новой, более взвешенной точки зрения. Романтический сюжет образует внутреннее противоречие в душе старого поэта – основного героя рассказа. Противоречие рождается от поисков смысла жизни: «Я жизнь искал, смысла в жизни искал, идеал искал, который мог бы дать славу, граничащую со святостью, ради которой можно было бы пожертвовать всеми радостями мира. Кто же их не искал? Нашел ли кто-нибудь?» – вздыхает поэт [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 1: хикәяләр (1907–1929). Б. 206].

В этом рассказе Г. Ибрагимов одну за другой опровергает идеи, которые были высказаны в предыдущих произведениях. Было время, когда старый поэт искренне верил, что идеал, земное счастье воплощаются в красивых девушках и любви. Но он отвергает это убеждение. В поисках смысла жизни пробует обратиться к вере. Но видя реки крови, пролитые во имя веры, разочаровывается и в этом. Затем

Яшәү мәгънәсен эзләп дингә дә мөрәҗәгать итә. Ләкин «дин исеменнән түгелгән кан дәрьяларын» күреп, гайрәте чигә. Изге идеал дип милләткә хезмәтне саный. Ләкин бу юлда да төрле ихтыяҗларның бугазга-бугаз килүен аңлый. Ниһаять, игътибары фән, гыйлем һәм мәдәниятә төбәлә. Герой әдәбият һәм сәнгать алдында «тук мещаннар һәм бай аристократлар»га хезмәт итүдән башка максатны эзли, йөрәге белән көтә, ләкин таба алмый. Нәтиҗәдә рухи газаплана, җәфа чигә. Язучы шундый авыр шөбһәләр эчендәге героен караңгы бакчада тормыш төбендә яшәүче кешеләр – сукбайлар белән очраштыра, карт шагыйрьгә алар авызыннан рәхмәт әйттерә. Бу рәхмәт «сәнгатьнең төп максаты – тормыш төбендәге кешеләргә хезмәт күрсәтү, аларны хак юлга өндәү» дигән фикерне раслый. Шушы ноктада авторның мәсьәләне социаль планда хәл итүе күзәтелә.

Язучы кешеләрне икегә бүлә: чынбарлыкта һәм хыял белән яшәүчеләр. Һәм романтикларның, идеал эзләүчеләрнең бәхетне иҗатта, сәнгатьтә таба алуын раслый, аларны тынгысыз яшәргә этәргән көчләрне билгеләп уза. Кешеләрнең икенче яртысы – «тәңренең бәхетле коллары», шуларның вәкиле булган сукбайлар өчен дә бәхет, рәхәтлек – әдәбият укуда, ул тудырган иллюзиядә кебек аңлашыла. Әдәбият – язучылар өчен генә түгел, укучы өчен дә тормыш мәгънәсе, яшәү шатлыгы дигән хакыйкать ассызыклана. Автор әдәбият һәм сәнгатьнең кеше тормышындагы урыны хакында уйлана. Шәхес өчен газиз кыйммәтләр: ана һәм сөйгән яр, дин, фән, гыйлем, милләт күздән кичерелеп, әдәбият аларның барыннан да югары куела, тормыштагы иң газиз нәрсә кебек шәрехләнә. Ләкин бәхетнең әдәбиятта – уйлап табылган, иҗат ителгән дөньяда булуы кешенең иллюзия белән яшәвен дә искәртә.

Г. Тукай иҗатына кагылышлы аеруча тәнкыйди характердагы «Талант трагедиясе» (1914) мәкаләсе «Йолдыз»да (1914, 2 апрель) басылып чыга. Казанның зыялылары, шушы мәсьәләне «хакимнәр суды»нда тикшереп, әдипне изоляциядә калдыру турында карар чыгаралар.



начинает считать идеалом служение народу. Но и на этом пути понимает, что разные интересы не могут прийти к согласию. Наконец, он обращает внимание в сторону науки, образования, культуры. Герой ищет более возвышенные цели литературы и искусства, чем угождение вкусам мещан и богатых аристократов. Ищет всем сердцем, но найти не может. В результате его постигают духовные страдания и горечь. В тот момент, когда герой находится во власти тяжелых дум и сомнений, автор отправляет его в темный сад, на встречу с бродягами, с людьми на дне жизни. Автор устами этих бродяг благодарит старого поэта. Эта благодарность доказывает мысль автора: основная цель искусства – служить людям, которые волею судьбы оказали на дне, направлять их на путь истинный. В этом видно, как автор решает вопрос в социальном плане.

Писатель делит людей на две группы. Те, которые живут в реальности, и те, которые живут в идеальном мире, грезят мечтой. Он утверждает, что романтики, идеалисты способны и могут найти счастье в творчестве, в искусстве. Отмечает силы, которые заставляют их жить исканиями. Другая половина людей, в том числе и бродяги, – счастливые рабы божьи. Для них счастье – чтение литературы, в иллюзиях, созданных поэтами. Автор утверждает, что литература – это смысл жизни, радости жизни не только для писателя, но и для читателя. Он размышляет о месте и роли литературы и искусства в жизни человека. Перечисляя ценнейшие для личности вещи: мать, любимые, вера, наука, образование, этнос, ставит литературу превыше их всех. Литература трактуется как самое дорогое, что может быть в жизни. Но здесь так же отмечается, что если счастье заключено в литературе, то есть в сотворенном, иллюзорном мире, то человек живет иллюзией.

Статья Галимджана Ибрагимова «Талант трагедиясе» («Трагедия таланта»), посвященная творчеству Г. Тукая и получившаяся особо критичной, была опубликована в газете «Йолдыз» 2 сентября 1914 года. Интеллигенция Каза-

Инкыйлабтан соң Г. Ибраһимов кабат шушы темага әйләнеп кайта: «Татарстан хәбәрләре» газетасының 1922 елгы 28 апрель (96) санында басылган «Өч җавап» язмасында үзенең фикере үзгәрмәвен билгели, «Мин рәхимсез тәнкыйть тарафдары һәм шундый тәнкыйтьләрнең файдасына ышанган кешеләрнең берсемен. Башка нәрсәләр, мәкаләләр хакындагы тәнкыйтьләр, кайбер вакыт үзләренең көчле дәлилләре белән азмы-күпме фикер үзгәртергә ярдәм итүләре булгалаганы хәлдә, ун ел буе сөйләнгән, язылган сүзләрнең һичберсе миллионер Дәрдемәнд, Тукай, Сәгыйть Рәмиевләрнең шигъри талантлары хакында элек гәзитәләрдә, аннан соң «Татар шагыйрьләре»нең беренче китабында моннан 10–12 ел элек язылган фикерләремне үзгәртергә сәбәп булырлык һичбер дәлил, һичбер материал, һичбер гыйльми исбат бирә алмадылар.(...) Шуңар күрә бу өч язучы хакындагы карашым моннан 10–12 ел элек ничек булса, әле дә шул көенчә калды» [Ибраһимов Г. Өч җавап // Ибраһимов Г.



Галимҗан Ибраһимов.
ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 5. С. б. 13

Галимджан Ибрагимов.
ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 5. Ед. хр. 13





Уфада «Галия» мәдрәсәсендә укыткан вакытта Галимҗан Ибраһимов яшәгән йорт. ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 5. С. б. 5

Дом, в котором жил Г. Ибрагимов во время преподавания в медресе «Галия». Уфа. ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 5. Ед. хр. 5

ни, коллективно рассмотрев эту статью, приняла решения о бойкотировании писателя.

После революции Ибрагимов снова вернулся к этой теме. В статье «Өч җавап» («Три ответа»), опубликованной в газете «Татарстан хәбәрләре» («Известия Татарстана») 28 апреля 1922 года № 26, отмечает, что его мнение не изменилось. «Я сторонник жесткой критики и верю в исключительную пользу именно такой критики. Критика о других вещах, статьях иногда обоснованными доказательствами может немного изменить мнение, но чтобы изменить мнение о том, что я говорю уже около десяти лет, то есть о творчестве и поэтическом даре миллионера Дэрдеменда, Тукая, Сагита Римиева, которые были опубликованы в газетах, в первой книге «Татар шагыйрьләре» («Татарские поэты»), нет никаких доказательств, никакого материала или научного основания... Поэтому мое мнение относительно этих трех писателей такое же, как было 10–12 лет назад» [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 5: әдәбият

Әсәрләр: сигез томда. Т. 5: әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933). Б. 310].

1915 елның 10 февралендә абыйсы Шакирҗан Ибраһимовны Беренче Бөтендөнья сугышына озату өчен Г. Ибраһимов туган якларына кайта. 1915 елның ноябреннән, Уфага килеп, «Галия» мәдрәсәсенә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып урнаша һәм 1917 елның февраль революциясенә кадәр шунда эшли, бер үк вакытта Уфа губерна земствосының өч еллык педагогик курсларында һәм кызлар мәктәбендә дә татар теле-әдәбияты дәресләре алып бара. «Галия» мәдрәсәсе җитәкчеләре һәм укытучылары оештырган кыска сроклы укытучылар курсларында да бик теләп эшли [Вәли Хангилдин. Галим һәм киңәшче // Галимҗан Ибраһимов: мәкаләләр, истәлек-хатирәләр. Б. 159].

Г. Ибраһимовта укыган шәкертләр аның дәресләрен зур ихтирам белән искә алалар. Алар арасында соңыннан күренекле булып киткән Г. Нигъмәти, шагыйрьләр С. Кудаш,



«Галия» мәдрәсәсе бинасы. ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 5. С. б. 60
Здание медресе «Галия». ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 5. Ед. хр. 60





Г. Ибраһимов «Галия» мәдрәсәсе шәкертләре арасында. ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 5. С. б. 3
Г. Ибрагимов среди шакирдов медресе «Галия». ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 5. Ед. хр. 3

һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933). Б. 310].

10 февраля 1915 года Ибрагимов вернулся в родные края, чтобы проводить старшего брата Шакирджана на Первую мировую войну. 10 ноября того же года приехал в Уфу и устроился преподавателем татарского языка и литературы в медресе «Галия», где проработал до февральской революции 1917-го года. Одновременно вел уроки татарского языка и литературы на трехгодичных педагогических курсах Уфимского губернского земства и в школе для девочек. Принимал участие в краткосрочных курсах для учителей, организованных руководством и преподавателями медресе «Галия» [Галимҗан Ибраһимов: мәкаләләр, истәлек-хатирәләр / төз. Р. Акъегет. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. Б. 159].

Ученики Г. Ибрагимова с большим уважением вспоминают его занятия. Среди них ставшие позднее знаменитыми ученый и писатель Г. Нигмати, поэты С. Кудаш, Ш. Бабич,

Ш. Бабич, Х. Туфан, журналистлар С. Атнаголов, Г. Ишмаев, М. Бикбулатов һ.б. була.

Мәдрәсәдә әдәбият укыту тәҗрибәсенә нигезләнеп, 1916 елны Г. Ибраһимов зур хезмәт – «Әдәбият дәресләре» китабын нәшер итә. «Әдәбият» сүзен киң мәгънәсендә кулланып, автор «матур әдәбият – шигырь» аның бер өлеше дип карый. Китапта әдәбият кагыйдәләре татар әдәбиятыннан мисаллар, әсәрләр анализлау белән үрелеп бара. Ул катлаулы төшенчәләр хакында гади генә итеп сөйләве белән аерылып тора. Мәсәлән, «Әсәр нәрсә хакында язылган булса, шул нәрсә мәүзугъ дип атала» рәвешендә темага билгеләмә биреп, Г. Тукайның «Туган авыл» шигыре туган авыл хакында булуы мисал итеп китерелә [Ибраһимов Г. Әдәбият дәресләре. Казан: Сабах, 1916. Б. 10–11]. Яки идея төшенчәсе «әсәрнең төбенә салынган караш вә тәэсир» кебек аңлатыла һәм Г. Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәрендә төп уйидея «болай барса, татар халкы бер вакыт бетәчәк!» икәнлек мисалга китерелә [Ибраһимов Г. Әдәбият дәресләре. Б. 13].



Шәехзадә Бабич (1895–1919)

Шаехзадэ Бабич (1895–1919)






«Әдәбият кануннары» китабы. 1918, 1919 елгы басмалар

Книга «Каноны литературы». Издания 1918, 1918 года

Х. Туфан, журналисты С. Атнагулов, Г Ишмаев, М. Бикбулатов и др.

На основе опыта преподавания татарской литературы в 1916 году Ибрагимов издал большой труд «Әдәбият дәресләре» («Уроки литературы»). Используя слово «литература» в широком значении автор выделяет художественную литературу – поэзию как ее часть. В книге правила литературы объясняются на основе примеров из татарской литературы, приводится анализ произведений. Труд отличается тем, что достаточно просто и понятно говорит о сложном. К примеру, «о чем произведение написано, то и является его темой». Это определение, данное Ибрагимовым понятию тема. В качестве примера приводится стихотворение Тукая «Туган авыл» («Родная деревня») и отмечается, что это стихотворение о родной деревне [Ибраһимов Г. Әдәбият дәресләре. Казан: Сабах, 1916. Б. 10–11]. Понятие «идея» трактуется как «мнение или впечатление, заложенное в основу произведения». Например, основная идея произве-

Г. Ибраһимов китабында поэтика нигезләре салына. Ул, беренчеләрдән булып, нәзым, нәсер һәм вәзен мәсьәләсен дә өслүбкә (стильгә) буйсындыра, шуның бер юнәлеше итеп карый. Бу татар әдәбиятына кагылышлы аерым бер бәхәсле мәсьәләләрне чишәргә ярдәм итә.

Әдәбиятның төр һәм жанрларга бүленеше мәсьәләләрендә «бөтендөнья әдәбияты» дигән төшенчә аша татар әдәбияты жанрларын дөнья әдәбияты фонында күзәтү омтылышы ясый. Бу өлкәдә төзек бер система тәкъдим итмәсә дә, татар әдәбиятында пәйда булган жанрларны мисаллар китереп күзәтеп уза.

Г. Ибраһимовның «Әдәбият дәресләре» тулы бер дәверне – татарларда әдәбият теориясе фәне формалашу дәверен йомгаклап куя. Дәреслек итеп язылса да, аның вазифалары күпкә киң: татар әдәбиятын нәзари кагыйдәләр ярдәмендә аңлату, бәяләү, үсеш юлларын сызу да максат итеп алынган була.

Тагын бер хезмәте – «Татар телен ничек укытырга» 1916 елда язып төгәлләнә, әмма 1918 елда гына басылып



Сәйфи Кудаш
(1894–1993)
Сайфи Кудаш
(1894–1993)





Галимҗан Нигъмәти
(1897–1941)
Галимджан Нигмати
(1897–1941)

дения Г. Исхаки «Ике йөз елдан соң инкыйраз» («Исчезновение через двести лет») – «если так пойдет и дальше, то татарский народ однажды исчезнет!» [Ибраһимов Г. Әдәбият дәресләре... Б. 13].

В этой книге Ибрагимова закладываются основы поэтики. Он одним из первых в татарском литературоведении уделил большое внимание вопросам ритма, повествования и стихосложения. Основы, заложенные Ибрагимовым, помогли решить некоторые спорные вопросы татарского литературоведения.

В вопросах о видах и жанрах литературы через понятие всемирная литература Г. Ибрагимов попытался сделать обзор жанров татарской литературы на фоне мировой литературы. Даже если он еще не составил цельной системы, но привел примеры жанров, которые появились в татарской литературе недавно.

«Уроки литературы» Г. Ибрагимова завершают в татарском литературоведении этап формирования литературной

чыга. Анда татар телен ничек укытырга һәм нәрсә укытырга дигән сорауларга җавап бирелә.

1916 елның 26 декабрендә «Галия» мәдрәсәсенең 10 еллык юбилее билгеләп үтелә. «Юбилей уңае белән үткәрелгән тантаналы җыелышта Г. Ибраһимов «Галия» мәдрәсәсенең мөгаллимнәр, башка зыялы кешеләрне әзерләүдәге роле, халыкны агарту юлындагы хезмәтләре, киләчәктә милли мәдәниятләрне үстерүдәге перспективалары турында зур доклад сөйләде», дип искә ала аның укучысы [Әхмәт Бикмурзин. Уфада // Галимҗан Ибраһимов: мәкаләләр, истәлек-хатирәләр. Б. 114]. Шушы ук истәлектә тагын бер кызыклы факт китерелә: Г. Ибраһимов докладындагы милли тел һәм әдәбиятны мөстәкыйль үстерү фикеренә каршы, Муса Бигиев төрки халыклар өчен уртак тел һәм мәдәниятне үстерү кирәклеген күтәреп чыга. Бу бәхәс инкыйлабтан соң да дәвам итәчәк әле.

Бәйрәм көннәрендә мәдрәсәнең уку-укыту бүлеге әгъзалары Г. Ибраһимов, Г. Терегулов, Ф. Сәйфи, Х. Мәхмүдев,





Галимҗан Ибраһимов фотосы автографы белән. 1913 ел.
ЯһМMҮ. Ф. 65. Тасв. 5. С. б. 53

Фотография Галимджана Ибрагимова в автографом. 1913.
ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 5. Ед. хр. 53







Галимҗан Ибраһимов фотосы автографы белән. 1913.
ЯһМMҮ. Ф. 65. Тасв. 5. С. б. 54

Фотография Галимджана Ибрагимова в автографом. 1913.
ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 5. Ед. хр. 54

теории. Хоть книга и написана в форме учебника, функции этого труда намного шире: объяснить, оценить татарскую литературу, основываясь на теоретических законах, определить пути ее дальнейшего развития.

Еще один труд Г. Ибрагимова «Татар телен ничек укытырга» («Как преподавать татарский язык» был завершен в 1916 году, опубликован в 1918. Здесь автор попытался дать ответ на вопросы: как преподавать татарский язык и что собственно преподавать.

20 декабря 1916 года было отмечено 10-летие медресе «Галия». Ученик Ибрагимова Ахмет Бикмурзин вспоминает: «На торжественном заседании по случаю юбилея Г. Ибрагимов выступил с большим докладом о роли медресе «Галия» в подготовке учителей, интеллигенции, о деятельности медресе в просвещении народа, о перспективах этого учебного заведения в развитии национальных культур» [Галимҗан Ибраһимов: мәкаләләр, истәлек-хатирәләр / Төз. Р. Акъегет. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007.

Җ. Абдюшев, З. Богданов, И. Йоманколов Зыя Камалигә тәбрикләү язалар. Андагы «...Сез үзеңезнең бетмәс-төкәнмәс иҗтиһадыңыз, мисле булмаган тәвәккәллеңез белән, һич юктан «Мәдрәсәи Галия диния» кебек олуг бер гыйлем йортын вөҗүдкә китереп, гыйлемгә, тәрбиягә сусаган яшьләргә зур хезмәт иттеңез. Борынгы ысул белән гакыллары богауланган, фикерләре туңган татар яшьләренә киң уй бирдеңез, шәхсиятләрен кысынкы йир астыннан чыгардыңыз һәм шул яшьләргә халкымызның иң караңгы почмакларына таралып, киләчәк хәятның хуҗалары булачак меңнәрчә балаларның аң вә тәрбияләренә билвасыйт хезмәте иттеңез» дигән сүзләр Зыя Камалиның милләт алдындагы олы хезмәтләрен тану, Г. Ибраһимовның аңа карата олы ихтирамы кебек кабул ителә [Галимҗан Ибраһимов. Әсәрләр: тугыз томда. Т. 9: Хатлар һәм документлар. 97 б.].

Г. Ибраһимовның шәхесе, хезмәтләре дә, эш-гамәлләре, әдәби әсәрләре дә XX йөз башы татар җәмгыятендә



«Галия» мәдрәсәсе укытучылары. 1916. ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 5. С. б. 31

Преподаватели медресе «Галия». 1916. ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 5. Ед. хр. 31





Г. Ибраһимовның төрле елларда дөнья күргән китаплары

Книги Г. Ибрагимова, изданные в разные годы

Б. 114]. В этих же воспоминаниях приводится еще один интересный факт: в противовес мнению Ибрагимова о самостоятельном развитии национального языка и литературы, высказанном в этом докладе, Муса Бигиев выступил с тем, что необходимо развивать общую культуру и язык для всех тюркских народов. Этот спор будет продолжен и после революции.

В дни празднования члены учебного отдела медресе Г. Ибрагимов, Г. Терегуров, Ф. Сайфи, Х. Махмудов, Дж. Абдюшев, З. Богданов, И. Юманкулов написали поздравление Зие Камили. Слова из этого поздравления: «Своим огромным трудолюбием, беспримерной решительностью из ничего вы создали такое замечательное высшее учебное заведение – «Медресе Галия диния». Вы служите образованию, воспитанию молодежи. Татарская молодежь была лишена осознанности из-за устаревших способов преподавания, вы зажгли их мысль, дали свободу, тем самым послужили для тысячей детей, которые станут учениками этих молодых людей». Эти

гел игътибар үзәгендә тора. Иң беренче әсәрләре басылып чыгуга ук татар вакытлы матбугаты битләрендә аларга мөнәсәбәт белдерелә башлый [Тутый. Яңа әсәрләр. «Татар хатыны нилә[р] күрми» // Йолдыз. 1910, 18 ноябрь; Кәримов Ф. «Яңа әсәр» мөнәсәбәте илә // Вакыт. 1911, 6 декабрь; Яңа әсәрне тәнкыйть. «Карак мулла» // Сибирия. 1912, 3 июнь; Яңа әсәрне тәнкыйть. «Сөю-сәгадәт» // Сибирия. 1912, 17 июнь һ.б.]. Язучының «Яшь йөрәкләр» кебек зур әсәрләре матбугат битләрендә махсус сөйләшүләргә азык була [Авыргазый. Яңа әсәрләр. «Яшь йөрәкләр» // Йолдыз. 1913, 24 гыйнвар; Хөсни. «Яшь йөрәкләр» // Идел. 1913, 21 февраль; Җәләй. Әдәби мөсахәбәләр. «Яшь йөрәкләр» // Вакыт 1913, 23 февраль; Сәйфи Ф. «Яшь йөрәкләр». (Тәнкыйть) // Хокук вә хәят. 1913. № 3. Б. 49–50; Газиз Г. «Яшь әдәбиятыбызда – «Яшь йөрәкләр» // Аң. 1913. № 11. Б. 189–194 һ.б.]. Әгәр XX йөз башында Г. Ибраһимов историографиясенә күз салсак, аның шактый киңкырлы булуы күзгә ташланыр. Язучы иҗатының романтик табигате,



Гали Рәхим
(1892–1943)
Гали Рахим
(1892–1943)





Сәгыйть Сүнчәләй
(1889–1937)
Сагит Сунчелей
(1889–1937)

слова понимаются как признание заслуг Зии Камали перед народом и знак большого уважения писателя к нему.

Личность, труды, деятельность, произведения Г. Ибрагимова всегда были в центре внимания татарской общественности начала XX века. Как только были опубликованы первые его произведения на страницах татарской периодической печати, общественность начала высказывать свое отношение к нему (Тутый. Яңа әсәрләр. «Татар хатыныниләр күрми» // Йолдыз. 1910, 18 ноябрь; Кәримов Ф. «Яңа әсәр» мөнәсәбәте илә // Вакыт. 1911, 6 декабрь; Яңа әсәрне тәнкыйть. «Карак мулла» // Сибирия. 1912, 3 июнь; Яңа әсәрне тәнкыйть. «Сөю – сәгадәт» // Сибирия. 1912, 17 июнь һ.б.) Язучының «Яшь йөрәкләр» кебек зур әсәрләре матбугат битләрендә махсус сөйләшүләргә азык була (Авыргазый. Яңа әсәрләр. «Яшь йөрәкләр» // Йолдыз. 1913, 24 гыйнвар; Хөсни. «Яшь йөрәкләр» // Идел. 1913, 21 февраль; Җәләй. Әдәби мөсахәбәләр. «Яшь йөрәкләр» // Вакыт. 1913, 23 февраль; Сәйфи Ф. «Яшь йөрәкләр». (Тәнкыйть) // Хокук вә хәят. 1913.

аның геройлар тудыру осталыгы, матур тел-стиле хуплау таба. Бигрәк тә «Яшь йөрәкләр», романтик хикәяләре, нәзари хезмәтләре җентекле анализлана. Әдәби иҗаты хакында әтрафлы язмалар авторлары буларак Г. Гобәйдуллинны, Җ. Вәлидине, Н. Гасрыйны аерып күрсәтергә мөмкин. Нәзари хезмәтләре хакында Г. Сәгъди, Г. Рәхим, Ш. Әхмәдиев, Н. Думави, С. Сүнчәләй, Хөсни Кәрим һ.б. катнашында зур-зур бәхәсләр булып уза. XX йөз башы әдәбият белеме, әдәби тәнкыйть Г. Ибраһимовны зур язучы, фикер иясе буларак бәяли.

Бер үк вакытта, аның сокланырлык эшләү куәсе, катлаулы, каршылыклы холкы, кырыслыгы, үткен һәм еш кына артык усал теле, дөньяга тәнкыйди карашлы булуы да үз хезмәтләрендә генә түгел, аңа кагылышлы язмаларда да күренә. Бу әдипнең үзенә һәм башкаларга чиктән тыш таләпчәнлеге белән дә бәйле була. Шул ук вакытта аның татар матбугатына, әдәбиятына, татар яңарышына кайчак көч тә җитмәслек зур максатлар куеп, тормышның һәр



«Ирек» газетасы нәшрияты урнашкан бина. Уфа. 1917.

Здание, где располагалась редакция газеты «Ирек». Уфа. 1917.

Источник: Галимджан Ибрагимов: документы и факты; Галимджан Ибрагимов глазами молодых / [авт.-сост. М.Х. Ибрагимов]. Казань: Татар. кн. изд-во, 2012





«Ирек» газетасы нәшрияты урнашкан бинаның хәзерге күренеше.

Современный вид здания, где располагалась редакция газеты «Ирек».

Источник: Галимджан Ибрагимов: документы и факты; Галимджан Ибрагимов глазами молодых / [авт.-сост. М.Х. Ибрагимов]. Казань: Татар. кн. изд-во, 2012

№ 3. Б. 49–50; һ.б.). Если взглянем на историографию Ибрагимова начала XX века, то заметим, что она достаточно разнообразна. Романтическая составляющая творчества, его мастерство создавать героев, эмоциональное повествование были восприняты литературными критиками положительно. Особенно детально были проанализированы роман «Молодые сердца», романтические рассказы, теоретические труды. В качестве авторов основательных критических статей по литературному творчеству Г. Ибрагимова можно назвать Г. Губайдуллина, Дж. Валиди, Н. Гасри. О теоретических исканиях писали Г. Сагди, Г. Рахим, Ш. Ахмадиев, Н. Думави, С. Сунчелей, Хусни Карим. С их участием происходили большие дискуссии по тем или иным сторонам творчества Г. Ибрагимова. Татарское литературоведение, литературная критика начала XX века оценивают Ибрагимова как крупного писателя и мыслителя.

Одновременно отмечается его трудоспособность, сложный и противоречивый характер, суровость, резкий и часто

өлкәсендә идеаллаштырылган үсеш траекториясе сызуы турында да сөйли.

1917 елдан соң Ибраһимов сәяси көрәш вакыйгаларында кайнап яши. Февраль революциясе булуга, ул укыту эшеннән китә, актив рәвештә иҗтимагый-сәяси тормышта катнаша башлый. «Галия»дә – тарих укытучысы, язучы Ф. Сәйфи-Казанлы һәм журналист Ш. Сүнчәләй белән бергә «Ирек» газетасын оештырып җибәрә: 30 мартта аның беренче саны басыла, ул сентябрь аена кадәр шактый актив эшләп килә, аннары «Солдат теләге» газетасы белән кушылып, «Безнең юл» дигән яңа исем белән чыга башлый. Һәр икесендә дә Г. Ибраһимов – редактор, Ф. Сәйфи-Казанлы секретарь була.

Г. Ибраһимов үзе газетаның төп мәсләген түбәндәгечә билгели: «империалистик сугышка каршы көрәш, җирләрне конфискацияләү өчен көрәш; татар буржуаз милләтчелек оешмаларына каршы, татар буржуазиясенең экстерриториаль-автономияле хәрәкәтенә (Милли идарәгә) каршы


ایرك

«Ирек» газетасы
Газета «Ирек»





Фатих Сәйфи-Казанлы (1888–1937)
Фатих Сайфи-Казанлы (1888–1937)

злой язык, критичность, что отражается не только в произведениях самого Ибрагимова, но и в публикациях, так или иначе его касающихся. Это также было связано с чрезмерной требовательностью писателя к себе и к окружающим. В то же время это говорит о том, что он чертил идеализированную траекторию развития для татарской печати, литературы, татарского возрождения в целом, ставя порой недостижимые цели.

После 1917 года Г. Ибрагимов живет бурной политической деятельностью. Сразу же после февральской революции он оставил преподавание, начал активно заниматься общественно-политической жизнью. Ибрагимов организует газету «Ирек» («Свобода») совместно с преподавателем истории в «Галия» и писателем Ф. Сайфи-Казанлы и журналистом Ш. Сунчелеем. 30 марта увидел свет первый номер этой газеты. Газета довольно активно работала до сентября, затем была объединена с газетой «Солдат теләге» («Желание солдата») и начала выходить уже под названием

көрәш һәм территориаль автономия (тупраклы мохтарият) өчен көрәш. Контрреволюцион Корнилов фетнәсеннән соң, югарыда күрсәтелгән лозунгларга Керенскийның Вакытлы хөкүмәтен тәнкыйтьләү һәм массаны «Бөтен власть – Советларга!» дигән лозунгка катгый әзерлек мәсьәләләре өстәлде» [Галимҗан Ибраһимов. Әсәрләр: тугыз томда. Т. 9: Хатлар һәм документлар. Б. 22].

«Ирек», аннары «Безнең юл» газетасы Г. Ибраһимов өчен халыкка иҗтимагый-сәяси хәлләрне аңлату мәйданы ролен үти. Истәлекләрдән күренгәнчә, әдип газета чыгаруны сәяси каршылыклар үткенәйгән вакытта иң мөһим эш дип саный: «Газетаның редакциясе Пушкин урамында, әлеге «Сарай» мосафирханәсенең бер бүлмәсендә иде. Арзанлы мосафирханә булуына карамастан, урыны каланың үзәгендә, җиде юл чатында. Бәләкәй, бик гади бер бүлмә иде ул. Ике өстәл, биш-алты урындык. Барлык җиһазы шул. Бер өстәлдә редактор – Г. Ибраһимов, икенчесендә секретарь Фатих Сәйфи-Казанлы утыра. Редакциянең штаты да



Г. Ибраһимов дуслары белән. ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 5. С. б. 41
Г. Ибрагимов с друзьями. ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 5. Ед. хр. 41





Фотоның арткы ягындагы Сәйфи Кудаш автографы. ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 5. С. б. 41
Автограф Сайфи Кудаша на обороте фотографии Г. Ибрагимова с друзьями. ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 5. Ед. хр. 41

«Безнең юл» («Наш путь»). В обеих газетах редактор – Г. Ибрагимов, секретарь – Ф. Сайфи-Казанлы.

Г. Ибрагимов сам определил основную задачу газеты таким образом: «Борьба против империалистической войны, против конфискации земель; против татарских буржуазных националистических организаций, против движения татарской буржуазии за экстерриториальную автономию (Национальное управление) и борьба за территориальную автономию (земельная автономия). После контрреволюционного бунта Корнилова к вышеуказанным лозунгам прибавились и критика Временного правительства Керенского и подготовка к лозунгу «Вся власть – Советам!» [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 9: хатлар һәм документлар. Б. 22].

Газеты «Ирек» и «Наш путь» служили для Г. Ибрагимова площадкой для объяснения народу общественно-политической обстановки. Как свидетельствуют воспоминания, писатель считал издание газет в период усиления политических противоречий самым важным делом: «Редакция

шул. Басмаханәгә түләргә акчасы булса, газета атнасына өч сан чыга, булмаса, ике белән дә кала» [Исмәгыйль Рәмиев. Якташым // Галимҗан Ибраһимов: мәкаләләр, истәлек-хатирәләр. Б. 94]. Үзенең бөтен каләм көчен, оештыру сәләтен газета аша татарлар белән «сөйләшү»гә салып, Г. Ибраһимов үз тирәсенә Уфаның талантлы кешеләрен туплый: М. Гафури, С. Рәмиев, С. Кудаш, С. Сүнчәләй, Ш. Бабич, Ә. Таңгатаровлар шундыйлардан. Үзе дә күп һәм ялкынлы яза. Мәсәлән, 1917 елда газетаның һәр санында аның шундый характердагы «Куәт – халыкта», «Халык – падишаһ», «Безнең юл», «Халык үзе хөкем итсен», «Өченче социалистик газета», «Халыкны саташтырмаңыз!», «Икенче съезддан алган тәэссоратым», «Эшче халык!» кебек публицистик мәкаләләре басылып килә.

Г. Ибраһимов, татар-башкорт мөселман сул эсерлар партиясенең оештыручылары һәм җитәкчеләренең берсе буларак, ул айларда гаять актив тормыш белән яши: демонстрацияләрдә нотыклар сөйли, гомуми мөселман



Петербург шәһәре күренеше. ХХ йөз башы
Вид города Петербург. Начало ХХ века





Петербург шәһәре. Таврия сарае. ХХ йөз башы
Таврический дворец. Петербург. Начало ХХ века

газеты находилась в одной комнате гостиницы «Сарай» на улице Пушкина. Несмотря на то, что эта была достаточно бюджетная гостиница, находилась она в центре города, на перекрестке всех дорог и улиц. Это была маленькая и просто обставленная комната: два стола, пять-шесть стульев. Это вся мебель. За одним столом сидит редактор Г. Ибрагимов, за другим – секретарь Ф. Сайфи-Казанлы. Это и весь штат редакции. Если есть деньги, чтобы заплатить в типографии, газеты выходят три раз в неделю, если нет, ограничиваются двумя номерами» [Галимҗан Ибраһимов: мәкаләләр, истәлек-хатирәләр... Б. 94]. Используя всю силу своего пера, организаторские способности, подчинив их «разговору с татарами через газету», Г. Ибрагимов сплотил вокруг себя талантливых людей Уфы: М. Гафури, С. Рамиева, С. Кудаша, С. Сунчелея, Ш. Бабича, А. Тангатарова. И сам пишет много и бурно. К примеру, в 1917 году в каждом номере газеты были опубликованы такого плана публицистические статьи Г. Ибрагимова, как: «Куәт – халыкта» («Сила – в народе»),

җыелышларында, корылтайларда, Милләт мәҗлесе эшендә катнаша, Мәскәүдә 1917 елның 1–11 маенда узган Бөтенроссия мөселманнарының Беренче съездында һәм Казанда 1917 елның 16 июлендә – 2 августында узган Икенче съездында чыгышлар ясый. Февраль революциясеннән соң төзелгән җәмәгать оешмаларында, сайлау кампанияләрендә эшли. 1917–1918 елларда Милләт Мәҗлесенә һәм Учредительное собрание депутаты итеп сайлана. 1917 елның декабрь ахырында, Учредительное собрание әгъзасы буларак, Петроградка китә һәм Совет хөкүмәте органнарында эшли башлый.

«Петроградка 5 гыйнварда, Учредилканың нәкъ ачылу моментына килеп җиттем. Таврия сараенда Совет властен тану, Учредилканың куылуы ихтималы турында кызу бәхәс кайный иде. Мәсьәлә минем өчен ачык иде. Шунлыктан башында большевистик фракция торган сул канат контрреволюцион Учредительный собрание залын ташлап чыкканда, мин һичнинди икеләнүсез большевикларга һәм



Мулланур Вахитов
(1885–1918)

Мулланур Вахитов
(1885–1918)





«Мулланур Вахитов иптәшнең кыскача тәрҗемәи хәле» («Шәрыкнең бөек революционеры Мулланур Вахитов» исемле китаптан). ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 1. С. б. 26

«Краткая биография товарища Мулланура Вахитова» (из книги «Великий революционер Востока Мулланур Вахитов»). ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 1. Ед. хр. 26

«Халык – падишаһ» («Народ – царь»), «Безнең юл» («Наш путь»), «Халык үзе хөкем итсен» («Пусть народ сам осудит»), «Өченче социалистик газета» («Третья социалистическая газета»), «Халыкны саташтырмагыз!» (Не запутайте народ!»), «Икенче съездан алган тәэссератым» («Мои впечатления от Второго съезда»), «Эшче халык!» («Рабочий народ»).

Будучи одним из организаторов и руководителей партии татаро-башкирских мусульман левых эсеров, Г. Ибрагимов эти месяцы жил невероятно активной жизнью: выступал с речью на демонстрациях, принимал участие в работе общемусульманских собраний, курултаев, Милли Меджлиса, первого всероссийского съезда мусульман, прошедшего в Москве 1–11 мая 1917 года и Второго съезда, прошедшего в Казани 16 июля – 2 августа 1917 года. Работает в общественных организациях, возникших после февральской революции, участвует в выборных кампаниях. В 1917–1918 годах был избран депутатом в Милли Меджлис и Учредительное собрание. В конце декабря 1917 года в качестве

сул эсерларга кушылдым. Шуннан соң «Бөтен власть Советларга!» лозунгысы астында Учредилкага каршы көрәш алып бардым. Берничә көн үткәч, Ленин имзасы белән Учредилканы куып тарату турында декрет чыкты. Гыйнвар урталарында булган Советларның Өченче Бөтенроссия съездына, Учредилканы ташлап чыгучы барлык депутатлар белән бергә, миңа да тавыш бирү хокуклы мандат тапшырылды», дип искә ала Г. Ибраһимов ул көннәрне [Галимҗан Ибраһимов. Әсәрләр: тугыз томда. Т. 9: Хатлар һәм документлар. Б. 56]. Съездда ул Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты әгъзасы итеп сайлана, М. Вахитов һәм Ш. Манатов белән берлектә, РСФСРның Милләтләр эшләре буенча халык комиссариаты карамагындагы Үзәк мөселман комиссариатын оештыруда катнаша, комиссар урынбасары була. Бу вакытта Г. Ибраһимовны күргән, бергә эшләгән кешеләр аның көчле, хәтта кискен характерлы, үз сүзендә нык торучан һәм башкаларга да йогынтылы шәхес булуын ассызыклыйлар. Тарихи шартлар үзгәрсә дә, аның



Г. Ибраһимов мөслимәләр белән. ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 5. С. б. 34
Г. Ибрагимов с мусульманками. ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 5. Ед. хр. 34





Наркомнац каршында мөселман эшләре комиссариаты төзү турында халык комиссарлары советы декретының күчермәсе. ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 2, С. б. 58

Копия декрета Совета народных комиссаров о создании Комиссариата по мусульманским делам при Наркомнаце. ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 2. Ед. хр. 58

члена Учредительного собрания уехал в Петроград и начал работу в органах советского правительства.

«В Петроград приехал 5 января, как раз к открытию Учредилки. В Таврическом дворце были бурные споры о признании советской власти, возможности разгнания Учредилки. Для меня вопрос был ясен. Поэтому когда левое крыло во главе с большевистской фракцией покинуло зал Учредительного собрания, контрреволюционного по сути, я без сомнений присоединился к большевикам и левым эсерам. Затем под лозунгом «Вся власть Советам» начал вести борьбу против Учредилки. Через несколько дней за подписью Ленина был издан декрет о роспуске Учредилки. На Третьем Всероссийском съезде советов, которое было где-то в середине января, вместе со всеми депутатами, покинувшими Учредилку, мне также был вручен мандат с правом голосования», – вспоминает Ибрагимов [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 9: хатлар һәм документлар. Б. 56]. На съезде он был избран членом Всероссийского центрального исполни-

артыннан күзәтү тукталмый. Шундый язмаларның берсе, 1918 елда Милләтләр эшләре буенча халык комиссариатының «информаторы» язган (Әдһәм Булбулович дип фараз ителә) «хәбәр»дә чорның сәяси атмосферасын аңлау һәм Г. Ибраһимовның позициясенә төшенү өчен ярдәм итәрлек күзәтүләр бар. «Информатор» Ибраһимовның татар-башкорт сул эсерларының сәяси платформасын Россия сул эсерларыннан аерып кабул итәргә кирәклек турындагы фикерен кабатлый һәм болай дип дәвам итә: «Һәм мөселман, һәм башка милләтче социалистлардан килгән явызлыкның чыганагы нәкъ менә шунда. Бар җирдә бөтендөнья пролетариатының мәсләкләре бер үк төрле булса да, бу социалистлар барыбер ниндидер аерым тенденцияләргә биреләләр. Гомумән алганда, барлык чит рече милләтләр демократиясе һәм алар, социалистлар, Россия революциясенең халыкара характерын аңламыйлар, алар бу революция бөтен дөнья файдасы өчен түгел, шәхси капризлар һәм тар мәнфәгатьләр өчен генә ясалган дип уйлыйлар. Рос-


ЧУЛПАН
چولپان

«Чулпан» газетасы
Газета «Чулпан»





Гражданнар сугышы күренеше
Сцены гражданской войны

тельного комитета. Вместе с М. Вахитовым и Ш. Манатовым принял участие в организации Центрального мусульманского комиссариата в составе народного комиссариата РСФСР по делам национальностей. Стал заместителем комиссара. Люди, которые в это время работали вместе с Ибрагимовым, отмечали его сильный, резкий характер и то, что он был человеком слова и личностью, оказывающей на окружающих огромное влияние.

Изменились исторические условия, но надзор над Ибрагимовым не прекратился. Об этом свидетельствует записка «информатора» Народного комиссариата по делам национальностей (есть мнение, что это Адгам Булбулович), написанная в 1918 году. В ней приводятся наблюдения, которые помогают понять политическую атмосферу эпохи и позицию Г. Ибрагимова в этой эпохе. «Информатор» повторяет утверждение Ибрагимова о необходимости принятия политической платформы татаро-башкирских левых эсеров отдельно от левых эсеров России и отмечает: «Начало

сия революциясенең төп башкаручысы рус пролетариаты булуга карамастан, бу чит кече милләтләр демократиясе Россия революциясен үзләренең капризларына буйсындырып карый һәм килеп туган форсат кебек файдалана. Россия революциясенең йомшак ягы да шунда. Бу йомшаклык өчен гаепле кешеләр – чит кече милләтләр демократиясе җитәкчеләре» [Галимджан Ибрагимов: документы и факты; Галимджан Ибрагимов глазами молодых: авт.-сост. М.-Х. Ибрагимов. Казань: Татар. кн. изд-во, 2012. С. 82]. Язмада Г. Ибраһимовның һәм аның фикердәшләре, мәсләктәшләренең Советларга кай ягы белән куркыныч булуы аермачык әйтелгән: ул – милли мәнфәгатьләрне кайгырту. Әдипне 1938 елда гаепләү һәм юк итү өчен нигез 1918 елда ук салына башлый.

Шушы чорда, сәяси эш белән бергә, Г. Ибраһимов Комиссариат органы булган «Чулпан» газетасын оештыра. Әлеге факт әдипнең инкыйлаби идеяләрне кешеләргә җиткерүнең, халык арасында аңлату эшләре алып



Г. Ибраһимов Колчак армиясе тылында.
ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 5, С. б. 1

Г. Ибрагимов в тылу армии Колчака.
ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 5. Ед. хр. 1





Гражданнар сугышы күренеше
Сцены гражданской войны

вреда от национальных социалистов и мусульман и других национальностей именно в этом. Когда цели и задачи пролетариата во всем мире в одном, эти социалисты все равно подвержены другим тенденциям. В целом демократия всех других малых народов и они (социалисты) не понимают международного характера российской революции, они думают, что революция была совершена не для пользы всего мира и не для личных капризов и узких интересов. Несмотря на то, что основная движущая сила российской революции – русский пролетариат, это демократия малых народов подчиняет российскую революцию своим капризам и использует как счастливое обстоятельство. В этом и слабость российской революции. Ответственны за эту слабость руководители демократии малых народов» [Галимджан Ибрагимов: документы и факты; Галимджан Ибрагимов глазами молодых / авт.-сост. М.-Х. Ибрагимов. Казань: Татар. кн. изд-во, 2012. С. 82]. В этой записке четко указано, чем были опасны Г. Ибрагимов и его соратники для сове-

баруның гаять мөһимлеген яхшы аңлавы турында сөйли. Газета Г. Ибраһимов мөхәррирлегендә 1918 елның гыйнварыннан 1919 ел башына кадәр чыгып килә. Иң кызу оештыру-аңлату эшләре вакытында да үзе иҗтимагый-сәяси хәлләрне аңлатып мәкаләләр язуын дәвам итә: «Мәрхүм Учредительное собрание», «Федерация, тупраклы мохтарият һәм Шуралар хөкүмәте», «Мәркәздәге һәм урыннарда мөселман комиссариатлары» һ.б.

Гражданнар сугышы көчәйгән бер вакытта, Комиссариат белән бергә, 1918 елның мартында Г. Ибраһимов та Мәскәүгә күчә. Көз көне аның үпкә авыруы көчәеп китә: 17 сентябрьдән 6 октябрьга кадәр сырхауханәдә ятып чыга. Октябрь урталарында Казанга кайта.

1919 елның җәендә башта олаучы, аннары вак-төяк белән сату итүче кебек киенеп, Ибраһимов Көнчыгыш фронтның аклар кул астындагы Красноуфимск, Екатеринбург, Камышлы, Төмән, Ишим, Ялуторовск, Петропавел һәм Курган шәһәрләрен һәм авылларын йөреп чыга. Аны



Колчак армиясенең һөҗүм планы

План нападения армии Колчака





Г. Ибраһимовның Колчак армиясе тылында төшкән фотосы. 1919. ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 5. С. б. 8

Г. Ибрагимов в тылу армии Колчака. 1919. ПиМН. Ф. 65. Оп. 5. Ед. хр. 8

тов: преследование национальных интересов. Основание для обвинения и ареста Г. Ибрагимова в 1938 были заложены еще в 1918-м.

Вместе с политической деятельностью в это же время Ибрагимов организует газету «Чулпан» – орган комиссариата. Этот факт говорит о том, что писатель очень хорошо понимал важность передачи народу революционных идей и просветительской работы среди народа. Газета выходит с января 1918-го до начала 1919 года под редакторством Г. Ибрагимова. Даже в самую горячую пору общественно-политической работы Ибрагимов продолжает писать статьи на общественно-политические темы: «Мәрхүм Учредительное собрание» («Покойное Учредительное собрание»), «Федерация, тупраклы мохтарият һәм Шуралар хөкүмәте» (Федерация, федеральная автономия и Правительство Советов»), «Мәркәздәге һәм урыннарда мөселман комиссариатлары» (Мусульманские комиссариаты в столице и на местах») и др.

Колчак тылына разведкага җибәрү карарын 5 нче армия штабы кабул итә. Г. Ибраһимов 1919 елның апрелендә Красноуфимск шәһәре янындагы Бирбарды заводы тирәсендә фронтны кисеп чыга, дүрт айдан соң, сентябрьдә кайтып керә. Бу хакта ул «Кызыл яу» газетасының 1919 елгы 7 сентябрь санында «Дошманнар арасында дүрт ай» дигән мәкалә бастыра. Әлеге язманы барлык татар газеталары диярлек күчереп басалар. Моннан тыш, ул Чиләбе шәһәрендә 5 нче армия карамагындагы 2,5 мең кызылармеец алдында үзе күргәннәр хакында чыгыш ясый, ул сөйләп бетерүгә йөзләгән солдат үзләрен фронт сызыгына җибәрүне сорап гариза яза [Галимджан Ибрагимов: документы и факты; Галимджан Ибрагимов глазами молодых. С. 91]. Әдип әлеге хәлләрне «Безнең көннәр» романында, «Яңа кешеләр» драмасында иҗади файдалана.

Г. Ибраһимовның «Дошманнар арасында дүрт ай» дигән язмасыннан сәяхәтнең максатларын шактый тулы күзалларга мөмкин: әдип сораулар куеп, шуларга үзе үк җавап биреп бара.

Беренчесе – халыкның Кызыл Армиягә һәм Колчак гаскәрләренә мөнәсәбәте, советлар тәкъдим иткән идеологиягә карашлары, шулай ук аклар ягындагы казаклар отрядларының фикерләре. Башкортстаннан Себергә кадәр булган зур территорияне узып, Г. Ибраһимов төрле милләтләр, сыйнфый төркемнәрнең хәлләрен һәм Гражданнар сугышында яклаган позицияләрен ачыклый.

Икенчесе – колчакчылар агитация максатында файдаланган качаклар, обозчылар. Үзе дә шулар арасында хәрәкәт иткән Ибраһимов аларның йогынтысы нык кимегәнлекне ассызыклый, халыкның канкойгыч сугыштан туйганлыгын, тыныч тормышка сусавын күрсәтә.

Өченчесе, күрәсең, Г. Ибраһимовны Колчак тылына җибәрүнең төп максаты – татар Милли Идарәсе әгъзаларының, милли хәрәкәт вәкилләренең, татар байлары һәм зыялыларының юлын күзәтү, аларны барлау, аклар ягындагы урынын-ролен билгеләү. Бәлки, бу очракта билгеле шәхесләрне кулга төшерү бурычы да куелган булгандыр:



В марте 1918 года, когда Гражданская война в стране усиливалась, Г. Ибрагимов переехал с Комиссариатом в Москву. Осенью у него случилось обострение туберкулеза, и от 17 сентября до 6 октября он пролежал в больнице, в середине октября вернулся в Казань.

Летом 1919 года, сначала в одежде грузчика, затем торговца Ибрагимов прошел по городам и селам: Красноуфимск, Екатеринбург, Камышлов, Тюмень, Ишим, Ялуторовский, Петропавловск и Курган, находящиеся под контролем восточного фронта белых. Штаб 5-й армии принял решение отправить его в разведку в тыл Колчака. В апреле 1919 года Ибрагимов пересек фронт около завода Бирбарды в городе Красноуфимске. Вернулся в сентябре, через четыре месяца. Об этом он написал статью «Дошманнар арасында дүрт ай» («Четыре месяца среди врагов»), которая была опубликована 7 сентября 1919 года в газете «Кызыл яу» («Красная армия»). Эту статью перепечатали практически все татарские газеты. Кроме того, закончил выступление с рассказом обо всем, что видел в тылу перед 2,5-тысячной 5-й армии красноармейцев в городе Челябинске. Как только он выступил, сотни солдат написали заявления с просьбой отправить их на линию фронта [Галимджан Ибрагимов: документы и факты; Галимджан Ибрагимов глазами молодых... С. 91]. Эти события были использованы в романе «Наши дни» и драме «Яңа кешеләр» («Новые люди»).

По этой публикации Ибрагимова можно понять цели его путешествия: ставит вопросы о состоянии дел и тут же отвечает на них.

Первое. Отношение народа к Красной армии и войска Колчака. К идеологии советов. Мнение отрядов казаков на стороне белых. Пройдя большую территорию от Башкортостана до Сибири, Ибрагимов выяснил состояния разных народов, представителей разных классов и их позиции в Гражданской войне.

Второе. Беглецы, грузчики, которые были использованы Колчаком в агитационных целях. Ибрагимов, будучи сам

язмадагы Вагыйз Нәүрүзовка карата әйтелгән «Вагыйзне Русиядә чагында ике мәртәбә тотып япкан булсам да, ул ничектер котылып, Колчакстанга барып чыккан» [Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. Т. 6: публицистика (1907–1932). Б. 203] дигән сүзләр шуңа ишарәли. Г. Ибраһимов Милли идарәнең Колчак ярдәме белән татар-башкорт халкына мөстәкыйльлек, азатлык бирү лозунгын күтәрүе, бу эшләрнең башында кемнәр торуы турында да язып үтә, аларның штабы кайда икәнлекне күрсәтә. Милли Идарәнең халыкны күтәрергә көче җитмәячәген ассызыкласа да, әдип аның әле җиңелеп тукталмаганын, яңадан һөҗүмнәр ясаячагын да искәртә: «Бәлки, тагы бер җирдә баш күтәрелер, погонын югалткан ак офицерлар, заводыннан, фабрик-банкысыннан, җир-суыннан аерылган алпавыт-капиталистлар, бәлки, тагы берничә мәртәбә эшче-крәстиән азатлыгына һөҗүм ясарлар. Бәлки, тагы безгә бик авыр көннәр кичерергә туры килер. Ләкин соңгы сүз – безнеке, ахыргы җиңү – пролетариатныкы,



Петропавловск шәһәре күренеше. XX йөз башы
Вид города Петропавловск. Начало XX века



среди грузчиков, отмечает, что их влияние сильно уменьшилось. Народ измучен войной и жаждет спокойной жизни.

Третье. Видимо, основная цель отправки Ибрагимова в тыл Колчака – проследить путь татарских богачей, интеллигенции, представителей движения национального возрождения, членов Милли Идаре, определить их место и роль среди белых. Может, была поставлена задача заполучить отдельных личностей: слова относительно Вагиза Наурузова «хотя два раза ловил и сажал Вагиза в России, он все равно освободился и оказался около Колчака», свидетельствуют об этом [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 6: публицистика (1907–1932). Б. 203]. Г. Ибрагимов так же пишет о том, что Милли Идаре с помощью Колчака поднял лозунг свободы, самостоятельности татаро-башкирского народа, кто находится во главе этого движения, указывает, где находится их штаб. Хоть и подчеркивает, что у Милли Идаре не хватит сил, чтобы сплотить весь народ, Ибрагимов отмечает, что он еще не побежден и будут дальнейшие атаки: «Может, поднимутся где-то в другом месте, может, белые офицеры, лишенные погонов, капиталисты, оказавшиеся без своих заводов, фабрик, банков, земли, может, еще раз нападут на свободу рабочих и крестьян. Может, нам еще предстоит пережить тяжелые дни. Но последнее слово наше. Последняя победа пролетариата, крестьян, всех угнетенных – советов. Мы верим в это так же, как верим, что завтра взойдет солнце» [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 6: публицистика (1907–1932). Б. 204].

Здесь уместно упомянуть еще один факт. В воспоминаниях Г. Баттала об Ибрагимове опровергаются слова писателя о связи Колчака и Милли Идаре: «Когда казанские националисты в 1918 году, спасаясь от красной диктатуры, сбежали в Петропавловск в Западной Сибири, в Омске еще не было диктатуры Колчака. В сентябре того же года организованное Милли Идаре в Уфе демократическое правительство, многие члены которого были социалистами, переселилось в Омск с целью захвата управления разогнанного правительства Сибирии. До окончания этого процесса все

эшче-крәстиән, барча мәзлумнәрнеке – Советларныкы булачак. Иртәгә кояш чыгачагына ничек ышансак, моңа да шулай ышанамыз» [Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. Т. 6: Публицистика (1907–1932). Б. 204].

Бу урында тагын бер фактны телгә алып китү кирәк. Г. Батталның Г. Ибраһимов турындагы хатирәләрендә әдипнең Колчак һәм Милли Идарә бәйләнешләре хакындагы фикерләре кире кагыла. «Казанлы милләтчеләр 1918 елның соңнарына таба, кызыл диктатура басымыннан качып, Көнбатыш Себердәге Кызылъяр (Петропавловск) шәһәренә киткән вакытта Омск шәһәрендә тәгаен «Колчак диктатурасы» дигән бернәрсә дә юк иде әле. Шул ук елның сентябрь аенда Уфа шәһәрендә оештырылган Милли Идарә тарафыннан төзелгән, күп кенә әгъзалары социалистлардан гыйбарәт булган бер демократик хөкүмәт, куып таратылган Сибирия хөкүмәтеннән идарәне үз кулына алу өчен, Омскига киткән иде. Бу процесс тәмам булганчы, бөтен антибольшевистик өлкә хакимиятләре отставкага китәргә тиеш иде. Адмирал



Омск шәһәре күренеше. XX йөз башы
Вид города Омск. Начало XX века




اش

«Эш» газетасы
Газета «Эш»

антибольшевистские областные правительства должны были уйти в отставку. Адмирал Колчак не был членом этого нового правительства. Если я не ошибаюсь, в это время Колчака в Омске еще даже не было. Из Америки он вернулся позднее. Суть вопроса в следующем: адмирал Колчак в ноябре 1918 года под давлением царских офицеров организовал военное правительство в Омске, арестовал социалистических членов организованного в Уфе демократического правительства и объявил себя диктатором всей России. Как и остальные демократы наши казались меж двух огней: между красной и черной диктатурой» [Галимҗан Ибраһимов: мәкаләләр, истәлек-хатирәләр... Б. 447]. Этот документ говорит о том, что советское правительство и большевики опасались Милли Идаре и отправили Ибрагимова в Сибирь, чтобы узнать реальную силу этой организации. В 1919–1920 годах Ибрагимов был членом центральной мусульманской военной коллегии, одновременно руководил редколлегией отдела печати в центральном бюро коммунистической

Колчак бу яңа хөкүмәтнең бернинди әгъзасы түгел иде. Ялгышмасам, ул вакытта Колчак Омскида да түгел иде әле. Америкадан ул соңрак килде. Эшнең хакыйкате шулдыр ки, адмирал Колчак 1918 елның ноябрь аенда Омскидагы иске патша офицерлары басымы астында бер «хәрби хөкүмәт» төзеп, Уфада корылган демократик хөкүмәтнең социалист әгъзаларын кулга алып, үзен бөтен Русиянең диктаторы итеп игълан иткәнчегә кадәр, башка демократлар кебек, безнекеләр дә ике ут арасында – кызыл диктатура белән кара диктатура арасында чолганышта калган иделәр» [Галимҗан Ибраһимов: мәкаләләр, истәлек-хатирәләр. Б. 447]. Әлеге истәлек совет хөкүмәте, большевикларның Милли Идарәдән шикләнүе, аның реаль көчен белү өчен Г. Ибраһимовны Себергә җибәрүе турында сөйли.

Г. Ибраһимов 1919–1920 елларда Үзәк мөселман хәрби коллегиясе әгъзасы, бер үк вакытта РКП (б) ҮК каршындагы Шәрык халыклары коммунистик оешмаларының Үзәк бюросында матбугат бүлеге редколлегиясе җитәкчесе



«Кызыл Армия» газетасы
Газета «Кызыл Армия»





«Кызыл шәрык» журналы
Журнал «Кызыл шарык»

организации восточных народов при ЦК РКП(б). В Казани работал в газетах и журналах «Эш» («Работа»), «Эшче» («Рабочий»), «Кызыл армия» («Красная армия»), «Кызыл Шәрык» («Красный Восток»). В Казани он также вернулся к литературному творчеству, которое на некоторое время было прервано. В 20-е годы Ибрагимов стал истинным лидером татарских писателей, теоретиком, определяющим пути развития новой татарской литературы. Он много печатался, по данным историка А.Л. Литвина, в 1918–1936 годах произведения Ибрагимова были напечатаны 54 раза на 10 языках! [Галимджан Ибрагимов: до¬кументы и факты; Галимджан Ибрагимов глазами моло-дых: авт.-сост. М.-Х. Ибрагимов. Казань: Татар. кн. изд-во, 2012. С. 125].

Роман «Наши дни» (1914–1920), описывающий события первой русской революции и искания татар на пути национальной политики, по словам самого Ибрагимова, был закончен в 1914 году и начал издаваться в издательстве «Гасыр», но издание было прекращено по предписанию

булып тора. Казанда «Эш», «Эшче», «Кызыл армия», «Кызыл Шәрык» кебек газета-журналларда эшли. Казанда ул бераз вакыт тукталып торган әдәби иҗат эшенә әйләнеп кайта. 1920 еллардан Г. Ибраһимов татар язучыларының чын лидеры, әйдаманына, яңа татар әдәбиятының үсеш юлын билгеләүче теоретикка әверелә. Бик күп басыла: тарихчы А.Л. Литвина, в 1918–1936 годах произведения Ибрагимова были напечатаны 54 раза на 10 языках! [Галимджан Ибрагимов: до¬кументы и факты; Галимджан Ибрагимов глазами моло-дых: авт.-сост. М.-Х. Ибрагимов. Казань: Татар. кн. изд-во, 2012. С. 125].

Беренче рус инкыйлабы хәрәкәтләрен һәм татарларның милли сәясәт юлында эзләнүләрен тасвирлаган «Безнең көннәр» романы (1914–1920), Г. Ибраһимовның язуына караганда, 1914 елны тәмамланып, «Гасыр» нәшриятында басыла башлаган булса да, цензура тарафыннан туктатыла. Язучы аның 1919–1920 елларда үзгәртелмичә диярлек дөнья күргәнлеген билгели. Ләкин бу вариант язучыда



«Безнең көннәр» китабы тышлыгы. 1919.
ЯһММУ. Ф. 65. Тасв. 1. С. б. 45

Обложка книги «Безнең көннәр» («Наши дни»). 1919.
ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 5. Ед. хр. 45





«Безнең көннәр» китабының титул бите (Г. Ибраһимов сурәте белән). 1919

Титульная страница книги «Безнең көннәр» («Наши дни», с фотографией Г. Ибрагимова). 1919

цензуры. Писатель отмечает, что в 1919–1929 годах роман был опубликован практически без изменений, но этот вариант вызвал у него недовольство. Ибрагимов говорит, что «основная ошибка романа – отсутствие ленинско-политической установки в понимании революции 1905-го года», и переделывает роман. Второй вариант был опубликован в 1934 году. В романе показана картина сложной, многогранной жизни России начала XX века. Здесь даны социальные оценки общественно-политическим движениям, национализму, вопросам народничества, спору кадимистов и джадидистов среди татар, показаны пути борьбы за национальное возрождение, личную свободу, разные политических течений и их взаимоотношения, развитие самосознания людей демонстрируется на примере многих героев.

В произведении очень сложно выделить основных персонажей. По отношению к перестройке национальной жизни среди молодежи возникают идеологические споры, выделяются разные типы интеллигенции: социал-демократ Зариф

канәгатьсезлек уята, ул «романда төп ялгышлык – 1905 ел революциясен аңлауда әсәрдә Ленинча сәяси установканың булмавындадыр» дип билгели һәм аны кабат эшли, икенче варианты 1934 елны басылып чыга.

Романда XX гасыр башы Россия яшәешенең катлаулы, күпкырлы сурәте тудырыла: иҗтимагый-сәяси хәрәкәтләргә дә, милләтчелек, халыкчылык мәсьәләләренә дә, татарлардагы кадим һәм җәдит тартышларына да гомумиләштереп бәя бирелә, төрле сәяси агымнарның, төркемнәрнең шәхес азатлыгы, милли яңарыш өчен көрәш юллары, үзара мөнәсәбәтләре һәм кешеләрнең үзаңы үзгәрү бик күп геройлар язмышларында тергезелә.

Әсәрдә үзәк геройларны аерып чыгару да кыен. Милләт тормышын үзгәртеп коруга нисбәтле, зыялы яшьләр арасындагы идеологик бәхәсләр, зыялы яшьләрнең төрле типлары: социал-демократ Зариф Булатов, эшче-революционер кавказлы Гәрәй Солтан, эшче Габдулла, эсер Давыт Урманов, анархист Әхмәт Таңгатаров, иттифакчы Нигъмәт



«Безнең көннәр» китабы. 1934
Книга «Наши дни». 1934






«Безнең көннәр» китабы. 1983
Книга «Наши дни». 1983

Булатов, рабочий-революционер, кавказец Герей Солтан, рабочий Габдулла, эсер Давыт Урманов, анархист Ахмет Тангатаров, Нигмат кази, народник Хабип Мансуров, сочувствующие революционной борьбе Джихангир и Сулейман Файзуллин, приказчики Фахри и Габдрахман, представители аристократии Разия Ширинская, Хайдар Акчулпанов, дочь чиновника Гаухар Ильясова, сын богача Йосыфзян. Взгляды этих героев, их судьбы превращают роман в историю отношения татарского общества к революции 1905-го года. Как верно подметил Г. Нигмати, основная тема романа – революционные движения в обществе [Нигъмәти Г. Сайланма әсәрләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1958. Б. 83]. Попытка обозначить страницы жизни шакирдов, духовенства, аристократии расщепляет произведение. Это отмечает и критика своего времени. Когда был опубликован переработанный второй вариант, Г. Сагди, Г. Нигмати и др. критики сравнили произведение с романом «Молодые сердца» – историей любви, посвященной судьбе романтичных влюбленных, которая

казый, халыкчы Хәбип Мансуров, инкыйлаби көрәшкә теләктәш шәкертләр Җиһангир һәм Сөләйман Фәйзуллин, приказчиклар Фәхри һәм Габдрахман, мирзалар вәкилләре Разия Ширинская, Хәйдәр Акчулпанов, чиновник кызы Гәүһәр Ильясова, бай малае Йосыфҗан кебек образларның караш-фикерләре, шәхси язмышлары гәүдәләнү романны татар җәмгыятенең 1905 ел иҗтимагый күтәрелешенә мөнәсәбәте тарихына әверелдерә. Г. Нигъмәти бик дөрес билгеләгәнчә, романда җәмгыять эчендәге чуалыш, буталышларны күрсәтү төп тема итеп алынган [Нигъмәти Г. Сайланма әсәрләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1958. Б. 83]. Шәкертләр, дин әһелләре, мөгаллимнәр, мирзалар, шымчылар һ.б. катлам яшәешенең үзенчәлекләрен калку билгеләргә омтылу әсәрне көпшәкләндерә, тарката, укырга авырлаштыра. Моны үз чоры тәнкыйте дә билгели. Аның эшкәртелгән икенче басмасы басылып чыккач та, Г. Сәгъди, Г. Нигъмәти һ.б. тәнкыйтьчеләр, әсәрне мәхәббәт тарихы, романтик гашыйклар язмышы бер тын белән укырга



«Кызыл чәчәкләр» китабы. 1922

Книга «Кызыл чәчәкләр» («Красные цветы»). 1922






«Кызыл чәчәкләр» китабы. 1958

Книга «Кызыл чәчәкләр» («Красные цветы»). 1958

читается на одном дыхании, в то же время отметили недостатки нового романа.

В послесловии ко второму изданию Ибрагимов оценивает это произведение как основное достижение своей творческой биографии: «Я нахожу, мои литературные творческие силы смогли развиться только благодаря Великой февральской революции. Произведения, которые были изданы до революции, расцениваю лишь как плоды поиска и подготовительного этапа. В целом я смог анализировать классовую войну всей прошлой исторический жизни, особенно борьбу во время первой революции и годы реакции только после Октябрьской революции и под влиянием трудов великого вождя Ленина» [Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. Т. 4: Безнең көннәр. Б. 439].

Действительно, роман воспринимается поворотным моментом в творчестве Ибрагимова-писателя. Практически в каждом последующем произведении писатель описывает

көйләгән «Яшь йөрәкләр» белән чагыштырып, шактый кимчелекләрен күрсәтеп узалар.

Романның икенче басмасына урнаштырылган «Икенче басмага сүз ахыры урынында» дигән текстта Г. Ибраһимов үз иҗат биографиясендә әсәрне иң югары казаныш буларак бәяли: «Мин үземнең әдәби иҗат көчләремнең иркен үсеп китә алулары – тик Бөек Октябрь революциясе аркасында гына мөмкин булды дип табам. Аңа кадәрле басылып чыккан әсәрләремне тик эзләнү һәм әзерлек баскычының җимешләре дип кенә саныйм. Гомумән, бөтен үткән тарихи торышның сыйнфый сугышларын, аеруча беренче революция һәм реакция елларындагы тирән катлаулы сыйнфый көрәш фронтларын аңлап анализларга мин бары Октябрь революциясеннән соң гына, тик бөек юлбашчыбыз Ленинның бу мәсьәләгә каратылган хезмәтләре яктысында гына ирешә алдым» [Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. Т. 4: Безнең көннәр. Б. 439].




«Кызыл чәчәкләр» китабына иллюстрацияләр. Рәссам – Р. Төхфәтуллин. 1958

Иллюстрации к повести «Кызыл чәчәкләр» («Красные цветы»).
Автор – Р. Тухватуллин. 1958






«Кызыл чәчәкләр» китабына иллюстрацияләр. Рәссам – Р. Төхфәтуллин. 1958

Иллюстрации к повести «Кызыл чәчәкләр» («Красные цветы»).
Автор – Р. Тухватуллин. 1958

исторические события, происходящие в стране, с точки зрения романтического героя, предложенного им ранее, трактует, оценивает. Эти произведения в какой-то степени воспринимаются как хроники, запечатлевшие исторические годы, события, которые захватили судьбы сотен и тысяч людей. Драма «Новые люди», повесть «Кызыл чәчәкләр» («Красные цветы»), посвященные установлению советских порядков, событиям Гражданской войны, и роман «Тирән тамырлар» («Глубокие корни»), который по форме является детективом, описывает жизнь деревни, процесс создания коллективных хозяйств, выступают произведениями, показывающими разные этапы преобразований, наступивших после 1917-го года. Оставаясь верным творческому кредо, Ибрагимов написал эти произведения с целью раскрытия исторической действительности на примере человеческих судеб, на примере положительных преобразований.

Драма «Новые люди» (1920) – одно из первых произведений с образами новых людей, воспитанных революцией.

Чыннан да, роман Ибраһимов-язучы иҗатында борылыш ясауга дәлил кебек кабул ителә. Моннан соң иҗат ителгән һәр әсәрендә диярлек әдип илдә барган олы тарихи вакыйгаларны үзе элегрәк тәкъдим иткән актив романтик герой күзлегеннән тасвирлый, шәрехли, бәяли башлый. Әсәрләр, күпмедер күләмдә, әлеге тарихи-сәяси көннәр-елларны, шул заман кешеләре күз алдыннан үткән шаулы өермәләрне, аларның кешеләр язмышын бөтереп үз артыннан алып китүен теркәгән елъязмалар кебек кабул ителә. Совет тәртипләре урнашу, гражданнар сугышы вакыйгаларын яктыртучы «Яңа кешеләр» драмасы, «Кызыл чәчәкләр» повесте, формасы белән детектив, яңа тормыш, күмәк хуҗалыклар төзү процессын яктырткан «Тирән тамырлар» романнары язучының 1917 ел революцияләре алып килгән үзгәрешләрнең төрле этапларын җентекләп сурәтләве кебек кабул ителщ. Алар Г. Ибраһимовның гомуми иҗат кредосына тугры калып, тарихи чынбарлыкны кешеләр язмышы мисалында, уңай үзгәрешләр төсендә яктырту максаты белән язылганнар.




«Тирән тамырлар» китабы. 1928

Книга «Тирән тамырлар» («Глубокие корни»). 1928





«Тирән тамырлар» китабына Г. Ибраһимовның кереш сүзе. 1928

Предисловие Г. Ибрагимова к книге «Тирән тамырлар» («Глубокие корни»). 1928

Драму можно расценивать как произведение, наиболее полно отвечающее требованиям социалистического реализма в творчестве Г. Ибрагимова. Критика своего времени приняла драму как революционное произведение, к примеру Ф. Сайфи-Казанлы отмечает, что основная идея драмы – показать дни борьбы великих, безымянных, безвестных героев, которые пали жертвами в деле революции, тысячами, десятками тысяч. Г. Худаяров определяет драму как камень в фундаменте революционной литературы [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 5: әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933). Б. 262–263].

В основе драмы классовые противоречие, которое выражено в конфликте Батырхана и Хайри. Батырхан – бедный парень, защищает честь любимой, убил клеветника и был отправлен на каторгу, откуда сбежал во время Первой мировой войны, затем он стал социалистом, командиром одного из отрядов Красной армии во время Гражданской революции. Хайри – деревенский богач, защищает белых,

«Яңа кешеләр» (1920) драмасы революцияләр чоры тәрбияләгән яңа кешеләр образын тудыручы беренче әсәрләрдән була. Аны Г. Ибраһимов иҗатындагы социалистик реализм таләпләренә иң тулы җавап бирә торган әсәр дип бәяләргә мөмкин. Үз чорының тәнкыйте драманы революцион әсәр дип кабул итә: әйтик, Ф. Сәйфи-Казанлы аның «төп идеясе иҗтимагый революция юлында исемсез, дансыз меңләп, ун меңләп корбан булган бөек каһарманнарның көрәш көннәрен күрсәтү» дисә, Г.Ходаяров аны «инкыйлаби әдәбият нигезендә зур таш» кебек күрә һ.б. [Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. Т. 5: Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933). Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. Б. 262–263].

Драманың үзәгендә сыйнфый каршылык ята, ул Батырхан һәм Хәйри конфликтында гәүдәләнә. Батырхан – ярлы егет, сөйгәненең намусын яклап, яла ягучыны үтерә, каторгага җибәрелә, Беренче Бөтендөнья сугышына кача, анда социалист булып җитешә, гражданнар сугышы вакытында




«Глубокие корни» китабы. 1987

Книга «Глубокие корни». 1987





«Яңа кешеләр» китабы. 1921

Книга «Яңа кешеләр» («Новые люди»). 1921

сбегает в Сибирь за Колчаком. Есть причина, усложняющая противоречивую ситуацию: Батырхан женился на дочери Хайри без его согласия. Таким образом, через семейные отношения писатель подходит к вопросам классовой борьбы. Причинами борьбы определяет социальное неравенство и стремление к национальной свободе, подчеркивает, что только такой борьбой новые люди, то есть Барытхан, учительница Камар, Тимеркай смогут обеспечить светлое будущее для страны. Это мнение выражено в ответе Батырхана старику Шайбеку, который обнаружил трупы классовых врагов: «Дорога одна, вот эта кровавая дорога – священный путь!» [Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. Т. 3: Кызыл чәчәкләр. Алмачуар. Тирән тамырлар. Яңа кешеләр. Б. 426].

Повесть «Красные цветы» (1921), охватывающая судьбы пяти молодых людей, выросших вместе, их дружбу, их жизненные пути, которые разделились под действием разных общественно-исторических событий, показывает

Кызыл Армия отрядларының берсендә командир. Хәйри – авыл бае, акларны яклый, Колчак артыннан Себергә кача. Бу каршылыкны катлауландыра торган шәхси сәбәп бар, ул – Батырханның Хәйри ризалыгыннан башка аның кызына өйләнүе. Шулай Г. Ибраһимов гаилә мөнәсәбәтләре аша сыйнфый көрәш мәсьәләсенә килә, көрәшнең сәбәпләре итеп иҗтимагый тигезсезлек һәм милли азатлыкка ирешү өметен билгели. Шушы көрәш аша гына яңа кешеләрнең – Батырхан, мөгаллимә Камәр һәм Тимеркәйләрнең – илне якты киләчәккә илтәчәген ассызыклый. Бу фикер Батырханның «сыйнфый дошманнар» мәетләренә тап булган Шәйбәк картка биргән җавабында кабатлана: «Юл бер генә! Менә шушы канлы юл – изге юл!» [Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. Т. 3: Кызыл чәчәкләр. Алмачуар. Тирән тамырлар. Яңа кешеләр. Б. 426].

Бергә уйнап үскән биш егет тормышын, дуслыгын, аларның иҗтимагый-тарихи вакыйгалар тәэсирендә төрле сукмаклардан аерылып киткән язмышын колачлаган «Кызыл



«Алмачуар» китабы. 1922
Книга «Алмачуар» («Чубарый»). 1922






«Алмачуар» китаплары тышлыклары. 1957, 1967
Обложка книги «Алмачуар» («Чубарый»). 1957, 1967

отношение к революции 1917-го года представителей разных классов в татарской деревне: торговцев, мулл, ремесленников, бедных крестьян. Повесть во главу угла ставит актуальный для татарского общества спор о путях достижения национальной свободы. Ответ на вопрос, как можно достичь национальной свободы – через классовую борьбу и революцию, или объединением одной идеей национальных и религиозных групп, один: только революция и активная борьба могут привести к светлому будущему. Писатель будто еще раз оправдывает свой выбор, сделанный в 1917 году: ошибочность идеи использования революции для религиозного и национального обновления показывает на примере судьбы богача Гали, образованного Фазыла. Строки из последнего письма Гали: «Я не могу вынести жизнь, которую вы построите… я уже не верю тому, что когда-нибудь вернутся прежние дни, прежние идеи.. Все имущество пропало… Дом разрушен… Совесть тоже куда-то исчезла. Скажите, ради чего мне жить?» доказывают, что он тоже жил не

чәчәкләр» (1921) повесте татар авылындагы сыйнфый катламнар: сәүдәгәрләр, муллалар, һөнәрчеләр, ярлы крестьяннар – вәкилләренең 1917 елгы вакыйгаларга мөнәсәбәтен ача. Повесть татар җәмгыяте өчен актуаль булган, милли азатлыкка ирешү юлларына кагылышлы бәхәсне үзәккә куя. Милләткә ирекне сыйнфый көрәш һәм инкыйлаб юлыннан барып яки төрле милли-дини төркемнәрнең бер идея тирәсендә берләшүе аша алырга мөмкинме дигән сорауга җавап бер: язучы бары тик инкыйлаб һәм көрәш кенә якты киләчәккә илтәчәген ассызыклый. Әйтерсең лә язучы әдәби әсәр эчендә үзенең 1917 елны сайлаган юлын тагын бер кат яклап чыга: инкыйлабны файдаланып милли-дини үсеш юлыннан бару идеясенең ялгыш икәнлеген Гали бай, укымышлы Фазыйллар язмышы мисалында сурәтли. Галинең соңгы хатындагы: «Сез төзиячәк тормышны мин күтәрә алмыйм... Элекке көннәрнең, элекке идеалларның кайчан да булса яңадан бер кайтуына иманым калмады... Мал бетте... Йорт-җир китте... Дәрт, вөҗдан да кайдадыр



«Алмачуар» китабына иллюстрация Рәссам – Н. Байбурин. 1967
Иллюстрация к рассказу «Алмачуар» («Чубарый»). Автор – Н. Байбурин. 1967





«Алмачуар» китабына иллюстрация Рәссам – Н. Байбурин. 1967
Иллюстрация к рассказу «Алмачуар» («Чубарый»). Автор – Н. Байбурин. 1967

только богатством, но и идеей. Слова Султана относительно Фазыла «польза от этих ученых мужей, наверное, очень большая, но в дни тяжелой борьбы тысячи их не стоит даже ноготка одного Гилязи, одного Шахбаза» показывают отношение к интеллигенции в новых условиях. Трагедия Гилязи и Шахбаза подчеркивает кровавое начало строительства новой жизни.

Пять друзей из деревни Зенгер Чишма – Султан, Шахбаз, Гали, Гыйлази, Фазыл – представлены как национальные характеры. Но революция раскидывает их по разным лагерям. Писатель обращается к языку символов: произведение начинается с изображения красных семян, с истории о том, как выросли красные цветы и распространились на весь мир. То, как пять мальчишек из Зенгер Чишме выросли, оказались в центре исторических событий и каждый проживал собственную судьбу, описывает рассказчик – один из этих мальчишек, Султан, что позволяет удачно использовать в повести приемы психологизма,

югалды. Әйтегез, ни белән яшим?» [Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. Т. 3: Кызыл чәчәкләр. Алмачуар. Тирән тамырлар. Яңа кешеләр. Б. 90] дигән юллар аның да байлык артыннан куып кына түгел, бәлки элек идеаллар белән яшәгән булуын күрсәтә. Солтанның Фазыйлга нисбәтле әйткән «Мондый укымышлы ирләрнең безгә файдасы, бәлки, зурдыр, ләкин боларның меңе авыр көрәш көннәрендә бер Гыйлаҗиның, бер Шаһбазның кисеп ташлаган тырнагына да тормыйлар бит» [Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. Т. 3: Кызыл чәчәкләр. Алмачуар. Тирән тамырлар. Яңа кешеләр. Б. 101] сүзләре зыялыларның яңа вазгыятьтә ничек кабул ителүенә ишарә ясый. Гыйлаҗи һәм Шаһбаз фаҗигаләре яңа тормыш төзүнең кан коеп башлануын ассызыклый.

Повестьта тудырылган Зәңгәр Чишмә авылы, биш дус – Солтан, Шаһбаз, Гали, Гыйлаҗи, Фазыйл образлары милли характерлар буларак иҗат ителгәннәр. Ләкин инкыйлаб аларны ике капма-каршы лагерьга аера. Язучы символлар теленә мөрәҗәгать итә: әсәрне кызыл орлыклардан кызыл




Г. Ибраһимовның Г. Кариев исем. Казан татар дәүләт яшь тамашачылар театры тарафыннан сәхнәләштерелгән «Алмачуар» спектакле афишасы. 2004

Афиша спектакля «Алмачуар» («Чубарый») в Казанском татарском театре юного зрителя. 2004





«Алмачуар» спектакленнән күренеш

Сцены из спектакля «Алмачуар» («Чубарый»)

оценивать события изнутри. Как и в своем дореволюционном творчестве, писатель обращается к приему потока сознания. Здесь Ибрагимов большое внимание уделяет национально-этнографическим явлениям, народным обрядам и обычаям. Это свойство его творчества с годами только усиливается.

Рассказ «Алмачуар» («Чубарый», 1922) посвящен любви татарского человека к коню, сабантуям, скачкам, встречам с родственниками. Любовь деревенского мальчишки Закира к своему коню отождествляется с любовью татар к лошадям, скачкам, праздникам, которая заложена в генетической памяти. Писатель стремится раскрыть национальный менталитет, национальное мировоззрение татар, показывая все это как исчезающую красоту жизни.

В романе «Казакъ кызы» («Дочь степи», 1923) Ибрагимов поднимает вопросы влияния историко-политических событий на тюркские народы в целом, на изменение тюркского мира. На фоне увлекательной и трагической

чәчәкләр үсеп, бөтен дөньяга таралу хакындагы хикәят белән башлап җибәрә. 5 малайның, Зәңгәр чишмә буенда уйнап үсеп, тарихи вакыйгаларның үзәгендә кайнавын, һәрберсе үз юлы буйлап язмышын язуын хикәяләүче әлеге малайларның берсе Солтан булу – повестьтагы психологизм алымнарын гаять уңышлы файдаланырга, вакыйгаларны эчтән торып бәяләргә мөмкинлек бирә. Инкыйлабка кадәрге иҗатындагы шикелле үк, язучы аң һәм кичереш агышына мөрәҗәгать итә. Повесть Г. Ибраһимовның милли-этнографик күренешләргә, халык йола-гадәтләренә аерым игътибар итүе хакында сөйли. Бу сыйфат аның иҗатында алга таба да көчәя бара.

«Алмачуар» (1922) хикәясе татар кешесенең атка мәхәббәтен, сабантуйлар, көрәш, ат чабыштыруларның матурлыгын күрсәтә. Авыл малае Закирның атка мәхәббәте – татар кешесенең аңында, аң төпкелендә яшәүче атка, ат чабышларына, сабантуй бәйрәмнәренә мәхәббәт белән тәңгәлләштерелә. Язучы милли менталитетны, татар кешесенә



«Алмачуар» спектакленнән күренешләр
Сцены из спектакля «Алмачуар» («Чубарый»)






«Сайланма әсәрләр». Биш китапта. 2 нче китап. 1934
«Избранные произведения». В пяти книгах. Книга 2-я. 1934

истории любви романтических героев Арсланбая и Карлыгач-Сылу, их борьбы за собственное счастье писатель рассказывает о жизни казахских степей, о политических и общественных процессах, происходящих там. Необходимо отметить, что история любви в этом романе расписана настолько мастерски эмоционально, что позволяет собрать воедино это полотно, несмотря на обилие общественных и политических мотивов. По справедливому замечанию Гали Рахима, роман открывает неизвестный ранее в татарской литературе мир: «Это произведение заставляет вспомнить поэмы самобытных степных поэтов, эпос, где отражена спокойная, неторопливая жизнь степных народов» [Рәхим Г. «Казакъ кызы» // Безнең юл. 1925. № 5. Б. 209.

Веками жившая на один лад степная жизнь претерпевает серьезные изменения после революции, куда проникают выборы в Государственную думу, а борьба политических партий превращается в борьбу за тюркский мир, за тюркский юрт. Две силы, два самых сильных рода

хас милли күзаллауны ачыкларга, яктыртырга омтыла, моны югала баручы матурлык дәрәҗәсенә куя.

«Казакъ кызы» (1923) романында Г. Ибраһимов сәяси-тарихи вакыйгаларның гомумән төрки халыкларга тәэсире, төрки дөньяны ничек үзгәртүе мәсьәләсен күтәрә. Мавыктыргыч һәм фаҗигале мәхәббәт тарихы, романтик геройлар Арысланбай белән Карлыгач-Сылуның үз бәхете-мәхәббәте өчен көрәше фонында язучы казакъ далаларындагы көнитеш, сәяси, иҗтимагый көрәш хакында сөйли. Әйтергә кирәк, бу романда мәхәббәт тарихы шулкадәр оста һәм тәэсирле уйланган, ул романны, иҗтимагый-сәяси мотивларның күп булуына карамастан, бербөтен итеп җыярга мөмкинлек бирә. Г. Рәхим хаклы рәвештә билгеләгәнчә, роман татар әдәбиятында моңарчы булмаган, күзәтелмәгән дөнья ача: «Бу әсәр күчмә төрки халыкларның шундый тыныч, мәһабәт агымлы, саф дала исе аңкып торган эпосларын, табигый дала шагыйрьләре тарафыннан тудырылган поэмаларын искә төшерә» [Рәхим Г. «Казакъ кызы» // Безнең юл. 1925. № 5. Б. 210].




«Сайланма әсәрләр».
Дүрт томда. III нче том. 1936
«Избранные произведения».
В четырех томах. Том III. 1936






«Дочь степи» китабы. 1934
Книга «Дочь степи». 1934

(кара-айгыр и сарман) и их главы – Байтуре и Сарсымбай – образуют две партии, выражая два разных образа жизни. Сарсымбай, стремившийся сохранить привычные порядки, его правая рука Биремджан – патриоты своей земли. Предводители земли кара-айгыр – Байтуре и Азымбай – очень хорошо чувствуют веяние времени, но стремятся только к личному обогащению и ради своих интересов готовы продать юрт белому царю.

Общественная борьба влияет на судьбы людей. Ибрагимов показывает это на примере Карлыгач-Сылу, которая ради своей любви смогла противостоять решению родителей, рода. Карлыгач, которая была наречена Калтаю, молодому человеку из рода кара-айгыр, с целью скрепить единство земли единством крови, отказывается от своего жениха. Писатель подчеркивает чрезвычайность этого явления на примере судьбы других женщин: Чулпан, Тукал, особенно Гульфанис, которая была похищена, но снова возвращена в род. Устами матери Алтынчеч писатель говорит

Гасырлар дәвамында бер көйгә салынган дала тормышына инкыйлабтан соң Дәүләт Думасына сайлаулар ташкыны үтеп керә, сәяси партияләр көрәше төрки ил-йорт өчен көрәшкә әверелә. Иң йогынтылы һәм көчле ике ыруг – кара-айгыр һәм сарман башлыклары Байтүрә һәм Сарсымбай җитәкләгән ике партия ике төрле яшәү рәвешен алга куя. Күнегелгән тәртипләрне үзгәртергә ашыкмаган Сарсымбай, аның уң кулы Биремҗан әкә – үз җиренең патриотлары. Кара-айгыр йортының җитәкчеләре, заман агышын бик тиз тоемлаучы Байтүрәләр, Азымбайлар исә – шәхси байлыкка омтылучы, үз мәнфәгатьләре өчен ил-йортны ак патшага сатарга әзер кешеләр итеп тасвирлана.

Иҗтимагый көрәш кешеләрнең язмышына да тәэсир итә. Ибраһимов моны Карлыгач-Сылуның мәхәббәте хакына ата-ана, нәсел-ыру карарына каршы чыгуында гаҗәеп оста сурәтләп бирә. Йола саклап, «җир берлеген кан белән беркетергә» дип кара-айгырлардан булган Калтайга ярәшелгән Карлыгач егеттән баш тарта. Язучы моның гайре табигый хәл булуын башка хатын-кызлар – Чулпан, Тукал, бигрәк тә урланып та кабат ярәшелгән ыруга кайтарылган Гөлфаныс – язмышында сурәтләп бирә. Анасы Алтынчәч авызыннан гаять куркыныч сүзләр әйттерә: «Телемне алмасаң, без биргән җегетне ташлап, кодалар белән талаш чыгара торган булсаң, сиңа имезгән ак сөтемне бәхилләмәм!» [Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. Т. 2: Яшь йөрәкләр. Казакъ кызы. Б. 353]. Ләкин бу сүзләр дә, казакъ далаларында чын сугыш башлану куркынычы да кызны туктатып кала алмый. Ул сөйгәне Арысланбай белән кача.

Шәхси бәхет өчен көрәш сәяси көрәш белән кушылып китә һәм Карлыгачның йола бозуы, ахыр чиктә, Сарсымбайның да, Арысланбайның да илдән сөрелүенә китерә. Шунысы кызык, язучы, туй уздыруларны, аннан соңгы сайлаулар вакыйгаларын бик җентекләп тасвирласа да, Арысланбай урлаганнан соң Карлыгач-Сылуга, аның кичерешләренә кагылмый. Укучы кыз көрәшенең бәхет китермәвен бары тик тышкы, сәяси вакыйгаларда гына күрә. Әсәрнең идеясе,



страшные слова: «Если не послушаешь меня, если бросишь молодого человека, которого мы предлагаем, если станешь причиной ссоры со сватьями, я проклинаю молоко, которым тебя кормила!» [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 2: Яшь йөрәкләр. Казакъ кызы. Б. 353]. Но даже эти слова, опасность войны в казахских степях не могут остановить девушку, она сбегает с любимым Арсланбаем. Борьба за личное счастье объединяется с политической борьбой, и нарушение Карлыгач традиции, в конечном счете, приводит к изгнанию и Сарсымбая, и Арсланбая. Что интересно, писатель очень подробно описывает свадьбу, последующие за тем выборы, но совершенно не касается переживаний Карлыгач-Сылу после ее похищения Арсланбаем. Читателю через описание политических событий остается только догадываться, что желанного счастья девушка не достигла. Таким образом, основная идея произведения заключается в том, что борьба за личное счастье зачастую мешает борьбе за мир, за национальную свободу.

В романе мастерски и с этнографической точностью описана материальная и духовная жизнь казахского народа: повседневность, кочевничество, обряды, обычаи, похищение невесты, похоронные обряды, застолья, свадьбы и т.д. С одной стороны, произведение является этнографической энциклопедией казахской жизни, с другой стороны, пробуждает ассоциации с древним образам жизни, с кочевым периодом истории тюрко-татар. Общество, где уживаются язычество и исламские традиции, естественное понимание справедливости, образ жизни, довольствуясь тем, что дает природа, привлекает своей первозданностью. Автор с сожалением рассказывает об исчезновении такой жизни. В то же время передача событий и переживаний больше через диалоги уводит писателя в сторону от потока сознания, внутренних диалогов, философских размышлений, которые были свойственны раннему творчеству.

В 1923 году было опубликовано, пожалуй, самое дискуссионное произведение Г. Ибрагимова «Адәмнәр»

шулай итеп, шәхси бәхет өчен көрәшүнең ил тынычлыгы, азатлыгы өчен көрәшкә комачаулавы турында сөйли.

Роман казакъ халкының матди һәм рухи тормышын, көнитеш рәвешен, мал карау, күчеп йөрүләрне, гадәт-йолаларны, кыз урлау, мәет күмү, мәҗлесләр, туйларны – барысын-барысын этнографик төгәллек белән сурәтләп һәм вакыйгалар агышына оста үреп бара. Бер яктан, әсәр казакъ тормышының этнографик энциклопедиясе дәрәҗәсендә булса, икенче яктан, төрки-татарларның да күчмә заманнары, борынгы яшәү рәвешләре белән ассоциацияләр уята. «Ясаган иягә» ышану (мәҗүсилек) һәм ислам йолалары гармониядә яши торган тирәлек, гаделлекнең табигатьтәгечә аңланылуы, табигать биргән нигъмәтләр белән көн күрү рәвеше самимилеге белән үзенә җәлеп итә. Бу тормышның югала баруын автор үкенеч хисе белән ассызыклый. Бер үк вакытта вакыйгалар һәм кичерешләрнең күбрәк сөйләү һәм сөйләшүләрдә бирелеше язучыны моңа кадәр иҗатына хас булган аң-кичереш агышына, эчке



«Адәмнәр» китабы. 1923
Книга «Адәмнәр» («Люди»). 1923






«Адәмнәр» китабы. 1998 ел
Книга «Адәмнәр» («Люди»). 1998

(«Люди», 1923), посвященное голоду, постигшему Поволжье в 1921 году. Произведение «полностью состоит из темных, ужасающих картин… совершаемые людьми, дошедшими до сумасшествия, до каннибализма, в результате ужасного голода, действия описаны жестко, даже жестоко с фактографической и натуралистической точностью» [Галимҗан Ибраһимов һәм хәзерге заман: тууына 115 ел тулуга багышланган фәнни конференция материаллары. Казан: Фикер, 2002. Б. 95–96]. Писатель восстанавливает эту трагедию с такой натуралистической точностью, словно хочет предостеречь от повторения такого типа явлений, подчеркивает, что голод способен разрушить веками создаваемые устои общества и моральные нормы, человечность, ведет разговор в целом о гуманности человека, способности перешагнуть через все ограничения при чрезвычайных обстоятельствах.

После приезда в Казань в жизни Г. Ибрагимова случилось большое событие: он решил создать семью. В 1920 году женился на Мастуре Гильмановне Файзуллиной (1898–

монологларга, фәлсәфи чигенешләргә өстенлек бирүдән читкә алып китә.

Шушы ук елны аеруча күп бәхәсләр уяткан әсәр – Идел буендагы 1921 елгы ачлык вакыйгаларына багышланган «Адәмнәр» (1923) повесте иҗат ителә. Әсәр «тулысынча кара, дәһшәтле картиналардан тора (...) коточкыч ачыгу нәтиҗәсендә акылдан шашарлык булган, кеше ите ашауга барып җиткән адәмнәрнең кылганнары кырыс, хәтта әйтергә кирәк, фактографик, натуралистик тәфсиллек белән сурәтләнә» [Галимҗан Ибраһимов һәм хәзерге заман: тууына 115 ел тулуга багышланган фәнни конференция материаллары. Казан: Фикер, 2002. Б. 95–96]. Язучы әлеге фаҗигане натуралистик төгәллек белән тергезеп, гүя аның кабатланырга тиеш түгеллеген искәртә. Ачлыкның җәмгыятьтә гасырлар буе камилләшеп килгән әхлакый нормаларны, кануннарны, кешелеклелек сыйфатларын җимерерлек көч булуын билгели. Кешенең кешелеклелеге дә, чиктән тыш хәлләргә куелганда теләсә



Г. Ибраһимов хатыны Гөлсем Мөхәммәдова һәм дуслары белән. Ялта. ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 5. С. б. 36

Г. Ибрагимов с женой Гульсум Мухаммедовой и друзьями. Ялта. ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 5. Ед. хр. 36





Г. Ибраһимов дуслары белән. Ялта. ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 5. С. б. 35

Г. Ибрагимов с друзьями. Ялта. ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 5. Ед. хр. 35

1976) – единомышленнице, члене Бюро мусульманских солдаток с 1917 года. Однако уже через год семья распалась [Биктимерова Т. Хәнифәме, Мәстүрәме?: [Галимҗан Ибраһимовның беренче хатыны Мәстүрә Фәйзуллина тур.] // Казан утлары. 1998. № 12.]. Летом 1923 года Ибрагимов попытал счастье со студенткой третьего курса медицинского факультета Казанского университета из Астрахани Уммугульсум Давыдовной Мухаммедовой (1903–1988). Невероятно красивая Гульсум стала для писателя товарищем, помощником, опорой. 5 ноября 1926 года на радость Галимджану родился сын Рустем.

В Казани Ибрагимов возобновляет педагогическую работу: на военно-командных курсах и в школе партии ведет политическую науку. 15 ноября 1925 года дает уроки общественных наук и татарского языка и литературы в Татарском коммунистическом университете и в школе партии, открытой с целью подготовки национальных, партийных и государственных работников.

нинди чикләүләрне атлап чыгарга сәләтле булуы турында да сүз алып бара.

Казанга кайткач, Г. Ибраһимов тормышында тагын бер зур вакыйга була: ул гаилә кору, балалар үстерү омтылышлары ясый. Иҗтимагый фикердәше, 1917 елдан Мөселман солдаткалар бюросы әгъзасы булган Мәстүрә Гыйльман кызы Фәйзуллина белән 1920 елда корган оя бик тиз таркала [Биктимерова Т. Хәнифәме, Мәстүрәме?: [Галимҗан Ибраһимовның беренче хатыны Мәстүрә Фәйзуллина тур.] // Казан утлары. 1998. № 12. 175–177 б.]. 1923 елның җәендә ул Казан университетының медицина факультетында 3 нче курста укучы Әстерхан кызы Гөлсем Давыт кызы Мөхәммәдова белән кабат гаилә тормышын башлап җибәрә. Гаять чибәр кыз Гөлсем әдип өчен чын-чынлап таянычка, иптәшкә, ярдәмчегә әверелә. 1926 елның 5 ноябрендә, олыгаеп бара торган Галимҗанны сөендереп, уллары Рөстәм туа.

Казанда Г. Ибраһимов педагогик эшчәнлеген яңарта: хәрби команда курсларында һәм партия мәктәбендә сәясәт



Г. Ибраһимов хатыны Гөлсем Мөхәммәдова, улы Рөстәм һәм Мөхәммәт Таһиров белән. Ялта. ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 5. С. б. 37

Г. Ибрагимов с женой Гульсум Мухаммедовой, сыном Рустемом и Мухамметом Тагировым. Ялта. ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 5. Ед. хр. 37





«Шәрыкнең бөек революционеры Мулланур Вахитов» китабы. 1919

Книга «Шәрыкнең бөек революционеры Мулланур Вахитов» («Великий революционер Востока товарищ Мулланур Вахитов»). 1919

28 декабря 1923 года Ибрагимов был избран членом Центрального исполнительного комитета Татарстана, вплотную начал заниматься изучением истории партии, революционного движения среди татар, стал одним из организаторов перевода В.И. Ленина на татарский язык. Пишет историко-публицистические книги «Шәрыкның бөек революционеры Мулланур иптәш Вахитов» («Великий революционер Востока товарищ Мулланур Вахитов», 1919), «Бөек Октябрь революциясе һәм пролетариат диктатурасы» («Великая Октябрьская революция и диктатура пролетариата», 1920), «Татарлар арасында революция хәрәкәтләре (1905)» («Революционные движения среди татар (1905)», (1925), «Татар студентлары хәрәкәте тарихыннан» («Из истории движения татарских студентов», 1922), «Урал һәм уралчылар» («Урал и уральцы», 1927). В них четко видна классовая позиция Ибрагимова. Книга «Иҗтимагый, әдәби хәрәкәтләр тарихын тикшерүдә марксизм ысулы» («Использование марксистского метода в исследовании истории

фәнен укыта. 1922 елның 15 ноябрендә милли партия һәм дәүләт эшлеклеләре әзерләү максатында ачылган Партия мәктәбендә һәм Татар Коммунистлар университетында иҗтимагый фәннәрдән һәм татар теле-әдәбиятыннан дәресләр бирә.

1923 елның 28 декабрендә Татарстан Үзәк Башкарма Комитеты әгъзасы итеп сайлана. Татарлар арасында революция хәрәкәтләре, партия тарихын өйрәнү белән ныклап шөгыльләнә башлый. В.И. Ленин әсәрләрен татарчага тәрҗемә итүне оештыручылардан була. «Шәрыкның бөек революционеры Мулланур иптәш Вахитов» (1919), «Бөек Октябрь революциясе һәм пролетариат диктатурасы» (1920), «Татарлар арасында революция хәрәкәтләре (1905)» (1925), «Татар студентлары хәрәкәте тарихыннан» (1922), «Урал һәм уралчылар» (1927) дигән тарихи-публицистик китаплар яза. Аларда Г. Ибраһимовның сыйнфыйлык позициясеннән торып иҗат итүе ачык күренә. 1922 елны дөнья күргән «Иҗтимагый, әдәби хәрәкәтләр тарихын тикшерүдә



«Пролетариат әдәбияты турында» китабы. 1924.
ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 1. С. б. 11

Книга «Пролетариат әдәбияте турында» («О пролетарской литературе». 1924.
ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 1. Ед. хр. 11





«Пролетариат әдәбияты турында» китабының эчтәлеге. 1924

Оглавление книги «Пролетариат әдәбияте турында» («О пролетарской литературе»). 1924

общественных и литературных движений»), опубликованная в 1922 году, показывает, что он уже освоил марксистскую методологию.

Взгляды Г. Ибрагимова в целом на литературу, на ее цели и функции, критерии оценки отдельных произведений претерпели значительные изменения: и в этих вопросах усилилось влияние классового подхода. В статьях «Пролетариат әдәбияты турында» («О пролетарской литературе», 1924), «Кара маяклар, яки Ак әдәбиятлар» («Черные вехи, или Белоэмигрантская литература, 1924), «Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак?» («Каким путем пойдет татарская литература?», 1927), написанных в духе марксизма-ленинизма, он подчеркивает, что литература является эффективным оружием в классовой борьбе, говорит о том, что дореволюционная литература не могла играть значительной роли в пролетарской борьбе, а эмигрантская литература вредна по сути. Самое печальное, пожалуй, то, что Г. Ибрагимов противопоставляет классовость и

марксизм ысулы» хезмәте инде аның марксизм методологиясен ныклап үзләштергәнлеге турында да сөйли.

Г. Ибраһимовның әдәбиятка, аның максаты һәм вазифалары, әсәрләрне бәяләү критерийлары мәсьәләләренә карашы, тамырыннан булмаса да, шактый үзгәреш кичерә, бу мәсьәләләрдә дә сыйнфыйлык рухы көчле. Марксистик-ленинчыл идеология тәэсирендә язылган «Пролетариат әдәбияты турында» (1924), «Кара маяклар, яки Ак әдәбиятлар» (1924), «Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак?» (1927) кебек мәкаләләрендә ул әдәбиятның сыйнфый көрәштә үз сүзен әйтергә тиешле идеологик корал булуын ассызыклый, революциягә кадәрге әдәбиятның пролетариат көрәшендә әһәмиятле роль уйный алмавы, эмиграциядә иҗат ителгән әсәрләрнең исә зарарлы булуы турында сөйли. Әмма иң аянычлысы, Г. Ибраһимов «сыйнфыйлык һәм миллилекне бер-берсенә каршы» куя, «татар иҗтимагый фикеренең төрле агымнары турында сүз кузгата һәм аларга сыйнфыйлык позициясеннән торып бәя бирә һәм чит



«Кара маяклар, яки Ак әдәбиятлар» китабы. 1924.
ЯһММУ. Ф. 65. Тасв. 1. С. б. 28

Книга «Кара маяклар, яки Ак әдәбиятлар» («Черные вехи, или Белоэмигрантская литература»). 1924.
ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 1. Ед. хр. 28





«Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак?» китабы. 1927.
ЯһММУ. Ф. 65. Тасв. 1. С. б. 33

Книга «Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак?» («По какому пути пойдет татарская культура?»). 1927.
ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 1. Ед. хр. 33

национализм, «говорит о разных течениях в татарском общественном движении, оценивает их с позиций классовой принадлежности участников, а представителей татарской интеллигенции, которые смогли спастись из крючка большевизма в эмиграции, обвиняет в контрреволюционной деятельности» [Абдуллин Я. Милләт язмышы: уйланулар. Казан: Фән, 1999. Б. 142]. Я.Г. Абдуллин отмечает, что эти труды Г. Ибрагимова, к сожалению, в будущем стали основой для многих авторов, которые делали обвинительные выступления по отношению к деятелям национального движения.

Труд под названием «Пролетариат әдәбияты турында» («О пролетарской литературе»), который был издан отдельной книгой в Москве, носит теоретический характер. Начинается работа с обзора концепций, которые с разных сторон подходят к анализу литературы. В отдельных главах рассматриваются вопросы отношения марксизма к литературе, классовости в литературе, связь литературы

илгә китеп большевизм элмәгеннән котыла алган татар зыялыларын контрреволюцион эшчәнлектә гаепли» [Абдуллин Я. Г. Ибраһимов: фикери һәм иҗади эволюциясе // Абдуллин Я. Милләт язмышы: уйланулар. Казан: Фән, 1999. 142 б.]. Я.Г. Абдуллин бу хезмәтләрнең, кызганычка каршы, алга таба милли хәрәкәт эшлеклеләрен гаепләп язган бик күп авторлар өчен таяныч булуын әйтә.

«Пролетариат әдәбияты турында» исеме астында Мәскәүдә аерым китап булып басылып чыккан хезмәт теоретик характерда. Ул әдәбиятка төрлечә якын килүче концепцияләрне күзәтүдән башлана. Аерым бүлекләрендә марксизмның әдәбиятка карашы, әдәбиятта сыйнфыйлык, аның иҗтимагый тормыш белән бәйләнеше кебек мәсьәләләр карала, татар дөньясындагы мәгърифәтчелек хәрәкәте, 1905 ел инкыйлабы тәэсирендә күтәрелеш, XX йөз башы һәм 1917 елдан соңгы аерым карашларга кагылып узыла. Нәтиҗә ясап, Ибраһимов болай яза: «Идеология, әдәбият, югарыдан күренгәнчә,




Г. Ибраһимовның РКП(б) әгъзалыгына «Личный листок» күчермәсе (1–2 битләре). 1924. ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 2. С. б. 59

Копия «Личного листка» Г. Ибрагимова на членство РКП(б). 1–2 страницы. 1924. ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 2. Ед. хр. 59






Г. Ибраһимовның РКП(б) әгъзалыгына «Личный листок» күчермәсе (3–4 битләре). 1924. ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 2. С. б. 59

Копия «Личного листка» Г. Ибрагимова на членство РКП(б). 3–4 страницы. 1924. ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 2. Ед. хр. 59

с общественной жизнью, затрагивается история просветительского движения в татарской культуре, общественный подъем под воздействием революции 1905 года, отдельные взгляды и мнения, господствовавшие в татарском обществе начала XX века и после революции 1917 года. Подводя итоги, Г. Ибрагимов пишет следующее: «...идеология, литература всегда и везде служат жизни, они обязаны быть связанными с событиями общественной жизни, подпитываться ими, поэтому и эпоха диктатуры пролетариата должна иметь свою собственную идеологию, искусство и литературу» [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 5: Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933). Б. 444].

Отдельно останавливаясь на вопросе культурного наследия, Г. Ибрагимов и здесь пишет достаточно резкие, имевшие негативные последствия в дальнейшем изучении татарской литературы слова: «Ни один марксист не внесет в список произведений, способных помочь в воспитании рабоче-крестьянской массы и молодого поколения в плане

һәрвакыт, һәркайда тормышның хезмәтчесе, иҗтимагый һәр хәлләргә бәйләнышлы, шулар белән сугарылган булуы мәҗбүри бер эш булганга, пролетариат диктатурасы дәверендә дә үзенең аерым идеологиясе, сәнгате һәм әдәбияты булу мәҗбүридер» [Ибраһимов Г. Пролетариат әдәбияты турында // Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. Т. 5: Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933). 444 б.].

Мәдәни мирас мәсьәләсенә аерым тукталып, бу өлкәдә дә Г. Ибраһимов гаять кырыс, алга таба татар әдәбиятын өйрәнүгә тискәре йогынты ясаган сүзләр әйтә: «Һичбер марксист «Сәлимә», «Мәгыйшәт» яки «Зөләйха»ларны эшче-крәстиян массасының, яшь буынның фикер, тойгы, хыял, мәгънә тәрбияләренә ярдәм бирә, сыйнфый аңнарын оештыра торган әсәрләр исемлегенә кертмәячәк» [Ибраһимов Г. Пролетариат әдәбияты турында. 465 б.]. Мәкалә татарның каләм ияләрен пролетариат әдәбияты тудырырга чакыру белән тәмамлана.


Всероссийская перепись

Бөтенроссиякүләм коммунистлар партиясе әгъзаларының санын алуда катнашкан Г. Ибраһимовның анкетасы. 1925.
ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 2. С. б. 60

Анкета Г. Ибрагимова во всероссийской переписи членов коммунистической партии. 1925.
ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 2. Ед. хр. 60





Муса Бигиев (1875–1949)
Муса Бигиев (1875–1949)

развития их сознания, чувств, мечтаний и замыслов, способных формировать классовое сознание, «Салиму», «Магишат» или «Зулейху»» [Там же. Б. 465]. Статья завершается призывом татарских писателей к созданию пролетарской литературы.

Одна из самых спорных публикаций Г. Ибрагимова – изданная отдельной книгой в Москве на русском и татарским языках «Кара маяклар, яки Ак әдәбиятлар» («Черные вехи, или Белоэмигрантская литература», 1924), в которой речь идет о книгах, изданных за рубежом, точнее о труде Мусы Бигиева «Исламият әлифбасы» («Азбука ислама»), публикациях Г. Исхаки в журнале «Азат Шәрык» («Свободный Восток»), статьях Расулзадэ Амина «Азәрбәйҗан җөмһүрияте» («Республика Азербайджан») и Г.К. Хатафа «Күк байрагы астында милли фәгалият» («Национальная деятельность по флагом неба») о Крымской республике. Г. Ибрагимов крайне отрицательно оценивает эти публикации, объясняет марксистскую позицию по вопросам, поднятым в них, а сам факт

Иң бәхәсле язмалардан, шулай ук Мәскәүдә һәм татарча, һәм русча аерым китап булып басылган «Кара маяклар, яки Ак әдәбиятлар»да (1924) сүз чит илләрдә дөнья күргән китаплар, төгәлрәк әйткәндә, Муса Бигиевнең «Исламият әлифбасы», «Азат Шәрык» журналындагы Г. Исхакый язмалары, Рәсүлзадә Әминнең «Азәрбайҗан җөмһүрияте», Г.К. Һатәфнең Кырым җөмһүрияте хакындагы «Күк байрагы астында милли фәгалият» турында бара. Г. Ибраһимов әлеге хезмәтләрнең авторларын тискәре бәяли, шул китапларда кузгатылган аерым мәсьәләләргә карата марксизм карашын аңлатып уза, чит илләрдә төрки-татарларга атап язылган мондый хезмәтләр бастыруны фашизм хәрәкәте дип тамгалый. Монда миллилек, милли мәнфәгатьләрне яклау күренешләренең Г. Ибраһимов тарафыннан «хезмәт халкы интересларына, советлар хакимиятенә каршы юнәлдерелгән буржуаз милләтчелек» дип бәяләнүе ачык күренә [Абдуллин Я. Г. Ибраһимов: фикери һәм иҗади эволюциясе. 142 б.].



Галимҗан Ибраһимов.
ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 2. С. б. 14

Галимджан Ибрагимов.
ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 2. Ед. хр. 14





«Татарстан хәбәрләре» газетасы

Газета «Известия Татарстана»

обнародования адресованных тюрко-татарам трудов за рубежом обозначает как фашистскую деятельность! Такого рода попытки защитить национальные интересы Г. Ибрагимов оценивает как буржуазный национализм, направленный против интересов трудового народа и советской власти [Абдуллин Я. Милләт язмышы: уйланулар. Б. 142].

В 1920 году Г. Ибрагимов возобновил практику годовых обзоров, отчетов о состоянии татарской литературы и печати. Хоть литературной процесс и оценивается с позиции создания пролетарской литературы, в этих материалах много интересных наблюдений о тенденциях развития татарской литературы. Например, в статье «Дүртенче елга кергәндә» («Встречая четвертый год»), опубликованной 7 ноября 1920 года (№ 106) в газете «Эшче», определяются отдельные мотивы революционного творчества М. Гафури, Ф. Бурнаша, Ш. Бабича. В предисловии к поэме М. Гафури «Эшче» («Рабочий»), изданной в Казани отдельной книгой, Г. Ибрагимов уже развивает свое мнение о творчестве

1920 елда Г. Ибраһимов әдәбият, матбугат торышы хакында еллык күзәтү, хисап ясау эшен яңартып җибәрә. Әдәби барыш яңа пролетариат әдәбиятын тудыру ягыннан бәяләнсә дә, мондый материалларда татар әдәбиятында хасил булган тенденцияләр хакында кызыклы фикерләр урын алган. «Эшче» газетасының 1920 елгы 7 ноябрь (106) санында басылып чыккан «Дүртенче елга кергәндә» мәкаләсендә, мәсәлән, М. Гафури, Ф, Борнаш, Ш. Бабичларның революцион иҗатларындагы аерым мотивлар билгеләнә. 1921 елны М. Гафуриның Казанда аерым китап булып басылып чыккан «Эшче» поэмасына сүз башы итеп язылган «Берничә сүз» язмасында инде, М. Гафури иҗаты хакындагы фикерләр үстерелеп, бу иҗатның татар әдәбияты тарихындагы урынын билгеләү омтылышы ясала. 1921 һәм 1922 елда әдип «Яңа әсәрләр» исеме астында бер-бер-сен дәвам итүче язмалар белән чыгыш ясый. «Татарстан хәбәрләре»нең 1922 елгы 7 февраль (31) санында басылган «Татар әдәбияты (Хисап урынында)», 7 март (56) санындагы



«Эшче» газетасы

Газета «Эшче»





Мирхәйдәр Фәйзи (1891–1928)

Мирхайдар Файзи (1891–1928)

автора, пытается определить его место в истории татарской литературы. В 1921 и 1922 годах писатель опубликовал друг за другом две статьи под названием «Яңа әсәрләр» («Новые произведения»). Статьи «Татар әдәбияты (Хисап урынында)» («Татарская литература (Вместо отчета»), опубликованная 7 февраля 1922 года в газете «Татарстан хәбәрләре» (№ 31), «Татар әдәбиятында өченче дәвер. Аңларга тырышыгыз!» («Третья эпоха татаркой литературы. Постарайтесь понять!»), опубликованная в той же газете 7 марта (№ 56), «Татарның соңгы тарихындагы өч дәвер (эпоха). («Аңлау» юллары)» («Три эпохи новой истории татар. (Пути «познания)»), увидевшая свет там же 20 марта (№ 66), имеют теоретический характер, утверждают, что дореволюционная печать выполнила свою задачу и теперь должна дать дорогу пролетарской литературе.

В статьях, посвященных отдельным произведениям, точно подмечены их основные признаки, новизна, которую они приносят литературному процессу. К примеру, в

«Татар әдәбиятында өченче дәвер. Аңларга тырышыгыз!», 20 март (66) санындагы «Татарның соңгы тарихындагы өч дәвер (эпоха) («Аңлау» юллары)» мәкаләләре исә, теоретик характерда, инкыйлабка кадәрге әдәбиятның, үз бурычын үтәп, яңа пролетариат әдәбиятына юл ачарга тиешлеген яклап язылганнар.

Аерым әсәрләргә багышланган мәкаләләрдә аларның төп сыйфатлары, әдәби барышка алып килгән яңалыгы төгәл тотып алына. Мәсәлән, М. Фәйзинең «Галиябану» драмасына сүз башы итеп 1922 елда язылган «Галиябану» хакында бер-ике сүз» язмасында әсәрнең һәм драматург иҗатының төп хасияте, яңалыгы билгеләнгән: «Беренче мәртәбә диярлек һичбер буяусыз, саф булганча, үзләренең уен-көлкеләре, җырлары, музыкалары, гыйшыклары, интригалары, бәетләре, көрәшләре белән крәстиян егетләре, крәстиян кызлары бу әсәр аркылы безнең театр галәменә килеп керәләр» [Ибраһимов Г. «Галиябану»хакында бер-ике сүз // Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. Т. 5: Әдәбият



Фәтхи Борнаш (1898–1942)

Фатхи Бурнаш (1898–1942)





Г. Ибраһимов Гыйбадулла Алпаров белән. 1933.
ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 5. С. б. 6

Г. Ибрагимов с Гибадуллой Алпаровым. 1933.
ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 5. Ед. хр. 6

предисловии к драме М. Файзи «Галиябану», написанной в 1922 году, определены главные особенности произведения и в целом творчества автора, указаны новые явления, привнесенные в татарскую драматургию этой пьесой: «Практически впервые крестьянские юноши и девушки вошли в театральный мир вместе со своими играми, песнями, музыкой, влюбленностями, интригами, баитами, борьбой, такими как есть, без дополнительных красок» [22, б. 302]. Там же отмечено, что музыка, песни в этом произведении использованы не только как дополнительный декоративный элемент, а играют полноправную роль в передаче содержания, органично вплетаясь в ткань произведения.

В статье «Өч җавап» («Три ответа»), написанной в духе теоретического спора с Ф. Бурнашем и опубликованной 28 апреля 1922 года в газете «Татарстан хәбәрләре» (№ 96), Г. Ибрагимов снова затронул вопрос о своих взглядах на литературу. Обращая внимание на изменения в творчестве Галимджана Ибрагимова после революции, Фатхи Бурнаш

һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933). Б. 302]. Шунда ук әсәрнең музыканы, җырны, бизәк өчен генә түгел, төп эчтәлекне белдерүче рольдә әсәр тукымасына табигый урнаштыруы күрсәтелә.

Ф. Борнаш белән нәзари бәхәс рухында язылган «Өч җавап»та («Татарстан хәбәрләре» газетасының 1922 елгы 28 апрель (96) санында басыла) Г. Ибраһимов үзенең әдәбиятка карашы мәсьәләсенә кагыла. Инкыйлабтан соң әдип язмаларындагы үзгәрешләргә игътибар итеп, Борнаш аны («Татарстан хәбәрләре» газетасының 1922 елгы 17 апрель (87) санындагы «Тукай шигырьләрендә иҗтимагый моңнар» мәкаләсе) «Татар шагыйрьләре»ндә Тукай иҗатына «саф сәнгать»күзлегеннән якын килүдә гаепләгән була. Г. Ибраһимов әдәбиятның тормышчан җирлектә яки җирдән аерылып языла алуы турында инкыйлабка кадәрге теорияләрдән баш тартмавын белдерә, әмма нинди юл белән барса да, әсәр вәгазь сөйләүдән азат булырга тиешлеген ассызыклый. Бу теорияләр һәм пролетариат әдәбиятына караган фикерләре арасындагы каршылыкны түбәндәгечә килештерә: «Ләкин әдипләр, шагыйрьләр күктә яшәми, талантлар күктән рухланмый – болар мәгълүм дәвернең, мәгълүм иҗтимагый-икътисади зәминнәрнең җимешләре булганга, шуңа карап, аларның безгә ача торган дөньялары, тормышлары, җанлы картиналары төрлечә була. Тормышның үзендәге төрле күренешләр безгә төрле фикер, төрле тәрбия биргән кебек, шагыйрьнең, әдипнең «битараф» җанлы тасвирлары, җанлы күренешләре дә укучының рухында үзенең мөндәриҗәсе, әдәбипәрдә астына яшерелгән мәгънәсе буенча төрле эз калдыра. Менә шул ноктадан инде шагыйрьнең, әдипнең кемгә, нинди әмәлгә, кайсы сыйныфка хезмәте мәсьәләсе килеп чыга» [Ибраһимов Г. Өч җавап // Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. Т. 5: Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933). 311–312 б.].

Татар иҗтимагый һәм иҗади фикеренең үсешен Г. Ибраһимов өч этапка бүлеп карый. Илдә инкыйлаби



обвинил его в одностороннем взгляде на творчество Тукая, которое было представлено в статье Г. Ибрагимова «Татарские поэты». Бурнаш высказал свое мнение в статье «Тукай шигырьләрендә иҗтимагый моңнар» («Общественные мотивы стихотворений Тукая»), опубликованной 17 апреля 1922 года в газете «Татарстан хәбәрләре» (№ 87). Г. Ибрагимов, в свою очередь, заявил, что он совершенно не отрицает своей дореволюционной теории относительно литературы: литература должна создаваться на основе реальной жизни или же в отрыве от реальности. В то же время он говорит о том, что художественное произведение должно быть свободно от прямого проповедничества. Г. Ибрагимов соотносит это свое мнение и дореволюционные теории относительно татарской литературы следующим образом: «…писатели и поэты живут не на небесах, талант их одухотворяется не небесами; они продукт своего времени, определенных общественно-исторических условий, они плоды этой жизни. Поэтому миры, которые они рисуют, разные. Так же, как разные события жизни рождают в нас совершенно разные мысли, совершенно по-разному воздействуют на нас, описанные поэтами, писателями миры оставляют совершенно разный, но глубокий след в душе читателя. Здесь и встает вопрос о принадлежности поэта, писателя какому-нибудь определенному классу, определенной точки зрения» [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 5: әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933). Б. 311–312].

Ибрагимов разделяет развитие татарской общественной и творческой мысли на три этапа. Третий этап, определяемый усилением в стране революционного движения, связан, по его мнению, с творчеством Г. Тукая Ф. Амирхана, Г. Камала, М. Гафури и таких марксистов, как Х. Ямашев и Г. Сайфутдинов.

В 1925–1927 годах Ибрагимов был руководителем Научного центра, одновременно председателем бюро изучения Татарстанского края, членом президиумов ВЦИК и ЦИК ТАССР.

хәрәкәтләр активлашу белән билгеләнгән өченче этап – Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Камал, М. Гафурилар иҗаты, Х. Ямашев, Г. Сәйфетдинов кебек марксистлар эшчәнлеге белән бәйле, дип күрсәтелә.

1925–1927 елларда Г. Ибраһимов Гыйльми Үзәк җитәкчесе, бер үк вакытта Татарстан төбәкләрен өйрәнү бюросы рәисе, Бөтенроссия ҮБК һәм ТАССР ҮБК Президиумы әгъзасы.

1921 елның 3 декабрь карары белән ТАССР Мәгариф Халык комиссариаты каршында Гыйльми Үзәк булдыру турында карар кабул ителә, 1921–1924 елларда ул оешу баскычын уза. 1925 елның 7 гыйнварында җитәкче булып Г. Ибраһимов килгәннән соң, Үзәк «Татарстанда мәдәният һәм фәннең барлык юнәлешләрендә тикшеренүләр башлап җибәрә» [Валеева Г.А. Академический центр Татарии: 1920-е гг. // Академический центр Наркомпроса ТАССР: документы и материалы. Казань: ИЯЛИ, 2015. С. 10–11]. Әдип эшчәнлегенең бу ягы турында танылган шәрык



Гаяз Максудов
(1891–1942)
Гаяз Мксудов
(1891–1942)





Мөхәммәтхан Фазлуллин
(1883–1964)
Мухамметхан Фазлуллин
(1883–1964)

Решение о создании Научного центра было принято 3 декабря 1921 года Народным комиссариатом просвещения ТССР, в 1921–1924 годах он прошел этап становления. 7 января 1925 года, когда руководителем центра стал Галимжан Ибрагимов, центр начал активные исследования практически во всех областях культуры и науки в Татарстане [Академический центр Наркомпроса ТАССР: документы и материалы. Казань: ИЯЛИ, 2015. С. 10–11]. Судя по воспоминаниям Ильи Бороздина, Г. Ибрагимову пришлось взяться за множество разных дел одновременно, решать совершенно разные проблемы, но он все успевал, всегда был радостен, активен, даже страстен, вдохновлял на разные свершения все свое окружение. Г. Ибрагимов изумляет своей потрясающей работоспособностью в должности председателя Научного центра: множество учреждений было создано именно по его инициативе, при его непосредственном участии было осуществлено огромное количество изданий. Работа просто кипела. Диапазон литературных интересов его также был

белгече, тарихчы, археолог Илья Бороздин язып калдырган истәлектә мондый юллар бар: «Галимҗан Ибраһимовка бик күп төрле эшләр башкарырга, төрле мәшәкатьләр чигәргә туры килде; һәм ул барысына да өлгерә иде, һәрвакыт шат, актив, ихтыярлы, дәртле була иде һәм башкаларны да рухландыра да, дәртләндерә дә белә иде. (...) Гыйльми Үзәк рәисе буларак, Г. Ибраһимов үзенең гаҗәп тырышлыгы белән шаккатыра иде. Әллә никадәр учреждение аның инициативасы белән булдырылды, әллә никадәр басмалар аның катнашы белән чыгарылды. Эш кайнап тора иде. Г. Ибраһимов, сәламәтлеге бик үк шәптән булмаса да, анда турыдан-туры катнаша иде. Аның әдәби кызыксыну диапазоны да гаять киң иде. Ул менә дигән язучы да, тарихчы да, телче дә, әдәбиятчы да һәм һәр җирдә дә үзенең сүзен әйтә ала иде. (...) Г. Ибраһимов акыллы, игътибарлы һәм кызык әңгәмәче иде. Ул үз карашларында мөстәкыйль һәм, күрәсең, үзенең тоткан позициясен җиңел генә ташламый иде» [Галимҗан Ибраһимов: мәкаләләр, истәлек-хатирәләр. 252–253 б.].



Мөхетдин Корбангалиев (1873–1941)

Мухутдин Курбангалиев (1873–1941)





Г. Ибраһимовның «30 лет на поприще культурной деятельности (1895–1925)» исемле мәкаләсенең кульязмасы. ЯһММУ. Ф. 65. Тасв. 1. С. б. 29

Рукопись статьи Г. Ибрагимова «30 лет на поприще культурной деятельности (1895–1925)». ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 1. Ед. хр. 29

невероятно широк. Ибрагимов был прекрасным писателем, историком, языковедом, литературоведом; и в каждой из этих областей мог сказать свое веское слово. По свидетельству современников, Г. Ибрагимов также был очень умным, внимательным и интересным собеседником. Он самостоятельно мыслил и очень тяжело расставался с позицией, придерживаемой ранее [Галимҗан Ибраһимов: мәкаләләр, истәлек-хатирәләр. Б. 252–253].

Научный центр взял под свое крыло практически все вопросы науки и культурного строительства в республике: здесь разрабатывались учебные программы и планы, рассматривались методические вопросы, подготовка учителей и повышение квалификации педагогов, создание терминологии на татарском языке, словарей, репертуар татарских театров, развитие и популяризация татарской музыки, музеи и библиотеки, деятельность кружков, вопросы истории края, культуры народов ТАССР, природа края, общественно экономическое развитие, археология, этнография. Развитие

Гомумән алганда, Гыйльми Үзәк төбәктәге барлык мәдәни мәсьәләләрне үз канаты астына ала: уку-укыту планнары һәм программалары, методик мәсьәләләр, укытучылар әзерләү һәм аларның белемен күтәрү дә, татар телендә фәнни терминология булдыру, сүзлекләр төзү дә, татар театрларының репертуары, татар музыкасын үстерү һәм популярлаштыру, музейлар, китапханәләр, түгәрәкләр эшчәнлеге дә, төбәк тарихын, анда яшәгән төрле милләтләр мәдәниятен, төбәкнең табигатен, иҗтимагый, икътисади үсешен өйрәнү дә, археология, этнография, татарны өйрәнү кебек фәннәрне үстерү дә төп бурычлардан санала. Үзәк төрле юнәлешләрдә Җәмгыятьләр оештыра, алар аерым фәнни институтлар кебек эшли башлыйлар. Мәсәлән, 1925 елдан Татарны өйрәнү җәмгыяте республиканың аерым кантоннарына экспедицияләр (елга 10) оештыра башлый, үз журналын – «Татарны өйрәнү җәмгыятенең хәбәрләре» («Вестник научного общества татароведения», елга 4 сан) булдыра, китаплар бастыра,




«Вестник научного общества Татароведения» журналы

Журнал «Вестник научного общества Татароведения»





Г. Ибраһимов язучылар, журналистлар, галимнәр арасында. 1925–1926. ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 5. С. б. 48

Г. Ибрагимов среди писателей, журналистов, ученых. 1925–1926. ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 5. Ед. хр. 48

по всем этим вопросам было провозглашена основной задачей Научного центра. Центр образовал разные общества: например, в 1925 году возникло Общество татароведения, которое выезжало на экспедиции в разные районы республики (примерно 10 экспедиций в год), организовало свой собственный журнал «Вестник научного общества татароведения» с периодичностью 4 номера в год, издавало книги, проводило конференции, другие мероприятия, организовывало экскурсии, открытые лекции и др. О деятельности и планах работы Научного центра можно узнать по докладу Г. Ибрагимова от 13 марта 1925 года, а также по отчетам о деятельности центра за 1926–1927 год [Академический центр Наркомпроса ТАССР: документы и материалы. С. 96–108]. Действительно, Научный центр стал той организацией, которая консолидировала все силы республики в области науки, образования, культуры и искусства, идеологии; проводила невероятно большую работу в этом направлении. Опираясь на потенциал Научного центра, Г. Ибрагимов

конференцияләр, төрле чаралар уздыра, экскурсияләр оештыра, халык өчен ачык лекцияләр укыла һ.б. Гыйльми үзәкнең эшчәнлеге һәм планнары хакында Г. Ибраһимовның 1925 елның 13 мартында ясаган докладына, 1926–1927 елларда башкарылган эшләр турындагы хисапка караганда [Академический центр Наркомпроса ТАССР: документы и материалы. С. 77–80; 96–108], ул, чыннан да, республикада фән, мәгариф, мәдәният, сәнгать, идеология ягыннан алдынгы көчләрне берләштергән һәм гаять зур эш алып бара торган бердәм оешмага әверелә. Г. Ибраһимов шушы зур потенциалга таянып, үзе инкыйлабка кадәр үк татар җәмгыятен, милли фикерләүне, күзаллауны үстерү һәм камилләштерү өчен әһәмиятле дип тапкан төрле юнәлешләрдә җиң сызганып эшкә керешә.

Шуларның берсе – татар әдәбияты тарихын туплау. Г. Ибраһимов татар әдәбияты тарихы фәнен тудыручыларның берсе исәпләнә. Әдәбиятның башка тармаклары (әйтик, әдәби тәнкыйть һәм әдәбият теориясе) белән



Гали Рәхим
(1892–1943)

Гали Рахим
(1892–1943)





Газиз Гобәйдуллин
(1887–1937)

Газиз Губайдуллин
(1887–1937)

засучив рукава начал работать во всех направлениях, которые еще до революции считал крайне важными для развития татарского общества: рост национального самосознания, расширение мировоззрения народа.

Одно из направлений, которое Г. Ибрагимов активно разрабатывал, – это история татарской литературы. Ибрагимов справедливо считается одним из основоположников научной истории татарской литературы. По сравнению с другими направлениями литературы – литературной критикой и теорией литературы – история татарской литературы как самостоятельное направление науки возникла гораздо позже, только в 1920–1930-х годах. Отдельно можно отметить заслугу Г. Ибрагимова, Дж. Валиди, Г. Рахима, Г. Газиза [Гыйләҗева Ч.М. Әдәбият фәне һәм Габдрахман Сәгъди. Б. 45]. Труд Г. Ибрагимова «Вопросы литературы» был одним из первых в этой области. В многочисленных объемных критических статьях он также анализировал отдельные произведения, творчество отдельных писателей, пытался дать

чагыштырганда, мөстәкыйль фән буларак әдәбият тарихы соңарып, 1920–1930 елларда гына мәйданга чыга. Бу эштә Г. Ибраһимов, Җ. Вәлиди, Г. Рәхим, Г. Газиз, Г. Сәгъди хезмәтләре зур роль уйный [Гыйләҗева Ч.М. Әдәбият фәне һәм Габдрахман Сәгъди. Казан: РИЦ, 2012. 45 б.]. Г. Ибраһимовның «Әдәбият мәсьәләләре» бу өлкәдә беренче тәҗрибәләреннән була. Күпсанлы күләмле тәнкыйть мәкаләләрендә дә Г. Ибраһимов аерым әсәрләрне, язучы иҗатын гомуми әдәби барыш фонында тикшерергә, бәяләргә омтыла. Әйтик, аның 1915 елда «Тормыш»ның 27 ноябрь (365) санында басылган «Әзерләнә башларга вакыт җитмәдеме?» хезмәте татар әдәбиятын дөнья әдәбияты контекстында өйрәнү мәсьәләсен куя.

Әмма татар әдәбияты тарихын булдыруга әзерлек инкыйлабтан соң гына нәтиҗә бирә. 1922–1927 еллар арасында Гыйльми үзәкнең әгъзалары да булган Г. Рәхим һәм Г. Гобәйдуллиннар «Татар әдәбияты тарихы» томнарын, 1923 елда Җ. Вәлиди «Очерк истории образованности



Галимҗан Шәрәф
(1896–1950)
Галимджан Шараф
(1896–1950)





Гомәр Толымбайский
(1900–1938)
Гумер Тулумбайский
(1900–1938)

им оценку на фоне общего развития татарской литературы. Скажем, его статья «Хәзерләнә башларга вакыт җитмәдеме?» («Не время ли подготовиться?»), опубликованная 27 ноября 1915 года в газете «Тормыш», ставит вопрос изучения татарской литературы в контексте общемировой.

Готовность к созданию научной истории татарской литературы была реализована только после революции. В 1922–1927 годах члены Научного центра Гали Рахим и Газиз Губайдулин составили тома «Истории татарской литературы»; в 1923 году Джамал Валиди опубликовал свой «Очерк истории образованности и литературы татар». Стал актуальным вопрос написания последовательной истории татарской литературы.

В 1923 году, когда был опубликован второй том «Истории татарской литературы» Г. Рахима и Г. Губайдуллина, 6 февраля 1923 года в газете «Татарстан» (№ 28) Г. Ибрагимов выступил с объемной статьей «Татар әдәбияты тарихына материаллар» («Материалы к истории татарской

и литературы татар» хезмәтен бастыра. Татар әдәбияты тарихын өзлексез итеп язу концепциясен эшләү көн тәртибенә менә.

1923 елда, Г. Рәхим һәм Г. Гобәйдуллиннар хезмәтенең 2 томы дөнья күргәч, Г. Ибраһимов «Татарстан»ның 6 февраль (28) санында «Татар әдәбияты тарихына материаллар» дигән күләмле язма белән чыга. Әлеге хезмәтләрдә, татар әдәбиятын өйрәнү фәнендә беренчеләрдән булып, авторлар төрки-татар әдәбияты тарихын Орхон-Енисей язмаларыннан башлыйлар, Алтын Урда, Болгар, Казан ханлыгы дәверләрен аералар. Г. Ибраһимов: «Бу, шөбһәсез, тарихи яктан да дөрест һәм, астында реаль тормыш булганга, бунын гыйльми нигезе дә бардыр» дип, аларның әдәбият тарихын ерактан башлавын хуплый [Ибраһимов Г. Татар әдәбияты тарихына материаллар // Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. Т. 5: Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933). 311–367 б.]. Бу фикер алга таба татар әдәбияты тарихының хронологиясен эшләүдә хәлиткеч


-ТАТАРСТАН-
تاتارستان

«Татарстан» газетасы
Газета «Татарстан»





«Татарстан» газетасы
Газета «Татарстан»

литературы»). Отмечая, что в этих трудах впервые в истории татарской литературы авторы начинают рассматривать истоки татарской литературы с орхоно-енисейской письменности, разделяя этапы Золотой Орды, булгарский период, Казанского ханства, Г. Ибрагимов положительно оценивает такой подход: «Это, несомненно, исторически верно, к тому же имеет в основе реальную жизнь, то есть научно обоснованно» [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 5: әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933). Б. 311–367]. Это мнение стало решающим при создании хронологии истории татарской литературы в дальнейшем, а одобрение Ибрагимова звучало как официальное признание данной концепции.

Г. Ибрагимов в этой статье дает также обзор изучения истории татарской литературы XIX – начала XX века, вместе с этим подчеркивает необходимость написания истории современной татарской литературы, используя при этом марксистский метод.

роль уйный, Ибраһимовның хуплавы исә әлеге концепциягә рәсми юл ачу булып яңгырый.

Мәкаләдә әдип XIX–XX йөз башында татар әдәбияты тарихын өйрәнү тәҗрибәләренә күзәтү ясап уза. Шуның белән бергә, әлеге язмада Г. Ибраһимов яңа заман әдәбияты тарихын марксизм ысулы кулланып язу кирәклеген мәсьәлә итеп куя.

«Кызыл байрак» газетасының 1923 ел 4 апрель (11) санына Җ. Вәлидинең «Очерк истории образованности и литературы татар» хезмәте чыгу уңае белән Г. Ибраһимов «Татар әдәбияты хакында тагын бер әсәр» дигән рецензия яза. Китап әдипне канәгатьләндерми: ул аның әдәбият тарихының төрле дәверләренә тигез карамавын, мәгърифәтчелек әдәбиятына игътибар җитмәүне, аерым авторларның (Г. Камал, Г. Чыгтай һ.б.) телгә алынмавын, әдәбиятта революция хәрәкәтләренең йогынтысы дөрес яктыртылмауны аерып тәнкыйтьли. Әдәбият тарихын булдыру мәсьәләсенә шул ук елны язылган «Татар әдәбиятын өйрәнү юлында» хезмәтендә дә кагылып узыла.




«Кызыл байрак» газетасы
Газета «Красное знамя»






«Безнең юл» журналы
Журнал «Наш путь»

По случаю публикации книги Дж. Валиди «Очерк истории образованности и литературы татар» в газете «Красное знамя» 4 апреля 1923 года (№ 11) Г. Ибрагимов написал рецензию «Татар әдәбияты хакында тагын бер әсәр» («Еще один труд о татарской литературе»). Писатель был недоволен этой книгой: он отмечает, что в ней разные эпохи истории татарской литературы рассмотрены не равнозначно, просветительская литература явно испытывает недостаток внимания, а отдельные авторы, например Г. Камал, Г. Чыгтай, и др., не упомянуты вовсе. Отдельно критикует ошибочное освещение влияния революционного движения на татарскую литературу. О создании истории татарской литературы Г. Ибрагимов говорит также в своем труде «Татар әдәбиятын өйрәнү юлында» («На пути изучения татарской литературы»), написанном в том же году.

В этих условиях осенью 1925 года Г. Ибрагимов вызвал в Казань Г. Сагди с целью специального исследования вопросов истории татарской литературы. За 5 лет работы, причем

Шушы шартларда, 1925 елның көзендә Г. Ибраһимов Г. Сәгъдине татар әдәбияты тарихы мәсьәләләре белән шөгыльләнү өчен Казанга махсус чакырта. 5 ел эчендә, югары уку йортларында тыгыз график белән эшләве өстенә, Г. Сәгъди утызлап гыйльми хезмәт яза. Алар арасында иң зурлары – «Татар әдәбияты тарихы» (1926), «Кешелек дөньясында тел, әдәбият, язу һәм аларның тарихи үсүләре» (1926), «Татар театр әдәбияты һәм аның үсү тарихы» (1926), «Галимҗан Ибраһимов һәм аның әдәби иҗатлары» (1928), «Пролетариат диктатурасы дәверендә татар әдәбияты» (1930), «Символизм турында» (1929 елда язылып төгәлләнә) [Гыйләҗева Ч.М. Әдәбият фәне һәм Габдрахман Сәгъди. Б. 24–26]. Г. Сәгъдинең эшчәнлегенә кагылышлы материалларда Г. Ибраһимовның әдәбият тарихын язу мәсьәләсендә галим белән турыдан-туры эшләве күренә. Бу яктан, әдипнең хатыны Г. Мөхәммәдова истәлекләре дә кызыклы факт була ала: «Г. Сәгъди кайбер чакларда төнге сәгать 2–3ләрдә дә телефон аркылымы яисә үзе килепме (бездән ерак тормый), яза торган китабының яңа бүлекләрен укый һәм сәгатьләр буе аерым тәгъбирләре, сыйфатландырулары турында Галимҗан белән фикер алыша. Ул вакытта Г. Сәгъди татар әдәбияты тарихын яза иде» [Гөлсем Мөхәммәдова. Зур тормыш // Галимҗан Ибраһимов: мәкаләләр, истәлек-хатирәләр. Б. 367]. Шул рәвешле, үзенең каләме белән дә, тәнкыйте һәм эш-гамәлләре белән дә, турыдан-туры тикшереп һәм бәхәсләшеп тә Г. Ибраһимов татар әдәбияты тарихын формалаштыруга хезмәт итә.

Әдәбият тарихы концепциясе бер канаты белән мирас мәсьәләсенә килеп кагыла. 1922–1923 елларда Г. Ибраһимов белән Җ. Вәлиди арасындагы бәхәс шул яссылыкта туа. Җ. Вәлиди үткән мәдәниятне, аның идеологик асылына карамыйча, өйрәнергә һәм белергә кирәк дигән фикер уздыра, Г. Ибраһимовның мираска сыйнфый якын килү таләбе алар арасында методологик дискуссиягә сәбәп була. Әйтик, Г. Ибраһимов «Татарстан хәбәрләре»нең 1922 елгы 7 март (56) санында басылган «Татар әдәбиятында өченче



совмещая с преподавательской деятельностью с плотным графиком в высших учебных заведениях, Сагди написал около 30 научных трудов. Самые значительные из них: «Татар әдәбияты тарихы» («История татарской литературы», 1926), «Кешелек дөньясында тел, әдәбият, язу һәм аларның тарихи үсүләре» («Язык, литература и письменность в истории человечества и их историческое развитие», 1926), «Татар театр әдәбияты һәм аның үсү тарихы» («Татарская театральная литература и ее история», 1926), «Галимҗан Ибраһимов һәм аның әдәби иҗатлары» («Галимжан Ибрагимов и его литературное творчество», 1928), «Пролетариат диктатурасы дәверендә татар әдәбияты» («Татарская литература в эпоху Диктатуры пролетариата», 1930), «Символизм турында» («О символизме», завершено в 1929 году) [Гыйләҗева Ч.М. Әдәбият фәне һәм Габдрахман Сәгъди. Б. 24–26]. В материалах Г. Сагди чувствуется влияние Г. Ибрагимова в вопросах истории татарской литературы. Интересны воспоминания Гульсум Мухаммедовой, жены писателя: «Габдрахман Сагди иногда даже в 2–3 ночи обращался через телефон или лично приходил к нам (жил недалеко от нас), зачитывал отдельные главы книги, которую писал, советовался с Галимджаном часами. В это время он писал историю татарской литературы» [Галимҗан Ибраһимов: мәкаләләр, истәлек-хатирәләр. Б. 367]. Таким образом, и своим творчеством, и критикой, и прямой деятельностью через публикации Г. Ибрагимов оказал огромное влияние на формирование научной истории татарской литературы.

Концепция истории литературы затрагивает вопрос культурного наследия. Спор между Г. Ибрагимовым и Дж. Валиди в 1922–1923 годах возник именно на этой почве. Валиди проводил мнение, что прошлое культуры необходимо изучать и знать, несмотря на идеологические основы. Ибрагимов же защищал мнение о том, что и к культурному наследию необходим классовый подход. Это стало причиной их методологической дискуссии. Например, в статье Г. Ибрагимова «Татар әдәбиятында өченче дәвер

дәвер (Аңларга тырышыгыз!)» мәкаләсендә инкыйлаби әдәбиятның кыйммәтен элеккеге мирастан югарырак куя. Җ. Вәлиди «Татарстан хәбәрләре»нең 1922 елгы 10 март (59) санында басылган «Аңларга тырыштык, аңлый алмадык (Галимҗан иптәш Ибраһимовка җавап)» мәкаләсендә, чын сәнгать әсәрләре дөньяга караш үзгәрү белән әһәмиятен югалтмый, «бу әсәрләрнең революционныймы, түгелме икәнлеген тикшермичә, фәкать сәнгать таләпләрен үтәгәнме, юкмы икәнлеген күздә» тоту хакыйкать дип ассызыклый [Вәлиди Җ. Аңларга тырыштык, аңлый алмадык (Галимҗан иптәш Ибраһимовка җавап) // Җамал Вәлиди: әдәби-тарихи һәм тарихи-документаль җыентык. Б. 416].

Гомумән, бу мәсьәләдә Г. Ибраһимовның эш-гамәлләре бүген дә шактый каршылыклы тәэсир калдыра. Бер яктан, әдип Г. Камал, Ф. Әмирхан кебек матди яктан авыр хәлгә тарыган каләм ияләренә игътибар күрсәтә: «Ярдәм мәҗмугасы» исеме астында 1921–1922 елларда басылып чыккан әдәби әсәрләр җыентыкларыннан килгән акча


یاردەم

«Әдәби ярдәм мәҗмугасы»ның беренче китабы. 1922

Первая книга «Әдәби ярдәм мәҗмугасы» («Сборника литературной помощи»). 1922




یاردەم یولندا.

Г. Ибраһимовның «Әдәби ярдәм мәҗмугасы»на язылган кереш сүзе. 1922 ел

Предисловие Г. Ибрагимова к «Сборнику литературной помощи». 1922

(Аңларга тырышыгыз!)» («Третий период в развитии татарской литературы (Постарайтесь понять!)»), опубликованной в газете «Известия Татарстана» 7 марта 1922 года (№ 56), ценность классовой литературы поставлена гораздо выше ценности литературного наследия. Джамал Валиди статьей «Аңларга тырыштык, аңлый алмадык (Галимҗан иптәш Ибраһимовка җавап)» («Попытались понять, да не смогли (ответ товарищу Галимджану Ибрагимову)»), опубликованной 10 марта 1922 года в газете «Известия Татарстана» (№ 59), утверждал, что истинное произведение искусства не теряет своей ценности при изменении исторической обстановки. Подчеркивает мысль о том, что необходимо обращать внимание в первую очередь на то, что соответствует ли произведение требованиям высокого искусства или нет, не обращая внимания на революционность или нереволюционность произведения [Җамал Вәлиди: әдәби-тарихи һәм тарихи-документаль җыентык. Казан: Җыен, 2010, Б. 416].

мохтаҗларга бирелә. Өлкән әдипләргә ярдәм сорап мәкаләләр яза һ.б.

Икенче яктан, эмиграциягә киткән талантлы каләмдәшләрен, көрәштәшләрен татар мәдәнияте тарихыннан сызып ташлау, аларны каралтып күрсәтү адымнары да Г. Ибраһимов тарафыннан ясала. Үзе хөрмәт иткән, дус булган шәхесләр эштән куылганда, кулга алынганда, гаепләнгәндә дә Г. Ибраһимов дәшми, алар авыр хәлләргә тарыганда ярдәм итми. Бу хакта Г. Батталның «Миражга алданган язучы» истәлегеннән дә укырга була [Баттал Г. Миражга алданган язучы // Галимҗан Ибраһимов: мәкаләләр, истәлек-хатирәләр. Б. 446–456]. Яки тагын бер мисал – Г. Ибраһимовның Р. Фәхретдин белән очрашуы хакында язган хисабы һәм аның милли руханиларга карата мөнәсәбәтне йомшартырга ярамау турындагы нәтиҗә өлеше шулай ук Фәхретдиннең хезмәтләрен, карашларын яхшы белгән татар әдибе образы белән ярашмый. Әлбәттә, моны шәхес культы заманнарының авыр атмосферасы белән аңлатырга



«Әдәби ярдәм мәҗмугасы»ның икенче китабы. 1922 ел

Вторая книга «Әдәби ярдәм мәҗмугасы» («Сборника литературной помощи»). 1922





1925–1927 елларда Г. Ибраһимов яшәгән йорт. Казан. ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 5. С. б. 64

Дом, в котором в 1925–1927 годах жил Г. Ибрагимов. Казань. ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 5. Ед. хр. 64

Мнение Г. Ибрагимова в отношении культурного наследия и сегодня оставляет противоречивые чувства. С одной стороны писатель всячески помогал Г. Камалу, Ф. Амирхану, представителям «старой» литературы, которые после революции оказались в тяжелом материальном положении, организовал в 1921–1922 годах издание сборника литературных произведений под названием «Ярдәм мәҗмугасы» («Сборник помощи»), деньги от продажи которого были переданы в пользу нуждающихся писателей; просил правительство о помощи пожилым писателем и др. С другой стороны, талантливых писателей, уехавших в эмиграцию, Г. Ибрагимов практически вычеркнул из истории татарской культуры. Даже когда были арестованы люди, которых он уважал и с которыми был в дружеских отношениях, Ибрагимов молчал, так ничего и не сказав в их защиту. Об этом можно прочитать статье Г. Баттала «Миражга алданган язучы» («Писатель, обманутый миражом») [Галимҗан Ибраһимов: мәкаләләр, истәлек-хатирәләр. Б. 446–456]. Или

мөмкин. Әмма бу эшләр күз алдында XX йөз башындагы кырыс, турысын әйтергә күнеккән Г. Ибраһимов образыннан бөтенләй үзгә холыклы кеше сурәте тудыра.

Г. Ибраһимовның инкыйлабтан соңгы эшчәнлеге турында сөйләгәндә, тагын бер мәсьәләгә – латин графикасына күчү мәсьәләсендә аның позициясенә тукталырга кирәк. Әдип озак вакытлар гарәп графикасында калуны яклады, моны нәкъ менә инкыйлабка кадәрге олы мирасны югалту куркынычы белән дәлилләде.

Бу мәсьәлә 1926 елның 26 февраленнән 5 мартына кадәр Бакуда Беренче Тюркология съезды уздырылу уңае белән аеруча кискен төс ала. «Безнең юл» журналының 1926 елгы 1–2 санында, шушы зур вакыйганы каршылап, Г. Ибраһимов «Беренче Тюркология съезды» дигән мәкалә бастыра. Анда съезддан төрки халыкларның үз тарихын, мәдәниятен өйрәнүдәге тәҗрибәләрне берләштерүне, «Үзәк тюркология институты» кебегрәк бер үзәк булдыруны, төрки халыкларның «алдында торган мәдәни-әдәби,



«“Урал” һәм уралчылар» китабы. 1927.
ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 1. С. б. 32

Книга «“Урал” һәм уралчылар» («Урал и уральцы»). 1927.
ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 5. Ед. хр. 32





Г. Ибраһимов Һади Такташ белән.
ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 5. С. б. 49

Г. Ибрагимов и Хади Такташ.
ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 5. Ед. хр. 49

еще один пример, отчет Г. Ибрагимова о встрече с Ризой Фахрутдиновым и его вывод о том, что смягчить отношение к национальному духовенству нельзя ни в коем случае. Это никак не соотносится с образом писателя, который очень хорошо знал труды Фахрутдинова. Конечно, это можно объяснить влиянием времени. Но мы знали Г. Ибрагимова в начале XX века, резким, да, но честным и справедливым, который всегда прямо говорил свое слово. Здесь же совершенно другой человек...

Когда разговор касается деятельности Г. Ибрагимова после революции, необходимо остановиться еще на одном вопросе: перехода на латинскую графику. Писатель долгое время выступал за сохранение арабской графики, обосновывая это тем, что необходимо беречь и транслировать дореволюционное наследие.

Вопрос перехода на латиницу обсуждался на Первом тюркологическом съезде, проходившем в Баку 26 февраля – 5 марта 1926 года. Встречая это событие, Ибрагимов

гыйльми хәрәкәтенә юллар сызу»ны өмет иткәнлеген яза [Ибраһимов Г. Беренче Тюркология съезды // Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. Т. 8: Төрки һәм татар теле белеме буенча хезмәтләр (1910–1930). Б. 270].

Съездда Г. Ибраһимов Татарстан делегациясен җитәкли. Анда, төрки халыкларның тарихын, телен, мәдәниятен өйрәнү, уртак терминология, төрки телләрне һәм әдәбиятларны укыту кебек күпсанлы мәсьәләләр белән берәттән, татарлар һәм башка төрки халыклар өчен хәлиткеч – алфавит мәсьәләсе көн тәртибенә куела. Съездны оештыручылар төрки халыкларга латин алфавитына күчүне тәкъдим итәләр. Татарстан делегациясе вәкиле Галимҗан Шәрәф гарәп хәрефләрен сакларга чакыра. Аның чыгышын Казан делегациясе алкышлап каршы ала, тавыш биргәндә дә казанлылар шушы позициядә кала (дөрес, хөкүмәтнең рәсми позициясен белгән Ибраһимов, коммунист булуын әйтеп, тавыш биргәндә бер якка да катнашмый. Аның бу адымы да зур батырлык була).



Г. Ибраһимов каләмдәш дуслары белән. ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 5. С. б. 45
Г. Ибрагимов с друзьями-писателями. ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 5. Ед. хр. 45





Г. Ибраһимов Мәҗит Гафури белән. ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 5. С. б. 39
Г. Ибрагимов с Маджитом Гафури. ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 5. Ед. хр. 39

опубликовал в журнале «Наш путь» (1926, № 1, 2) большую статью под названием «Беренче Тюркология съезды» («Первый тюркологический съезд»). Здесь он отмечает, что съезд объединит опыт разных народов в изучении своей истории и культуры, выражает надежду на создание единого центра, например центрального института тюркологии, объединяющей и определяющей пути развития тюркских народов в решении культурных, литературных и научных проблем [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Сигез томда. Т. 8: Төрки һәм татар теле белеме буенча хезмәтләр (1910–1930). Б. 270].

На этом съезде Г. Ибрагимов был руководителем делегации Татарстана. Вместе с рассмотрением многочисленных вопросов истории, языка, культуры тюркских народов, их изучения, общей терминологии, преподавания тюркских языков и литературы, был поставлен и актуальной для татар и других тюркских народов вопрос – проблема алфавита. Организаторы съезда предлагали тюркским

Съездан кайтуга, «Безнең юл» журналының 1926 елгы 3 санында Г. Ибраһимов «Беренче Тюркология съезды нәрсә бирде?» дигән мәкалә белән чыга. Анда каралган мәсьәләләрне җентекләп күзәтеп узганнан соң, алфавит турында болай дип яза: «1) Татарстанның, татар халкының мәгълүм мәдәни, тарихи, икътисади хәлләре сәбәбеннән, бездә латинга күчәргә мөмкинлек юк. 2) Безнең гамәли юлыбыз – гарәп хәрефләрен реформа мәсьәләсенә бөтен 100 процент көчне, дикъкатьне юнәлдерү, хәзердән шуның чарасына керүдер» [Ибраһимов Г. Беренче Тюркология съезды нәрсә бирде? // Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. Т. 8: Төрки һәм татар теле белеме буенча хезмәтләр (1910–1930). Б. 275]. Охшаш фикерләр әдипнең «Кызыл Татарстан» газетасының 18 август (185) санында басылган «Тюркология өчен кыйммәтле материаллар» мәкаләсендә дә кабатлана. Бу язмаларда әдип яңалифкә күчүнең татарларны гарәп графикасында гасырлар дәвамында язылган мирастан мәхрүм калдыру ягына игътибар итә.





«Безнең юл» журналында басылган «Беренче Тюркология съезды» мәкаләсеннән фрагментлар

Фрагменты статьи «Первый тюркологический съезд», опубликованной в журнале «Наш путь»





«Кызыл Татарстан» газетасы

Газета «Красный Татарстан»

народам перейти на латинский алфавит. Представитель делегации Татарстана Галимджан Шараф выступил с призывом сохранить арабские буквы. Его выступление Казанская делегация встретила с аплодисментами, при голосовании казанцы также остались верны своей позиции, правда, Г. Ибрагимов, хорошо знавший официальную позицию правительства в этом вопросе, отмечая, что он коммунист, при голосовании воздержался. И этот его шаг был большим подвигом.

Сразу после приезда Г. Ибрагимов опубликовал статью «Беренче Тюркология съезды нәрсә бирде?» («Что же нам дал тюркологический съезд?») в № 3 журнала «Наш путь» за 1926 год. Детально рассмотрев все вопросы, обсуждавшиеся на съезде, об алфавите говорит так: «1. Учитывая, что мы хорошо знаем культурное, историческое, экономическое состояние Татарстана, татарского народа, нет никакой возможности перехода на латиницу. 2. Наш путь – 100 % своего внимания направить на реформу арабского алфавита,

1928 елның 24 гыйнваренда ВПК(б)ның Татарстан өлкә комитеты бюросы яңалифкә күчү чараларын көчәйтү мәсьәләсен күтәрә. Нәтиҗәдә Татарстан советларының 1929 елгы 8 маенда булган 8 съезды республикада яңалифкә күчү карарын кабул итә. 1929 елны язган Автобиографиясендә Г. Ибраһимов гарәп алфавитын яклауны «бик зур хатабыз булды» дип бәяли [Галимҗан Ибраһимов. Әсәрләр: тугыз томда. Т. 9: Хатлар һәм документлар. 47 б.]. Әмма аның алфавит мәсьәләсендә позициясе татар мәдәниятенә сакчыл һәм акыллы мөнәсәбәте турында сөйләп тора.

Бу елларда Г. Ибраһимов көнне төнгә ялгап эшли: галимнәр белән аралаша, төрле чараларда катнаша, чыгышлар ясый, бер сүз белән әйткәндә, мәдәни үсешне үзе күзаллаган юнәлештә алга җибәрү өчен бөтен көчен куя.

Әмма язмыш аның күп планнарына үзгәреш кертә. 1927 елның 17 мартында, Татарстан советларының 7 съездында чакта, Г. Ибраһимовның хәле начарлана: үпкәсенә



Г. Ибраһимовның медицина картасы. Кулъязма. ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 2. С. б. 62

Медицинская карта Г. Ибрагимова. Рукопись. ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 2. Ед. хр. 62





Г. Ибраһимовның медицина картасы. Кулъязма. ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 2. С. б. 62

Медицинская карта Г. Ибрагимова. Рукопись. ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 2. Ед. хр. 62

заняться этим немедля» [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 8: төрки һәм татар теле белеме буенча хезмәтләр (1910–1930). Б. 275]. Это же мнение повторяется в статье писателя «Тюркология өчен кыйммәтле материаллар» («Ценные материалы для тюркологии»), опубликованной в газете «Красный Татарстан» 18 августа (№ 180, 185). В этих публикациях писатель обращает внимание на то, что переход на латиницу, по сути, означает лишиться многовекового культурного наследия татарского народа.

24 января 1928 года бюро областного комитета ТАССР поднимает вопрос об ускорении перехода на латиницу. В результате 8-й съезд Советов Татарстана, который состоялся 8 мая 1929 года, принял решение о переходе на латиницу. В автобиографии, написанной в 1929 году, Г. Ибрагимов уже называет свою защиту арабского алфавита большой ошибкой [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 9: Хатлар һәм документлар. Б. 47]. Но позиция в вопросах алфавита показывает его бережное и мудрое отношение к татарской культуре.

кан савудан, аспирацион пневмония башлана, үлем куркынычы туа. Аны Казандагы Иске университет клиникасына салалар. Табиблар консилиумы, үпкә туберкулезы дигән диагноз белән, кичекмәстән җылы һавалы якларга китәргә киңәш бирә. Гыйльми үзәктәге вазифасын тапшырып, ул 21 апрельдә Кырымга кузгала. Биредә доктор А.В. Дьяконов карамагына беркетелә: бер еллап сырхауханәләрдә ята, аннары даими докторлар күзәтүе астында Ялтада яши. Татарстан да, Кырымдагы хакимият тә әдипнең сәламәтлеген яхшырту өчен уңайлы шартлар тудыра. Гаилә башта Халтурин урамы 5 йортка (1927–1937, сентябрь) урнаша. Г. Ибраһимовның Кырымда яшәгән еллары хакында партиянең Ялта районы комитетында беренче секретарь (1930–1932), Кырым өлкә комитетында бүлек мөдире (1932–1934) Шакир Даутовның истәлекләренә караганда [Галимҗан Ибраһимов: мәкаләләр, истәлек-хатирәләр. Б. 289–295], әдип диңгезгә якын урнашкан ике бүлмәле бакчалы фатирны бик ярата. 1936–1937 елларда



1927–1936 елларда Г. Ибраһимов яшәгән йорт. Ялта.
Дом, в котором в 1927–1936 годах проживал Г. Ибрагимов. Ялта.
Источник: Галимджан Ибрагимов: документы и факты; Галимджан Ибрагимов глазами молодых / [авт.-сост. М.Х. Ибрагимов]. Казань: Татар. кн. изд-во, 2012





1927–1936 елларда Г. Ибраһимов яшәгән йортның хәзерге күренеше. Ялта.
Современный вид дома, в котором в 1927–1936 годах проживал Г. Ибрагимов. Ялта.
Источник: Галимджан Ибрагимов: документы и факты; Галимджан Ибрагимов глазами молодых / [авт.-сост. М.Х. Ибрагимов]. Казань: Татар. кн. изд-во, 2012

В эти годы Г. Ибрагимов работает практически круглосуточно: общается с учеными, принимает участие в различных мероприятиях, выступает в докладами, в общем, все свои усилия направляет на развитие культуры родного народа.

Судьба внесла свои коррективы в планы Г. Ибрагимова. 17 марта 1927 года во время 7 съезда советов ТАССР его самочувствие резко ухудшилось: кровоизлияние в легкие, аспирационная пневмония, встала реальная угроза смерти. Он был госпитализирован в университетскую клинику в Казани. Консилиум врачей ставит диагноз туберкулеза легких, рекомендует немедленно уехать в теплые края. Передав все свои дела в Научном центре, 21 апреля 1927 года Г. Ибрагимов с семьей уехал в Крым. Здесь он был поручен заботам доктора А.В. Дьяконова, около года пролежал в разных больницах, а затем жил в Ялте под постоянным присмотром врачей. Правительства Татарстана и Крыма старались создать все условия для поддержания здоровья писателя. Семья Ибрагимовых сначала живет в доме

Ибраһимовны Боткин урамы 23 йортка күчерәләр, шунда кулга алына.

Бу юлы Казаннан китүне Г. Ибраһимов иҗат эше белән киңрәк шөгыльләнү өчен мөмкинлек дип кабул итә [Шакир Даутов. Кырымда // Галимҗан Ибраһимов: мәкаләләр, истәлек-хатирәләр. Б. 294]. «Безнең көннәр» романының дәвамын, «Тирән тамырлар» романын яза, моңа кадәр басылган әсәрләренең яңа басмаларын («Татар хатыныниләр күрми» һ.б.) әшли, әсәрләрен рус теленә тәрҗемә иттереп («Татар хатыны ниләр күрми», «Тирән тамырлар», «Казакъ кызы» романнары) нәшриятка әзерли, мәкаләләр яза.

«Тирән тамырлар» (1928) романы – социалистик реализм агымында иҗат ителгән әсәре, Г. Ибраһимовның шушы агымда милли әдәби традицияләрне яңартуына бер дәлил булып тора. Әйтерсең, әдип яңа тормыш төзү барышын сурәтләүне әдәбиятка үзе куйган таләпләрдән артык читләшмичә алып барырга тели: маҗаралылык, чорга бәя бирүне тирән тамырлар символы ярдәмендә



1936–1937 елларда Г. Ибраһимов яшәгән йорт. Ялта.

Дом, в котором в 1936–1937 годах проживал Г. Ибрагимов. Ялта.

Источник: Галимджан Ибрагимов: документы и факты; Галимджан Ибрагимов глазами молодых / [авт.-сост. М.Х. Ибрагимов]. Казань: Татар. кн. изд-во, 2012





1936–1937 елларда Г. Ибраһимов яшәгән йортның хәзерге күренеше. Ялта.

Современный вид дома, в котором в 1936–1937 годах проживал Г. Ибрагимов. Ялта.

Источник: Галимджан Ибрагимов: документы и факты; Галимджан Ибрагимов глазами молодых / [авт.-сост. М.Х. Ибрагимов]. Казань: Татар. кн. изд-во, 2012

№ 5 по улице Халтурина в городе Ялта, в 1927–1937 годах. Судя по воспоминаниям Шакира Даутова, писатель очень любил эту квартиру, которая располагалась близко к морю [Галимҗан Ибраһимов: мәкаләләр, истәлек-хатирәләр. Б. 289–295]. В 1937 году Ибрагимовы были переселены в дом № 23 по улице Боткина, там писатель и был арестован.

Этот отъезд из Казани Г. Ибрагимов воспринял как возможность заняться творческой деятельностью [Галимҗан Ибраһимов: мәкаләләр, истәлек-хатирәләр. Б. 294]. Он пишет продолжение романа «Наши дни», роман «Глубокие корни», готовит новые издания ранее опубликованных произведений, например «Судьба татарки». Организует перевод на русский язык некоторых произведений и готовит их к изданию, например «Судьба татарки», «Глубокие корни», «Дочь степи», пишет статьи.

Роман «Глубокие корни» (1928) – произведение, созданное в духе социалистического реализма, является

башкару, композиция өлкәсендәге тәҗрибәләр, сюжеттан тыш элементларның күпләп кулланылуы «пролетар әдәбиятына» хас схематизмнан котылырга мөмкинлек бирә. Детектив сюжет, «Хезмәт» совхозының алдынгы эшчесе Фәхринең үтерелгән гәүдәсе табылу, җинаятьчеләрне эзләү, аларны табып җәза бирү кебек, классик тәртиптә үсә барып, әсәрне мавыктыргыч ясый. Бер үк вакытта, «җинаять– җәза» рамкаларын Г. Ибраһимов социалистик идеяләр белән рухланган массалар психологиясен ачу өчен файдалана, җәмгыятьтә әхлак принципларының үзгәрешен бәян итә.

1928 елда Татарстанда Г. Ибраһимовның әдәби иҗатына һәм иҗтимагый-сәяси эшчәнлегенә 20 ел тулуын билгеләп үтү мәсьәләсе кузгатыла. 10 мартта Казанда тантаналы зур кичә уздырыла, анда әдипнең иҗаты турындагы төп докладлар татар һәм рус телләрендә Г. Нигъмәти һәм профессор Г. Линсцер тарафыннан ясала. Республиканың төрле төбәкләрендә конференцияләр,



Г. Ибраһимов татар язучылары арасында. Ялта. ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 5. С. б. 33
Г. Ибрагимов среди татарских писателей. Ялта. ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 5. Ед. хр. 33






Г. Ибраһимовның Хезмәт Батыры грамотасы (№ 118) күчермәсе. ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 2. С. б. 61
Копия грамоты Г. Ибрагимова – героя труда (№ 118). ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 2. Ед. хр. 61

доказательством того, что Ибрагимов обновил традиции национальной литературы в новом русле. Писатель будто хочет показать процесс строительства новой жизни, особо не отступая от требований, предъявляемых к художественным произведениям им же самим: приключенческий характер, оценка эпохи при помощи символа глубоких корней, эксперименты с композицией, использование внесюжетных элементов позволяют избежать схематизма, свойственного пролетарской литературе. Детективный по сути сюжет развивается как нахождение трупа убитого передового работника совхоза «Труд», поиск преступников и наказание, то есть в классической последовательности, делая произведение интересным и увлекательным. В то же время Г. Ибрагимов расширяет рамки преступления и наказания психологией героев, со¬циалистическими идеями и описанияем одухотворенности общества этими идеями, рассказывает о трансформациях моральных принципов в обществе.

әдәби кичәләр, очрашулар, җыелышлар була. Бу юбилей халык бәйрәменә әверелә. Әмма әдип үзе бу тантаналарда катнаша алмый. Юбилей уңаеннан һәм фән, мәдәният өлкәсендәге күренекле хезмәтләре өчен Г. Ибраһимов Дәүләт Сәнгать фәннәре академиясенең хакыйкый әгъзасы итеп сайлана. 1928 елның 13 августында аңа Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты карары белән Хезмәт Батыры дигән мактаулы исем бирелә.

1931 елның 21 мартында, 4 яше тулып узгач, Г. Ибраһимовның бердәнбер улы Рөстәм йөрәк параличыннан үлә. Кайгы атаның сәламәтлеген какшата, гаилә тормышына да тискәре тәэсир ясый. Гөлсем ханым белән аерылышалар.

1932 елда Г. Ибраһимовның сәламәтлеге яхшыра, ул Кырымнан китү турында да сүзләр кузгата. 1933 елның көзендә Татарстан хөкүмәте аны Республика колхозчы-ударникларының икенче съездына кунакка чакыра. 30 сентябрь көнне Казанга кайтып, 1 октябрьдә Ибраһимов съездда



Г. Ибраһимовны Беренче Бөтенсоюз совет язучыларының съездына делегат итеп сайлау хакында хәбәр. ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 2. С. б. 85

Новость о выборе Г. Ибрагимова депутатом на Первый всесоюзный съезд советских писателей. ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 2. Ед. хр. 85







Улы Рөстәмнең үлгәч төшерелгән фотосы, Г. Ибраһимов автографы белән. 1931. ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 5, С. б. 55

Фотография умершего сына Г. Ибрагимова Рустема с автографом писателя. 1931. ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 5. Ед. хр. 55

В 1928 году был татарское общество с размахом отметило двадцатилетие литературной и общественной деятельности Г. Ибрагимова. 10 марта 1928 года в Казани прошел торжественный вечер, где на татарском и русском языках были сделаны основные доклады о творчестве писателя Г. Нигмати и профессором Г. Линсцером. В разных уголках республике прошли конференции, литературные вечера, встречи, собрания. Юбилей стал народным праздником. Сам писатель не смог принять участие в торжественном мероприятии. По случаю юбилея за заслуги в области науки и культуры Г. Ибрагимов был избран действительным членом Государственной академии искусствоведческих наук. 13 августа 1928 года постановлением ВЦИК ему было присвоено звание Героя труда.

21 марта 1931 года, на пятом году жизни, единственный сын Г. Ибрагимова Рустем умер от паралича сердца. Это горе пошатнуло здоровье отца, негативно повлияло и на взаи-

чыгыш ясый, республикадагы зур үзгәрешләр турында сөйли. Ул районнарга да чыга, галимнәр, сәнгать әһелләре, яшь иҗатчылар белән очраша. Болар аның күңелендә зур канәгатьләнү тудыралар. Әдип Казаннан зур күңел күтәренкелеге белән кайта, әмма салкын тидереп, кабат авырып китә, больницага эләгә, 1934 һәм 1935 елларда ике авыр операция кичерә.

1935 елның 7 июнендә Г. Ибраһимов Ялтада Фәтхуллина Хәдичә Мөхәмәтдин кызы белән гаилә кора [Бу фактны башка төрле аңлату да бар. Кара: Галимджан Ибрагимов: документы и факты; Галимджан Ибрагимов глазами молодых: авт.-сост. М.-Х. Ибрагимов. Казань: Татар. кн. изд-во, 2012. С. 59–61]. Хәдичә ханымның үз сөйләвенә караганда, ул 1912 елда Уфада «Галия» мәдрәсәсе каршындагы мөгаллимәләр курсында әдәбият дәресләрен Г. Ибраһимовтан ала. 1932 елның җәендә Ялтага бара һәм шунда очрашып, алар бергә яши башлыйлар [Локман Бадыйкшан. «Мин аңа яшьтән үк гашыйк идем...» (Галимҗан Ибраһимовның



Г. Ибраһимов хатыны Хәдичә белән. 1935.
ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 5. С. б. 43
Г. Ибрагимов с женой Хадичой. 1935.
ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 5. Ед. хр. 43





Г. Ибраһимов хатыны Хәдичә һәм дуслары белән. 1935. ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 5. С. б. 42
Г. Ибрагимов с женой Хадичой и друзьями. 1935. ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 5. Ед. хр. 42

моотношения супругов. 1933 году Галимджан Ибрагимов и Гульсум Мухаммедова развелись.

В 1932 году здоровье Г. Ибрагимова несколько улучшилось, он даже поднял вопрос об отъезде из Крыма. Осенью 1933 года правительство Татарстана пригласила его на второй съезд колхозников-ударников. 30 сентября Ибрагимов вернулся в Казань, 1 октября выступил на съезде, говорил о больших изменениях в республике. Выезжал в районы, встречался с учеными, деятелями искусства, молодыми писателями. Все это вызвало удовлетворение в душе писателя. Он уехал из Казани с большим воодушевлением, но снова простудился, опять попал в больницу. В 1934 и 1935 годах перенес две операции.

7 июня 1935 года Галимжан Ибрагимов женился на Фатхуллиной Хадиче Мухаметдиновне (1893–1967). По рассказу Хадиче, она училась на курсах учительниц при медресе «Галия» в Уфе в 1912 году, где Г. Ибрагимов вел уроки литературы. Летом 1932 года она поехала в Ялту и

хатыны Хәдичә Фәтхуллина сөйләгәннәрдән) // Галимҗан Ибраһимов: мәкаләләр, истәлек-хатирәләр. Б. 426–428].

Авыруының торган саен җитди төс алуына карамастан, әдип гомеренең соңгы көннәренә кадәр әдәби һәм фәнни иҗат эшен дәвам иттерә. Казан белән тыгыз элемтәдә яши: татар язучылары аның янына килеп йөриләр. Төрле елларда фатирында Ш. Камал, Г. Нигъмәти, К. Тинчурин, И. Салахов, Ш. Госманов, М. Гафури, Г. Кутуй, М. Максуд, Һ. Такташ, С. Сәйдәшев К. Нәҗми, М. Әмир һ.б. булып китә. Аеруча яшь каләм әһелләренә ярдәм итә: Г. Ибраһимов аларга остаз да, киңәшче дә, тәнкыйтьче дә була. Мәсәлән, 1930 елның май аенда ул, Татарстанның ун еллыгына багышлап, шушы еллардагы мәдәни казанышларны барлаган «Ерактан сәлам» исемле язма әзерли. Анда Татарстанның әдәбияты, сәнгате өлкәсендәге казанышлар да, яшь көчләрнең уңышлары да, хәл ителергә тиешле мәсьәләләр дә уртага куеп сөйләшүгә чыгарыла. Мәкалә Г. Ибраһимовның татар дөньясында барган хәлләрдән тулысынча хәбәрдар булуын күрсәтә.



Кәрим Тинчурин
(1887–1938)
Карим Тинчурин
(1887–1938)





Һади Такташ
(1901–1931)
Хади Такташ
(1901–1931)

там встретила Г. Ибрагимова, а затем они начали жить вместе [Галимҗан Ибраһимов: мәкаләләр, истәлек-хатирәләр. Б. 426–428].

Несмотря на то, что болезнь писателя все усиливалась, он до конца своей жизни продолжал заниматься литературным и научным творчеством. Сохранил связи с Казанью: к нему приезжали татарские писатели. В разные годы в его квартире были Ш. Камал, Г. Нигмати, К. Тинчурин, И. Салахов, Ш. Гусманов, М. Гафури, А. Кутуй, М. Максуд, Х. Такташ, С. Сайдашев, К. Наджми, М. Амир и др. Г. Ибрагимов поддерживал молодых писателей, был для них и учителем, и советчиком, и критиком. Например, в мае 1930 года по случаю десятилетия ТАССР он подготовил публикацию «Ерактан сәлам» («Привет издалека»), освещающую культурные достижения республики. Там он предлагает обсудить современную литературу Татарстана, достижения в области искусства, успехи молодых писателей и другие вопросы, которые требуют решения. Статья

1937 елның башында рәсми даирәләрдә Г. Ибраһимовка карата ниндидер салкынлык барлыкка килүе сизелә башлый. Март аенда 50 яше тулу Татарстанда билгеләнмичә генә үтә. И. Салаховның истәлекләрендә мондый юллар бар: «Бу елның 12 мартында Галимҗан Ибраһимовка илле яшь тулды. Без, яшь язучылар, шул уңай белән Казанда әдәбият дөньясында зур тантана булыр дип өметләгән идек. Гаҗәпкә, бу көннәр бик «тыныч» үтте, хәтта газета-журнал битләрендә дә гадәттәге тәбрикләүләр, сәламләүләр күренмәде. Аптырадык. Бу ни хәл? Галимҗан ага татар әдәбиятына зур хезмәт күрсәткән, тирән хис, фикер тулы әсәрләре белән меңләгән, йөз меңләгән укучыларның күңелләрен җәлеп иткән, сөендергән, көендергән әдип, галим унҗиденче елга хәтле үк инкыйлаб хәрәкәтендә катнашкан, шуның өчен төрмәләрдә утырган, әмма бу юлыннан тайпылмаган кыю большевик, җәмәгать эшлеклесе бит. Ул татар әдәбияты, мәдәнияте, фән үсеше өчен бар көчен, гомерен фида иткән талант иясе. Ничек инде шундый олы, фидакарь



Кави Нәҗми
(1901–1957)
Кави Наджми
(1901–1957





Салих Сәйдәшев
(1900–1954)
Салих Сайдашев
(1900–1954)

показывает, что Г. Ибрагимов был хорошо осведомлен о процессах, происходящих в татарском мире.

В начале 1937 года отношение официальных кругов к Г. Ибрагимову охлаждается. Пятидесятилетие писателя в марте 1937 года в Татарстане практически не было упомянуто. В воспоминаниях И. Салахова написано следующее: «12 марта сего года Галимджану Ибрагимову исполнилось 50 лет. Мы, молодые писатели, по этому случаю ожидали в Казани большое мероприятие. На удивление, эти дни прошли очень спокойно, даже на страницах газет и журналов не было никаких обычных в таких случаях поздравлений и приветствий. Удивительно. Что за дела? Галимджан ага – личность, верой и правдой служивший татарской литературе своими произведениями, наполненными глубокими чувствами, мыслями, оказавшими влияние на души тысяч, сотен тысяч читателей; писатель, ученый, который еще до 1917 года принимал активное участие в революционном движении, из-за этого просидевший в

затның хезмәте, табыш-җимешләре игътибарсыз, ихтирамсыз кала?» [Галимҗан Ибраһимов: мәкаләләр, истәлек-хатирәләр. Б. 430–431].

Үзе дә үлем лагерьларын үтеп, акланып кайтканнан соң, «Колыма хикәяләре» роман-хроникасында (1989 елда басыла) И. Салахов әлеге сорауларга җавап эзләп архивларда эзләнүләрен искә ала, Мәскәүдәге Үзәк дәүләт әдәбият һәм сәнгать архивында (ЦГАЛИ) «Татар совет әдәбиятындагы корткычлык турында» (1937 ел, 19 ноябрь) дип исемләнгән документка тап булуын, анда татар әдәбияты, иҗатчылар адресына коточкыч гаепләү сүзләре әйтелүне, Г. Ибраһимовның латинга кучүгә, Сталинның милли сәясәт тәгълиматына каршы хәрәкәт оештыруы турында сүз алып барылуны сөйләп уза [Галимджан Ибрагимов: документы и факты; Галимджан Ибрагимов глазами молодых. С. 123–124]. Күрәсең, Г. Ибраһимовның милли мәнфәгатьләрне алга куюы һәм татар дөньясындагы абруе совет идеологиясенә куркыныч янау булып тоела.



Галимҗан Ибраһимов.
ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 5. С. б. 28

Галимджан Ибрагимов.
ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 5. Ед. хр. 28





Галимҗан Ибраһимов. ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 5. С. б. 27
Галимджан Ибрагимов. ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 5. Ед. хр. 27

тюрьмах, но так и не отошедший от своего пути, смелый большевик, общественный деятель. Весь свой талант направил на развитие татарской литературы, культуры, науки. Как можно оставить без должного внимания, без уважения заслуги такого великого человека?» [Галимҗан Ибраһимов: мәкаләләр, истәлек-хатирәләр. Б. 430–431].

И. Салахов, и сам прошедший через лагеря, позже попытался найти ответы на эти вопросы. В Центральном государственном архиве литературы и искусства в Москве (ЦГАЛИ) он обнаружил документ от 19 ноября 1937 года, в котором в адрес многих татарских литераторов было высказано обвинение, отмечено, что Г. Ибрагимов был против перехода на латиницу, что он организовал движение против национальной политики Сталина [Галимджан Ибрагимов: документы и факты; Галимджан Ибрагимов глазами молодых. С. 123–124]. Видимо, защита Г. Ибрагимовым национальных интересов и авторитет его в татарском мире были расценены опасными для Советской идеологии.

Хәер, совет хөкүмәте Г. Ибраһимовка беркайчан да тулысынча ышаныч күрсәтми, дип яза тарихчы А.Л. Литвин архив документларына нигезләнеп. Аның артыннан һәрвакыт күзәтәләр, 1927–1928 елларда оператив күзәтү активлаша. Галим моны Ибраһимовның Октябрь инкыйлабының 10 еллыгы уңаеннан, партия өлкә комитетында милли мәсьәләләр буенча махсус киңәшмәгә чыгыш буларак язылган «Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак?» (1927) китапчыгы, әлеге хезмәттәге татарларның, кайда гына яшәсәләр дә, үзләрен бердәм татар мәдәнияте вәкилләре кебек хис итүләре, шуңа күрә татар мәдәниятен Татарстан белән чикләмичә өйрәнү һәм үстерү кирәклеге турындагы фикерләре белән бәйләп аңлата. 1927 елның 14 июнендә ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты Г. Ибраһимов чыгышын милли-мәдәни автономиягә чакыру буларак карый һәм кире кага, әдипнең үзен «милли мәдәниятне социализм төзү чарасы итеп түгел, үзмаксат буларак карауда» гаеплиләр [Галимджан Ибрагимов:



Г. Ибраһимовның
Габделхак Ибраһимовка биргән
фотосы. 1932.
ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 5. С. б. 19

Фотография Г. Ибрагимова,
подаренная им Габдельхаку
Ибрагимову. 1932.

ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 5. Ед. хр. 19





Фотоның арткы ягындагы
Г. Ибраһимов автографы.
1932 ел, 29 август.
ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 5. С. б. 20

Автограф Г. Ибрагимова на
обороте фотографии, подаренной
Габдельхаку Ибрагимову.
29 августа 1932.
ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 5. Ед. хр. 20

Говоря по правде, советская власть никогда полностью не доверяла Г. Ибрагимову. Как пишет А.Л. Литвин, основываясь на архивных документах, за ним постоянно следили. В 1927–1928 годах оперативная слежка активизируется. Ученый объясняет это тем, что по случаю 10-летия Октябрьской революции Г. Ибрагимов подготовил большое выступление для особого совещания обкома партии по национальным вопросам «Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак?» («По какому пути пойдет татарская культура», 1927), которое было опубликовано отдельной книгой. В этой книге было указано, что татары, где бы они ни жили, ощущают себя представителями единой татарской культуры, поэтому необходимо изучать татарскую культуру, не ограничиваясь лишь Татарстаном. 14 июня 1927 года обком ТАССР оценил выступление Г. Ибрагимова как призыв к национально-культурной автономии, а самого писателя обвинил в том, что он рассматривает национальную культуру не только как средство строительства

документы и факты; Галимджан Ибрагимов глазами молодых. С. 130].

Соңгы елларда 1937 елның 10 мартында әдәбият тәнкыйтьчесе Гомәр Галинең кулга алынуы, аннан беренче (1937 елның 20 марты) һәм икенче сорау алу (1937 елның 4 мае) беркетмәләрендәге сәер төгәлсезлекләр, шуның белән бәйләп Г. Ибраһимовның 144 хаты җентекләп өйрәнелү турында мәгълүматлар билгеле булды. Р. Мостафин әлеге эшләрнең Г. Ибраһимовка каршы кампаниянең башлангычы булуын күрсәтә [Галимджан Ибрагимов: документы и факты; Галимджан Ибрагимов глазами молодых. С. 138–142]. «Ибраһимов эше»ндә башка «эшләр» буенча алданрак кулга алынган партия эшлеклеләре М. Баһаветдинов (элеккеге комсомол өлкә комитетының секретаре), Г. Мөхәммәтҗанов (элеккеге ВКП(б) өлкә комитетының икенче секретаре), И. Рәхмәтуллин (элеккеге ВКП(б) өлкә комитетының бүлек мөдире), В. Филиппов (элеккеге Татарстан Үзәк сайлау комиссиясе секретаре), К. Абрамов



Галимҗан Ибраһимов.
ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 5. С. б. 29

Галимджан Ибрагимов.
ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 5. Ед. хр. 29





Ялта шәһәре күренеше. XX йөз башы

Вид города Ялта. Начало XX века

социализма, а как самоцель [Галимджан Ибрагимов: документы и факты; Галимджан Ибрагимов глазами молодых. С. 130].

В последние годы стало известно, что с целью обвинения Г. Ибрагимова 10 марта 1937 года был арестован литературный критик Гумер Гали, раскрылись странные несоответствия в протоколах первого (20 марта 1937 года) и второго (4 мая 1937 года) его допроса, факт изучения и экспертизы 144 писем Г. Ибрагимова органами. Р. Мустафин отмечает, что эти дела были началом кампании против Г. Ибрагимова [Галимджан Ибрагимов: документы и факты; Галимджан Ибрагимов глазами молодых. С. 138–142]. В «деле Ибрагимова» были показания арестованных ранее по другим делам М. Багаутдинова, секретаря обкома комсомола; Г. Мухаметзянова, второго секретаря обкома ВКП(б); И. Рахматуллина, завотделом обкома ВКП(б); В. Филиппова, секретаря Центральный Татарской избирательной комиссии; К. Абрамова, председателя Совета

(элеккеге Татарстан АССР Министрлар Советы рәисе), язучы Кави Нәҗми күрсәтмәләре һәм Казан дәүләт педагогия институты ректоры булып торган Газыйм Касыймов гаризасы мөһим роль уйный [Галимджан Ибрагимов: документы и факты; Галимджан Ибрагимов глазами молодых. С. 128–130].

1937 елның 25 августында Г. Ибраһимовны, 1920 еллардан башлап, «Уң троцкийчы милләтчеләрнең совет хакимиятенә каршы оешмасы» эшендә катнашуда Җинаятьләр Кодексының 58/10 һәм 58/11 маддәләре буенча гаепләү кәгазенә кул куела, өендә тентү уздырыла, үзен 29 августта кулга алалар [Галимджан Ибрагимов: документы и факты; Галимджан Ибрагимов глазами молодых. С. 34–80]. Авыру хәлендәге әдипне Казанга алып кайталар. Г. Ибраһимовның туганнары, ул Казанга барып җитмәгән, дип тә әйтәләр [Галимджан Ибрагимов: документы и факты; Галимджан Ибрагимов глазами молодых. С. 62]. Ул 1938 елның 21 гыйнварендә Черек күл (Черное



Галимҗан Ибраһимов.
ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 5. С. б. 30

Галимджан Ибрагимов.
ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 5. Ед. хр. 30





Галимҗан Ибраһимов рәсеме. ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 5. С. б. 26

Портрет Галимджана Ибрагимова. ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 5. Ед. хр. 26

Министров Татарстана; писателя Кави Наджми; заявление ректора Казанского государственного педагогического института Газима Касимова [Галимджан Ибрагимов: документы и факты; Галимджан Ибрагимов глазами молодых. С. 128–130].

25 августа 1937 года было подписано обвинение Г. Ибрагимова по статьям 58/10 и 58/11 Уголовного кодекса в том, что начиная с 1920-х годов он принимал участие в работе антисоветской деятельности националистов правых троцкистов; в его доме был произведен обыск. Сам он был арестован 29 августа [Галимджан Ибрагимов: документы и факты; Галимджан Ибрагимов глазами молодых. С. 34–80]. Больного писателя привезли в Казань. Есть и другая версия происходивших событий [Галимджан Ибрагимов: документы и факты; Галимджан Ибрагимов глазами молодых. С. 62]. Судя по документам [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Тугыз томда. Т. 9: Хатлар һәм документлар. Б. 336], 21 января 1938 года Галимджан Ибрагимов умер в тюремной больнице на Черном

озеро) төрмә хастаханәсендә вафат була. 27 гыйнварда Архангел зиратында гомуми кабергә күмелә.

1938–1956 еллар аралыгында Г. Ибраһимовның мирасы гына түгел, исеме дә татар мәдәниятеннән алып ташлана. Ә бит, кулга алынганчы, аның иҗаты иң актив өйрәнелгәннәрдән була. 1917 елдан соң Г. Ибраһимовның әсәрләрен ХХ йөз башы әдәби барышында тулы бер мәктәп барлыкка китергән иҗат буларак бәяләү омтылышлары да ясала: аерым алганда, Г. Сәгъди хезмәтләрендәге монографик бүлекләр [Сәгъди Г. Татар әдәбияты тарихы. Казан: Татар. дәүләт нәшр. басмасы, 1926. 300 б.; Сәгъди Г. Пролетариат диктатурасы дәверендә татар әдәбияты («Татар әдәбияты тарихы»ның икенче бүлеге урынында). Казан: Татиздат, 1930. 200 б.], аның күпсанлы мәкаләләре [Сәгъди Г. Карт марксист, бөек әдип Галимҗан Ибраһимов һәм аңа юбилей әзерлеге // Мәгариф. 1927. № 12. 94–98 б.; Сәгъди Г. Татар пролетариат матур әдәбиятына 20 ел // Кызыл Татарстан. 1927, 2 февраль; Сәгъди Г. Галимҗан



Казанның Архангел зиратында Г. Ибраһимовка символик рәвештә куелган каберташ.
ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 5. С. б. 57

Надгробный памятник Г. Ибрагимову над символической могилой на Архангельском кладбище.
ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 5. Ед. хр. 58





«Галия» мәдрәсәсе бинасына куелган мемориаль такта. Уфа.
ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 5. С. б. 59

Мемориальная доска на здании медресе «Галия». Уфа.
ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 5. Ед. хр. 59

Озере. 27 января был похоронен в общей могиле на Архангельском кладбище.

В 1938–1956 годах не только творчество Г. Ибрагимова, но даже его имя было вычеркнуто из татарской культуры. До ареста творчество Ибрагимова было одним из самых активно изучаемых. После 1917 года были сделаны попытки расценить творчество Ибрагимова как создавшее свою школу в процессе развития татарской литературы в начале ХХ века: в частности, в трудах Г. Сагди («Татар әдәбияты тарихы» (1926), «Пролетариат диктатурасы дәверендә татар әдәбияты («Татар әдәбияты тарихы»ның икенче бүлеге урынында)» (1930), («Карт марксист, бөек әдип Галимҗан Ибраһимов һәм аңа юбилей хәзерлеге» (1927), «Татар пролетариат матур әдәбиятына 20 ел» (1927), «Галимҗан Ибраһимов иҗатында типлар эволюциясе» (1928) и др., Г. Нигмати («Галимҗан Ибраһимовның яңа әсәре» (1929), «Г. Ибраһимов һәм аның иҗат юлы турында» (1932) һ.б.), Ф. Сайфи-Казанлы высказывается именно такая оценка.

Ибраһимов иҗатында типлар эволюциясе // Мәгариф. 1928. № 2. Б. 24–33], Г. Нигъмәтинең әдип әсәрләрен күзәтеп-анализлап барган әтрафлы язмалары [Нигъмәти Г. Галимҗан Ибраһимовның яңа әсәре // Революция елларында әдәбиятыбыз. М., 1929. Б. 80–99; Нигъмәти Г. Г. Ибраһимов һәм аның иҗат юлы турында // Яңалиф. 1932. № 6/7. Б. 104–113; № 8. Б. 77–88 h.б.], Ф. Сәйфи-Казанлының иҗтимагый фикергә караган хезмәтләренә бәяләмәләре шундыйлардан. Ләкин бу чорның идеологик каршылыклар, эзләнүләр чоры булуы әдип иҗатын бөтенлекле анализларга комачаулый.

Г. Ибраһимовны кулга алу белән бәйле документларны өйрәнгән А.Л. Литвин, әдипнең мирасын юк итү омтылышына тукталып, болай дип яза: «Язучы өстеннән суд булмый, тикшерү эше аның үлеме белән бәйле туктатыла. Бернинди гаепләү юк. Нәрсә нигезендә аның әсәрләре китапханәләрдән җыеп алына, ни өчен исемен яхшы яктан телгә алырга ярамый – бу аңлашылмый... Җавап



Г. Ибраһимов исемендәге бульварга куелган мемориаль такта. Уфа
Мемориальная доска на бульваре Г. Ибрагимова. Уфа





Г. Ибраһимовның үзе исән вакытта басылган китаплары
Прижизненные издания Г. Ибрагимова

Но то, что этот период был полон противоречий и был, по сути, временем исканий, мешает детальному анализу творчества писателя.

А.Л. Литвин, изучавший документы, связанные с арестом Г. Ибрагимова, останавливаясь на вопросе уничтожения наследия писателя, пишет следующее: над писателем не было суда, следственное дело было прекращено в связи с его смертью. Никакого обвинения нет. На каком основании его произведения были изъяты из библиотек? Почему нельзя было упоминать его имя? Это совершенно не ясно. Видимо, в государстве, где действует не закон, а человек, который сидит во главе правительства, можно делать все, что угодно [Галимджан Ибрагимов: документы и факты; Галимджан Ибрагимов глазами молодых. С. 135].

После разоблачения культа личности, когда начались оправдания необоснованно обвиненных деятелей науки и культуры, писатель Амирхан Еники обратился к правительству с просьбой пересмотреть дело Галимджана

бер: хокуксыз, идеологиягә буйсындырылган, закон түгел, бәлки хакимият башындагы кешенең фикере өстенлекле булган дәүләттә нәрсә эшләсәң дә ярый» [Галимджан Ибрагимов: документы и факты; Галимджан Ибрагимов глазами молодых. С. 135].

Шәхес культы фаш ителеп, гаепсез тоткыннарны аклау башлангач, язучы Ә. Еники Г. Ибраһимов эшен кабат карауны сорап мөрәҗәгать итә. Әдипне аклау хакындагы карар чыгуга (1955 елның 24 сентябре) [Галимджан Ибрагимов: документы и факты; Галимджан Ибрагимов глазами молодых. 336 с.] аның иҗат мирасын кайтару комиссиясе оеша, өч томлык сайланма әсәрләрен басмага әзерләү эше башлана. Бу эшне Г. Халит башлап йөри: китаплар 1956 елда басылып та чыгалар. Г. Ибраһимов әсәрләре әдәби барышка, урта һәм югары уку йортлары программаларына әйләнеп кайта, СССР һәм чит ил халыклары телләренә тәрҗемә ителә. Урамнарга, аерым мәдәният оешмаларына аның исеме бирелә. 1961 елда исә яшь галим М. Хәсәнов Галимҗан Ибраһимовның Октябрьгә




Г. Ибраһимовның 1956–1957 елларда басылган өч томлы «Сайланма әсәрләр»е

«Избранные произведения» Г. Ибрагимова в трех томах, изданные в 1956–1957 годах





Афзал Шамов (1901–1990)

Афзал Шамов (1901–1990)

Ибрагимова. 24 сентября 1955 года, когда было вынесено Постановление об оправдании писателя [Ибраһимов Г. Әсәрләр. Т. 9: Хатлар һәм документлар. Б. 337], была организована комиссия по возвращению творческого наследия писателя, началась работа по подготовке к изданию избранных сочинений Г. Ибрагимова 3 томах. Во главе этой работы стал Г. Халит. Книги были изданы в 1956 году. Произведения Г. Ибрагимова вернулись в программы школ и вузов, были переведены на языки народов СССР и иностранные языки. Его именем были названы улицы, отдельные культурные учреждения. В 1961 году молодой ученый М.Х. Хасанов успешно защитил диссертацию на соискание ученой степени кандидата филологических наук по дооктябрьскому периоду творчества Галимджана Ибрагимова. В 1964 году была опубликована его монография, систематизирующая и анализирующая многочисленные произведения, критические, научные труды Г. Ибрагимова [Хәсәнов М.Х. Галимҗан Ибраһимов. Тормыш һәм иҗат юлы. Казан:

кадәрге иҗаты буенча кандидатлык диссертациясе яклый [Хәсәнов М.Х. Галимҗан Ибраһимов иҗаты: Октябрьгә кадәрге чор: филол. фән. канд. ... дис. Казан, 1961. 343 б.]; 1964 елда язучының күпсанлы әсәрләрен һәм тәнкыйди, фәнни хезмәтләрен системага салып язылган саллы монографиясе укучыга тәкъдим ителә [Хәсәнов М. Галимҗан Ибраһимов: тормыш һәм иҗат юлы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1964. 331 б.]. Галимҗан Ибраһимов тормышы һәм иҗаты, күпкырлы эшчәнлеге әдәбият белеме галиме, җәмәгать эшлеклесе М. Хәсәновның гомерлек темасына әверелә [Хасанов М. Галимджан Ибрагимов: крат. очерк жизни и творчества. Казань: Татар. кн. изд- во, 1966. 26 с.; Хасанов М.Х. Галимджан Ибрагимов. Казань: Татар. кн. изд- во, 1969. 432 с.; Хасанов М. Галимжан Ибрагимов. Казань: Таткнигоиздат, 1977. 432 с. һ.б.]. М.Х. Хәсәнов 1971 елда Г. Ибраһимов шәхесенең Октябрь инкыйлабыннан соңгы чорына багышланган докторлык диссертациясен уңышлы яклый [Хасанов М.Х. Эволюция творчества Галимджана Ибрагимова в послеоктябрьский



Мансур Хәсәнов (1930–2010)

Мансур Хасанов (1930–2010)






Мансур Хәсәновның Г. Ибраһимов турындагы хезмәтләре

Труды Мансура Хасанова о Г. Ибрагимове

Татар. кит. нәшр., 1964. 332 б.]. Жизнь и творчество, многоплановая деятельность Г. Ибрагимова стали пожизненный темой М. Хасанова. В 1971 году М. Хасанов защитил докторскую диссертацию по творчеству Г. Ибрагимова после Октябрьской революции. В 1987 году вышла монография в Москве на русском языке (Хасанов М.Х. Писатель, ученый, революционер: страницы жизни и творчества Г. Ибрагимова. М.: Наука, 1987. 318 с.). Наследием Г. Ибрагимова занимались и другие ученые: можно отметить Г. Халита, Х. Усмана, И. Нуруллина, А. Шамова, Ф. Агзамова, Ф. Баширова и др. Издаются публицистические, биографические и литературные труды (Мухамедова З.Д. Большая жизнь. Казань: Татар. кн.изд-во, 1968. 100 с.; Поварисов С.Ш. Күкнең җиденче катында: романнар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. 464 б.; и др.).

В 1974 году было принято решение о подготовке собрания сочинений писателя в 8 томах, в 1974–1987 годах тома собрания были изданы. В 1987 году по случаю 100-летия

период: дис. ... д-ра филол.. наук / ИВ АН СССР. М, 1971. 595 с.]. 1987 елда китап рус телендә Мәскәүдә дөнья күрә [Хасанов М.Х. Писатель, ученый, революционер: страницы жизни и творчества Г. Ибрагимова. М.: Наука, 1987. 318 с.]. Г. Ибраһимов мирасын барлау белән башка галимнәр дә актив шөгыльләнә: бу юнәлештә эшләгән Г. Халит, Х. Госман, И. Нуруллин, А. Шамов, Ф. Әгъзамов, С. Поварисов, Я. Абдуллин, Ф. Бәширов, М. Мәһдиев, Г. Әдһәмова һ.б. галимнәрне аерып күрсәтергә мөмкин. Г. Ибраһимов шәхесенә шәхси-әдәби бәя биреп язылган әдәби, публицистик, биографик китаплар да нәшер ителә [Мухамедова З.Д. Большая жизнь. Казань: Татар. кн. изд-во, 1968. 100 с.; Поварисов С.Ш. Күкнең җиденче катында: романнар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. 464 б. һ.б.].

1974 елда язучының сигез томлыгын (1974–1987) әзерләү турында карар кабул ителә, әлеге томнар 1987 елга кадәр укучы кулына килеп ирешә. Г. Ибраһимовның юбилейларына багышлап республикада зур чаралар, фәнни-гамәли конференцияләр уздырыла, әдипнең иҗат мирасын, шул




Мансур Хәсәновның Г. Ибраһимов турындагы хезмәтләре
Труды Мансура Хасанова о Г. Ибрагимове






Г. Ибраһимовның тугызтомлык «Әсәрләр»е
«Произведения» Г. Ибрагимова в девяти томах

Галимджана Ибрагимова в республике прошли большие мероприятия, научно-практические конференции.

В 1967 году Институту языка, литературы и истории было присвоено имя Галимджана Ибрагимова, сейчас это Институт языка, литературы и искусства имени Галимджана Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. В 1987 году был открыт музей писателя в его родной деревне Султанмуратово.

Перестроечное время внесло два новшества в изучение творческого наследия Г. Ибрагимова: во-первых, были опубликованы документы о его жизни, особенно об аресте [Галимҗан Ибраһимов: мәкаләләр, истәлек-хатирәләр / төз. Р. Акъегет. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007; Галимджан Ибрагимов: документы и факты; Галимджан Ибрагимов глазами молодых / авт.-сост. М.-Х. Ибрагимов. Казань: Татар. кн. изд-во, 2012]. В добавление к 8-томнику произведений Г. Ибрагимова был составлен и издан девятый том, полностью состоящий из документов и писем [Ибраһимов Г.

мирасның күләгәдәрәк кала килгән якларын тикшерү эше алып барыла.

1967 елны Тел, әдәбият һәм тарих институтына Г. Ибраһимов исеме бирелә (хәзер – Татарстан Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм сәнгать институты). 1987 елда туган авылы Солтанморатта язучының музее ачыла.

Ибраһимовның иҗат мирасын өйрәнүгә үзгәртеп корулар ике яңа юнәлеш өсти: бер яктан, аның тормышына кагылышлы, бигрәк тә кулга алынуы белән бәйле бик күп документлар әйләнеп кайта [Галимҗан Ибраһимов: мәкаләләр, истәлек-хатирәләр: төз. Р. Акъегет. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. 544 б.; Галимджан Ибрагимов: документы и факты; Галимджан Ибрагимов глазами молодых: авт.-сост. М.-Х. Ибрагимов. Казань: Татар. кн. изд-во, 2012. 336 с.], хәтта 8 томлыкка өстәп Ф. Ибраһимова документлар, хатлардан торган 9 нчы томны төзи [Галимҗан Ибраһимов. Әсәрләр: тугыз томда. Т. 9: Хатлар һәм документлар: төз. Ф. Ибраһимова. Казан, 2000. 464 б.]. Икенче яктан, иҗатына, хезмәтенә яңача



Г. Ибраһимовның Солтанморат авылындагы музей-йорты.

Дом-музей Г. Ибрагимова в деревне Султанмуратово.

Источник: Галимджан Ибрагимов: документы и факты; Галимджан Ибрагимов глазами молодых / [авт.-сост. М.Х. Ибрагимов]. Казань: Татар. кн. изд-во, 2012





Казанда Г. Ибраһимов исемендәге 17 нче номерлы татар гимназиясе каршындагы язучы бюсты

Бюст у Татарской гимназии № 17 им. Г. Ибрагимова г. Казани

Әсәрләр. Тугыз томда. Казан, 2000. Т. 9: Хатлар һәм документлар / төз. Ф.Ибраһимова]. Во-вторых, были написаны научные труды, которые подходили к изучению творчества и деятельности Г. Ибрагимова уже без политических ограничений (Саляхова З.Г. Натурализм в творчестве Галимджана Ибрагимова: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2004. 23 с.; Хакимова Л.З. Формирование и эволюция общественно-политических и исторических взглядов Галимджана Ибрагимова: автореф. дис. ... канд. ист. наук. Казань, 2004. 27 с.; Хакимов Б.Э. Деятельность Галимджана Ибрагимова в области татарского языкознания: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2005. 29 с.; Мингазова Р.А. Руссоистские традиции в творчестве Галимджана Ибрагимова: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2009. 26 с.).

Галимджан Ибрагимов – личность, которая изменила татарскую культуру, татарское общество, литературу, науку, национальное самосознание народа, его духовный мир, открыла новые возможности в описании духовного мира

тыю-чикләүләрсез анализ ясаган махсус фәнни хезмәтләр язылa [Хакимова Л.З. Общественно-политические и исторические взгляды Галимджана Ибрагимова. Казань : Татар. кн. изд-во, 2007. 119 с.], диссертацияләр яклана [Саляхова З.Г. Натурализм в творчестве Галимджана Ибрагимова: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2004. 23 с.; Хакимова Л.З. Формирование и эволюция общественно-политических и исторических взглядов Галимджана Ибрагимова: автореф. дис. ... канд. ист. наук. Казань, 2004. 27 с.; Хакимов Б.Э. Деятельность Галимджана Ибрагимова в области татарского языкознания: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2005. 29 с.; Мингазова Р.А. Руссоистские традиции в творчестве Галимджана Ибрагимова: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2009. 26 с.], күпсанлы мәкаләләр басыла.

Шулай итеп, Галимҗан Ибраһимов – татар мәдәниятен һәм гомумән җәмгыятен, әдәбиятны, фәнне, милли үзаңны үзгәрткән, халыкның рухи дөньясын сурәтләүдә яңа мөмкинлекләр ачкан шәхесләрдән. Аның тормышы, иҗаты, күпкырлы



Казан шәһәрендәге Галимҗан Ибраһимов проспекты

Проспект Ибрагимова в г. Казани






«Галимҗан Ибраһимов турында истәлекләр» китабы. 1966

Книга «Воспоминания о Галимджане Ибрагимове». 1966

народа. Вся его жизнь, творчество, политическая, научная и культурная деятельность служили одной цели – возрождению татарской культуры, совершенствованию татарского мира, поднятию его на более высокую светлую, прекрасную и духовную ступень. Как его научные труды стали основой формирования и установления джадидистской системы образования среди татар, развития татароведения, так и общественно-политическая жизнь служила обновлению татарского общества.

В истории татарской литературы у Г. Ибрагимова есть свое, только его место: он тот, кто создал новую татарскую литературу в начале XX века, талантливый прозаик, который определил пути развития этой литературы на долгие годы вперед. Произведения писателя, направленные на создание романтического идеала, показали высоты, к которым должен стремиться татары, красоту, чистоту, свойственную человеку в общем духовную глубину, богатство мысли, сопереживание – все это было описано Г. Ибрагимо-

сәяси, фәнни һәм мәдәни эшчәнлеге бер максатка – татар яңарышына, алгарышына, татар дөньясын рухи югарылыкка күтәрүгә юнәлтелгән була. Фәнни хезмәтләре татарларда җәдиди уку-укыту системасын формалаштыру, татарларны өйрәнүче гуманитар фәннәрне үстерү юлында бәяләп бетергесез яңалыклар алып килгән кебек, шәхси сәяси-иҗтимагый тормышы да татар җәмгыятен, андагы карашларны яңарыш дулкынына көйләүгә хезмәт итә.

Татар әдәбияты барышында Г. Ибраһимовның үз урыны бар: ул – XX гасыр башында мәйданга чыккан яңа татар әдәбиятын тудыручы, аның үсеш юлларын билгеләүче талантлы прозаик. Әдипнең романтик идеал тудыруга йөз тоткан, татар кешесе омтылырга тиешле бөеклек һәм биеклекләрне, сафлык-матурлыкларны, гомумән кешегә хас күңел тирәнлеген, фикер байлыгын, акыл мөмкинлекләрен, хис-кичерешләр муллыгын соклангыч тасвирлый алган әсәрләре татар җәмгыятен үзгәртү зарурлыгын үзәккә куя белгән, милләт язмышына битараф булмаган, үзен




Гөлсем Мөхәммәдованың «Эзләнүләр» китабы. 1987

Книга Гульсум Мухаммедовой «Поиски». 1987






Г. Ибраһимовның тууына 100 ел булуга багышланган фәнни-гамәли конференция программасы. 1987. ЯһММҮ. Ф. 65. Тасв. 2. С. б. 83

Программа научно-практической конференции, посвященной 100-летию Г. Ибрагимова. ЦПиМН. Ф. 65. Оп. 2. Ед. хр. 83

вым с изумительной красотой. Центральные фигуры произведений Г. Ибрагимова – молодежь, которая растет, развивается, приходит к мысли о необходимости перестройки татарского общества; это романтические активные герои, которые неравнодушны к судьбе своего народа, позиционируют себя как неделимая часть общества.

Творчество Г. Ибрагимова ценно тем, что воссоздало картину эпохи не только в историко-культурном плане, но и в психологическом, психоаналитическом и философском аспектах. Его прозаические произведения по части описания цельности жизни, ее единства с историко-культурной картиной времени продолжают традиции русских и европейских писателей. В то же время по философской составляющей, приданию произведениям дополнительных смыслов, оттенков, выстраиванию многослойной жизни он является продолжателем традиций и восточной литературы. С помощью всех этих приемов Ибрагимов-писатель добивается национального, поистине народного звучания тем и моти-

җәмгыятьнең бер вәкиле итеп санаучы актив романтик геройлар иҗат итә.

Г. Ибраһимов әсәрләре чор панорамасын тарихи-мәдәни аспектта гына түгел, психологик, психоаналитик, фәлсәфи яссылыкларда тергезүләре белән дә әһәмиятле. Тормышның бөтенлекле тарихи-мәдәни сурәтен ясау ягыннан аның проза әсәрләре рус һәм Европа сүз осталарының роман традицияләрен дәвам итә. Шул ук вакытта фәлсәфи тирәнлек, өстәмә мәгънәләр бирү, күпкатламлы тормыш моделе төзү өчен ул шәрык әдәбиятларына, саф Европа романтизмына хас символларга, психологизм алымнарына мөрәҗәгать итә. Шулар ярдәмендә тарихи заман алып килгән тема һәм мотивларга милли яңгыраш бирә. Шушы сыйфатлары белән аның иҗаты дөнья әдәбияты фонында үзенчәлекле бәя ала.

1914 елдан соң әдипнең иҗат кредосы үзгәрә башлый. Ул, бөек тарихи вакыйгалар чорында яшәвен аңлап, үзенең каләм көчен, талантын, рәссамлык осталыгын инкыйлаби вакыйгаларны теркәп калдыруга, аларның төрки-татар дөньясына




Г. Ибраһимовка багышланган фәнни-гамәли конференция материаллары җыентыгы. 2003

Сборник материалов конференции, посвященной Г. Ибрагимову. 2003






Г. Ибраһимовка багышланган фәнни-гамәли конференция материаллары җыентыгы. 2007

Сборник материалов конференции, посвященной Г. Ибрагимову. 2007

вов, предлагаемых исторической эпохой. Это качество творчества позволяет дать ему своеобразную оценку на фоне мировой литературы.

Творческое кредо писателя начало меняться в 1914 году. Осознав, что живет в эпоху великих исторических событий, Г. Ибрагимов всю силу своего творчества, весь свой талант, мастерство художника направил на фиксирование событий революционной действительности, пытался описать их влияние на татарский мир и в общем на человека, воздействие их на национальные интересы. Создание хроники исторических событий, показ изменения характера человека в этих событиях он считал для себя делом чести.

К сожалению, в 1927 году, именно в тот момент, когда Г. Ибрагимов начал служить своей высокой цели и как политик, и как общественный деятель, и как ученый, тяжелая болезнь подкосила его, заставила умерить пыл, отказаться от надежд. И после этого, даже если и не мог, как раньше, активно трудиться, писатель оставался в строю, был

һәм, гомумән, кеше шәхесенә тәэсирен, милли мәнфәгатьләргә йогынтысын сурәтләүне алга куя. Тарихи вакыйгалар елъязмаларын булдыруны, шул өермәләр эчендә кеше холык-фигыленең үзгәрешен күрсәтүне үзенең намус эше дип саный. Әдипнең «...өченче дәвер әдәбияты нәфисәсе, «буржуа-пролетарий-революция» сүзләрен күп вакыт телгә дә алмастан, тик сыйнфый көрәш фаҗигаләрен, эшче-крәстиян тормышларын битараф тасвирлар, азатлыкка таба хыялый романтизм ялкыннары белән бу дәвер рухына хезмәт итәр» [Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. Т. 5: Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933). 300 б.] дигән сүзләре аның шул чор иҗат максаты белән тәңгәл килә.

Кызганычка каршы, милли сәясәте белән дә, каләм көче ярдәмендә дә, җәмәгать эшлеклесе һәм галим-тикшеренүче буларак та актив хезмәт итү чорына аяк баскач, 1927 елны, каты авыру Г. Ибраһимовның өметләренә киртә куя. Элеккеге кебек тормышның төрле өлкәләрендә туктаусыз алга таба хәрәкәт итә, көтелмәгән яңа фикерләр һәм идеяләр тудыра




Г. Ибраһимовның тууына 125 ел тулуга багышланган җыентык. 2012

Сборник, посвященной 125-летию со дня рождения Г. Ибрагимова. 2012






Г. Ибраһимовка багышланган фәнни-гамәли конференция материаллары җыентыгы. 2012

Сборник материалов конференции, посвященной Г. Ибрагимову. 2012

авторитетом в татарском обществе, идейным вдохновителем. Еще 10 лет служения татарской культуре и обществу прошли между Ялтой и Казанью. Но случилась трагедия похлеще всех болезней – культ личности, политика уничтожения сильных, талантливых людей не дала возможности Г. Ибрагимову достойно дописать свою судьбу. Галимджан Ибрагимов стал жертвой той идеологии, в которую искренне верил; коммунистической, социалистической идеологии, которую считал единственно верным способом достижения светлого будущего для татарского народа, освобождения его, ради которой даже отрекся от своих прежних взглядов и соратников. К счастью, физическое уничтожение писателя не может уничтожить духовный мир, который он создал.

Жизнь, богатейшее творчество Галимджана Гирфановича Ибрагимова – прекрасный образец служения народу. Смысл, который упорно искал в жизни Г. Ибрагимов, несомненно, заключается в стремлении к высоким целям, служении своему народу, нации, ее возрождению и развитию.

алмаса да, әдип сафта кала, халык өчен абруйлы, акыллы, алдан күрә белү сәләтенә ия идея әйдәманы булудан туктамый. Тагын 10 ел татар мәдәнияте өчен юллар Ялта белән Казан арасындагы тыгыз бәйләнешләрдә сызыла. Әмма авырудан да зәһәррәк афәт – шәхес культы, көчле шәхесләрне юк итү сәясәте – аңа үз язмышын язып бетерергә мөмкинлек бирми. Галимҗан Ибраһимов үзе ышанып хезмәт иткән, татар халкын яктылыкка, азатлыкка чыгарачак бердәнбер юл дип караган, хәтта шушы уртак көрәш өчен үзе кайчандыр дөрес дип санаган фикерләрдән, көрәштәшләреннән ваз кичкән инкыйлаби идеянең, коммунизм-социализм төзү идеологиясенең корбаны була. Ләкин үзен физик яктан юкка чыгарса да, ул әдип төзегән рухи дөньяны юк итә алмый.

Галимҗан Гыйрфан улы Ибраһимовның шәхси тормышы, күпкырлы бай иҗаты – халыкка хезмәт итүнең соклангыч үрнәге булып тарихка язылды. Хәятта Г. Ибраһимов эзләгән мәгънә – халыкка, үз милләтенә, аның яңарышына һәм алгарышына хезмәт итүдә икәнлеге шиксез.




Суфиян Поварисовның Галимҗан Ибраһимовка багышланган трилогиясе
Трилогия Суфияна Поварисова, посвященная Г. Ибрагимову






Ф. Әбсәләмова һәм Ү. Гыймадиев тарафыннан төзелгән библиографик күрсәткеч. 1979
Библиографический указатель, составленный Ф. Абсалямовой и У. Гимадиевым. 1979




Г. Ибраһимовның тууына 125 ел тулуга багышланган «Галимджан Ибрагимов: документы и факты» китабы. Автор-төзүчесе М.Х. Ибраһимов. 2012 ел
Книга «Галимджан Ибрагимов: документы и факты», посвященная 125-летию Г. Ибрагимова. Автор-составитель. М.Х. Ибрагимов. 2012



Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты бинасы
Здание, где располагается Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ



*«Ул, яшим, ди иде. Яшәве гомум өчен иде. Ул алгы көненең күгендә өмит йолдызының ялтыравын күрә вә бөтен вөҗүде белән шуңа таба ашкына иде... Аның җаны бөек әмәлләр белән тулы булып, күңелендәге:*

*– Язмыш уң биреп, гомер вафа итсә, шул халыкның авыр көненә бер үзгәреш бирермен, томанлы вә караңгы хәятына бер нур тудырырмын!... – дигән өмете тышка бәреп чыгарга якынлаша иде»*

(Г. Ибраһимов. «Яшь йөрәкләр»)

*«Мин кулыма музыка коралы алып уйный башласам, шул минутта гүя эчем бөтен татарлык куәтен үзенә җыя… Шулвакыт мин, бәлки хыялыйлыгымнандыр, язмыш уң биреп, гомер вәфа итсә, музыкам белән татарның аслы рухын уятырмын, күгәргән йөрәген сафлармын һәм авыр язмышына бер үзгәреш бирермен, томанлы вә караңгы хәятына бер нур тудырырмын кебек хис итә башлыйм…»*

(Г. Ибраһимов. «Яшь йөрәкләр»)

*Әдәбият ... «Ул безгә назик вә мөәссир хисләр, гали моң, матур ләүхәләр түксен! Безгә гади күренгән нәрсәләрне бөтенләй башка итеп күз алдыбызга салсын. Шуның өчен дә истигъдадлары икърар кыйлынган олугъ шагыйрьләрнең хакыйкый шигырьләрендә табигатьнең моң, мөәссир вә матур мәнзарәләре, үзенең хиссияте шәхсиясе, әүлахе руханиясе мөһим урын тоталар. Вә алган мәүзугъларының да күбрәге адәмнең хыял вә хисенә тәэсир итә торган яклары алына вә мөмкин кадәр җанлы ләүхә вә җанлы тасвир чыгарырга мәел ителгән була».*

(Г. Ибраһимов. «Әдәбият мәсьәләләре»)

**ЖИЗНЬ И ТВОРЧЕСТВО ГАЛИМДЖАНА ИБРАГИМОВА**

Редактор *А.А. Мартьянова*
Верстка *Н.Т. Абдуллиной*

Формат 60×84 1/16. Гарнитура «Cambria».
Тираж 300 экз.

Подготовлен
в Институте языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, Казань, ул. К. Маркса, 12